Альберт ГАДЕЛ

ФОКУСЛАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

УДК 793.8(031)
ББК 85.35:92
Г13

Рәссамнары:
Рушан Шәмсетдинов, Илгиз Шәмсетдинов

Гадел, А. С.

Г13 Фокуслар энциклопедиясе / Альберт Гадел. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2016. – 143 б.

ISBN 978-5-298-03175-2

Атаклы фокусчы, Казан циркының баш режиссёры булып эшләгән Альберт Гадел әлеге китабында фокус серләрен ача: вак әйберләр белән манипуляция ясарга, пыяла ватыклары өстендә йөрергә, кадакка ятарга, ут йотарга өйрәтә. Фокус күрсәтергә бөтен кеше дә өйрәнә аламы, әллә фокусчы булып туарга кирәкме – монысын инде вакыт күрсәтер. Хәзергә, әйдәгез, фокус теориясен өйрәнергә!

УДК 793.8(031)
ББК 85.35:92

ISBN 978-5-298-03175-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2016
© Гадел А. С., 2016

Альберт ГАДЕЛ

ФОКУСЛАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2016

ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы 7

Нәрсә соң ул манипуляция? 10

Тәңкәләр белән манипуляция 10
Теннис шарлары белән манипуляция 13
Шарларны, яулыкларны пиджак итәгендә тоту жайланмасы 14
Фокус күрсәтү өчен жайланмалар 16
Күз буучының тылсымлы таягы 18
Букет әзерләү ысулы 20
Чәчәк ясауның икенче ысулы 22
Күз буучының костюмы 23
Реквизитлар әзерләү 24

Яулыклар белән фокуслар 25

Сихерләнгән кулъяулык 25
Тәңкә яулык аша чыга 26
Серле тартма һәм яулыклар 29
Буш яулык астыннан шәм пәйда була 31
Жыелмалы шәм ясау 32
Шәм ялкыны уч төбендә 34
Янмас тасма 37
Утта янмас яулык һәм серле шәм 39
Үзе чишелүчән яулыклар 42
Яулык астыннан чәчәкләр чыгару 45

Эчтәлек

Кубиклар белән фокуслар 47

Елыр кубик 47
Хәйләкәр кубик 49
Фокусчының кулы кубик аша чыга 51

Оча торган шарлар 53

Оча торган шарның беренче төре 53
Оча торган шарның икенче төре 54
Оча торган шарның өченче төре 57
Оча торган өстәл 59

Карталар белән фокуслар *62*

Магнитлы карталар 62
Киселмәс карталар 63
Карталарның мастьлары юкка чыга 64
Картаның масте уч төбендә югала 65

Баулар белән фокуслар 67

Үзеннән-үзе төйнәлүче, чишелүче бау 67
Киселгән бау яңадан ялгана 68
Тылсымлы бау 70

Су белән фокуслар 72

Буш кәсәләрдә су пәйда була 72
Хәйләкәр стакан 74
Тере су 75

Эчтәлек

Кәгазьдән акча ясау 76

Кәгазьдән акча ясауның беренче ысулы 76
Кәгаздән акча ясауның икенче ысулы 77
Янган газета кисәге акчага әверелә 77

Микромагия 79

Ясалма бармак белән фокуслар 80
Уч төбеннән яулыкның югалуы 81
Буш фунтикка яулык ничек барып кергән 82
Шырпы кабы белән «микромагия» 83
Шырпы кабы уч төбендә мәтәлчек ата 88
Шырпы кабы астында тәңкә юкка чыга 89

Менталь магия 91

Мнемотехника турында кыскача аңлатма 92
Тамашачының уен белү 93
Кул бармаклары белән төсләрне белү 94
«Күзле» бармаклар 95
Тамашачының күзенә карап төсне белү 96
Зирәк чыгыш 99
Уй-фикерне күз карашы аша тапшыру 100
Алдан күрү 102

Дәрвиш уеннары 105

Баш бармак аша энә-без уздыру 105
Беләк аша пычаклар уздыру 107
Магнитлы дәрвиш 110

Кылыч кисмәс кул 112
Тәндә ут йөртү 114
Ут йоту 116
Авыздан ут фонтаны 118
Ут өстендә йөрү 119
Үткен кылычлардан баскыч 121
Чылбыр-богаудан котылу 122
Пыяла ватыкларында йөрү 126
Кадакка яту 127

Эстрада гипнозы 129

Гипнозның кешегә тәэсире 132
Кан тибеше ярдәмендә яшерелгән әйберне табу 133
Чыгышның икенче варианты 134

Күз буу театры 135

Иллюзия трюкларының җыелма сере 137
Күренешләрнең алмашынуы 140

Фокус остасы. *Г.Ризванов* 141

СҮЗ БАШЫ

Мин балачактан Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре белән «женләнеп» үстем. Җиде-сигез яшьләрдә булдым микән, Зәй районының Югары Шепкә авылы клубында укытучы әнием Гөлҗәннәт белән (әтиебез хәрби очучы, 1945 елның февраль аенда, Венгрияне азат иткәндә, хәбәрсез югала) Казаннан килгән филармония артистлары концертында күз буучыны күреп шаккаткан идем. Хәй ага Мушинский булган икән ул. Үсеп җитеп, артист-иллюзионист булып эшли башлармын да Хәй аганың көндәшенә әйләнермен дип уема да килми иде.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли башлаганда, эстрада бригадаларында өч иллюзионист бар иде: Хәй Мушинский, Рәмзи Гарифуллин, Полина Половникова. Милли сәнгатебездә Советлар чорына кадәр ул жанрны яхшы белүче, башкаручы артистлар булмаган дисәм ялгышмам. Дөрес, циркта көрәшче Кара Әхмәт булуы турында бөек шагыйребез Габдулла Тукай үзенең «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасында язып калдыра.

1959 елда, иллюзия сәнгате дөньясында зур тавыш чыгарып, иллюзия остасы Али Вадның (Александр Вадимовның) «Искусство фокуса», «Фокус на клубной сцене», «Фокусы для всех» һәм иллюзия сәнгатенең тарихын «От магов древности до иллюзионистов наших дней» дигән китаплары бер-бер артлы басылып чыкты. Аңа ияреп, Мәскәү филармониясе иллюзионисты Арутюн Акопян да «Фокусы на эстраде» дигән китабын бастырды. Фокус сөючеләр һәм шулай ук эстрадада эшләүче яшь иллюзионистлар өчен бу китаплар өстәл китабына әверелде.

Уналты яшьтән үк Пермь өлкәсенең Закамский шәһәрендә хәрби заводта хезмәт кую, Урта Азиядә «бәхет эзләп» ачлы-туклы дөнья күрү, армия хезмәте, институтта уку, филармониядә артист-иллюзионист булып эшләү, цирк артисты, Казан циркының баш режиссёры булып утыз ел эшләгән чорлар артта, кире әйләнеп кайтмаслык булып, томан эчендә калган.

Менә инде тормышта күргәннәрне, узганнарны сагынып, искә алу чорына килеп тә житкәнмен. Уртаклашасы серләрем бар: шушы китапта иллюзия (күз алдау) сәнгатенең серләрен ачасым килә.

Сүз башы

«Иллюзия – күз алдау – «күз буу» тарихы белән танышыйк. Тарихчылар күз буу сәнгате Мисырда туган дип саныйлар. Безнең эрага кадәр биш мең еллар элек үк Чатча-Эм-Анк дигән тылсымчы Хуфу фиргавенне үзенең чыгышы белән гаҗәпләндергән. Сәнгать тарихчылары, папирусларда сурәтләнгән «могҗизалар» бүгенге күз буучыларның номерларын хәтерләтә, дип язалар.

Борынгы Мисыр, Халдей, Бабил, Грециядә җир асты мәгарәләренең серле бүлмәләрендә ул «могҗизалар»ның серләре сакланган. Дин әһелләре ул серләрне, күз карасы кебек саклап, буыннан-буынга гына тапшыра торган булганнар. Тылсым гыйлеменә ия булу аларга үзләрен Аллага якын кешеләр итеп күрсәтү өчен кирәк булган.

Ул чорда зур акыл, тапкырлык белән эшләгән механизмнар гыйбадәтханәләрдә гади халык өчен, чынлап та, могҗизалар күрсәткән: Алла сыны күз алдында җанланган, алтарьларда үзлегеннән «изге утлар» кабынган. Таш сыннар динне мактап «елаганнар».

Фокус – күңелле шаяру гына түгел, катлаулы башваткыч та. Шуңа күрә фокусчы иҗади булырга, механиканы, физиканы, химияне белергә тиеш. Артист өчен кулларның, бармакларның җитезлеге, сәхнәдә үзен тотышы да кирәкле сыйфатлар.

Фокусчылар ике төркемгә бүленә: күз буучы һәм манипуляторга.

Күз буучы үзенең чыгышында күптөрле катлаулы аппаратлар, механизмнар кулланса, манипулятор үзенең хәрәкәтчән оста бармакларына, кул чукларына таяна.

Манипуляция – катлаулы кул хәрәкәтләре ясап, оста итеп фокус күрсәтү. Манипуляция – күз буу сәнгатенең «әлифбасы». Гәүдәнең, кул чукларының нәфис хәрәкәтләнүе, башның борылуы, күзнең сизелер-сизелмәс кенә уйнавы артист-манипулятор чыгышында бик әһәмиятле.

Күп очракта фокусчы, манипуляция белән күз бууны кушып, программасын баета, осталыгын арттыра, профессиональ яктан үсә. Ялкау артист-иллюзионистлар да очрый, алар, манипуляцияне кире кагып, үзләренең чыгышларын ярлыландыралар, программаларында катлаулы зур аппаратлар, механизмнар кулланалар. Циркта еш кына манеж астына төшү өчен люклар, төрле җайланмалар ярдәмендә, «юк булу», «пәйда булу» кебек трюкларны ясыйлар.

Бу очракта инде күз буу сәнгате гади генә машиналар хәрәкәтенә кайтып кала: бөтен эшне ассистентлары башкарып, артист – күзәтүче генә булып чыгыш ясый.

Манипуляция – күз буу сәнгате – балет станогы янында кул, аяк, гәүдә хәрәкәтләре ясауны таләп итә. Кулларның житезлеге, осталыгы тамашачыларны һәрвакыт гаҗәпләндерә. Фокусчының бармаклары, пианист, баянчыларның бармаклары кебек оста хәрәкәтләнеп, чыгыш ясаганда, уңышларга ирешергә ярдәм итә.

Бу китапны укып чыктым да фокусчы булдым дигән сүз түгел. Оста күз буучы булу өчен, манипуляция техникасын-кагыйдәсен яхшы үзләштерер, шактый репетицияләр ясарга, тир түгәргә кирәк.

Мин чыгышларымда, манипуляция белән күз бууны катнаштырып, бербөтен тамаша ясыйм. Кайсы күз буу, кайсы манипуляция икәнен тамашачы аңламый да кала. Мавыктыргыч серле тамаша күреп, кеше йә соклана, йә гаҗәпләнә. Фокусчының ялгышырга хакы юк. Ялгышса, көлкегә каласы көн кебек ачык. Кем дә кем яхшы фокусчы буласы килсә, манипуляция техникасын яхшылап өйрәнергә тиеш.

Без иң элек төрле вак әйберләр (реквизитлар) белән манипуляция ясарга өйрәнербез, аннары күз буу, аппаратлар белән чыгыш ясау булыр. Шулай ук микромагия, менталь магия, дәрвиш уеннары, сәхнә гипнозы, «күз буу, кара бүлмә» (кара театр) алымнары, серләре белән дә танышырбыз.

Нәрсә соң ул манипуляция?

Кагыйдә

1. Манипуляциянең гадиен булсынмы, катлаулысынмы, әйбәтләп өйрәнмичә, беркемгә дә, хәтта өйдәге туган-тумачаларыгызга да күрсәтмәгез. Уңышсызлыкка очрап, көлкегә калуыгыз бар. Фокусчы өчен аннан да начары юк. Манипуляция, күз буу трюкларын күрсәткәндә, артист ялгышмаска тиеш.

2. Шул ук манипуляцияне, фокусны беркайчан да бер үк кешеләр каршында кабатлап күрсәтмәгез!

3. Мактанып, шаярган булып манипуляциянең, иллюзиянең серен бервакытта да ачмагыз. Тамашачы фокусчының серен белмәскә тиеш. Манипуляция бит әле ул фокус түгел, ә аның ярдәмчесе генә. Шуңа күрә сер ачылмасын, тамашачы гаҗәпләнерлек булсын.

4. Уңышсызлыклардан курыкмагыз, шаяртып төзәтеп җибәрсәң, аны тамашачылар сизми дә кала, «шулай кирәктер» дип кенә уйлый.

5. Яңа трюклар уйлап табыгыз. Һәр чыгышыгыз бәйрәмгә әйләнсен. Сәхнәдә фокус күрсәтү җан азыгы булсын. Шул вакытта гына чын артист-күз буучы (фокусчы) булырсыз. Тамашачыларга һәрвакытта рәхмәтле булып баш иегез, тез чүгегез. Шул вакытта гына тамашачылар сезне яратырлар, хөрмәт итәрләр.

Тәңкәләр белән манипуляция

Күнекмәләр ясау өчен, төрле зурлыктагы тәңкәләр кирәк. Совет чорындагы 1 сумлык, хәзерге 5 сумлык тәңкәләр кулай. Алар залдагы тамашачыга яхшы күренәчәк. Күнегү өчен лимонад, сыра шешәләренең сырлы калай капкачлары бик әйбәт. Тәңкәләр, бөкеләр белән эшләгәндә, пальмировка (франц. *кучеру*), ягъни сиздермичә тәңкәне ачып уч төбендә тоту, уч төбенә кысу алымын яхшы итеп үзләштерергә кирәк.

Тәңкәне сул кулның уч төбенә куеп, «уңайлы урын» эзләгез, учның кайсы җирендә тәңкә яхшы кысылып тора ала, шунда туктагыз. Учның кайсы җире икәнен төгәл генә әйтеп булмый, чөнки төрле кешенең кулы төрлечә. Һәрбер өйрәнчек үзе, шул уңайлы урынны табып, репетицияләр уздырырга тиеш. Зур

көзге алдында күнегүләр уздыру үз-үзеңнең һәр хәрәкәтеңне күреп, ялгышларны бетерергә ярдәм итәр. Кул хәрәкәтен, гәүдә тотышын, мимиканы күзәтү уңайлы, файдалы булыр.

Пассировка тамашачыларның игътибарын җәлеп итү өчен кирәк. Янәсе, тәңкәне (шарны, бөкене) бер кулдан икенче кулга күчерәсез, ә ул вакытта тәңкә үз урынында, уч төбендә кала. (1 нче рәс.).



1 нче рәсем

Чыгыш вакытында бер үк хәрәкәтләрне кабатламагыз, тамашачыларның шикләнүе мөмкин. Шуның өчен төрлечә «пассировка» – күчерү хәрәкәтләрен үзләштерергә кирәк.



2 нче рәсем

Иң элек тәңкәләр белән оста итеп пассировка ясарга өйрәнегез, аннан соң башка төрле әйберләргә күчәргә була. Өйрәнергә җиңел булсын өчен, пассировканы гадирәк ысуллардан башлыйбыз. Һәр кешенең биш бармагының да исемнәре бар: баш, имән, урта, атсыз һәм чәнти бармаклар.

1 нче ысул. Уң кулыгыздагы тәңкәне имән бармак белән урта бармак арасына кыстырып (2 нче рәс.), баш бармак белән җиңел генә тотып, тәңкәне сул кулга күчерү хәрәкәте вакытында тәңкәне уч төбенә, үзегез «тапкан» җиргә куегыз. Ялган хәрәкәт ясап, янәсе, тәңкәне сул кулның учына саласыз (3 нче рәс.).

3 нче рәсем

Уң кул белән сул кул өстендә «сихри» хәрәкәтләр ясап, ике кулның да бармакларын, ачып, тамашачыларга күрсәтегез. Тәңкә юкка чыккан.

Сул кулның уч төбен (4 нче рәс.), уң кулның аркасын күрсәтеп, кулларның буш булуын, тәңкәнең юкка чыгуын күрсәтәсез. Ә чынлыкта тәңкә уң кулның уч төбенә кысылган була (4 нче рәс.).

4 нче рәсем

Хәзер инде «югалган тәңкә»не кайдан теләсәгез,

5 нче рәсем



6 нчы рәсем

7 нче рәсем

шуннан алырга була: тамашачының чәченнән, колагыннан, кесәсеннән һ.б. җирләреннән.

2 нче ысул. Уң кулның имән бармагы белән чәнти бармак арасына тәңкәне куясыз (5 нче рәс.). Тәңкәне сул кулга күчергән булып, имән бармак белән чәнти бармак тәңкәне кысып тора.

Сул кул, тәңкәне учына алган кебек, ялган хәрәкәт ясый. Өстәлдән йә кесәдән тылсымлы таякны уң кул белән алганда, уч төбендәге тәңкәне тиз генә кесәгә йә өстәлгә төшерәсез (6 нчы рәс.).

Хәзер инде куллар буш. Серле хәрәкәт ясап, тылсымлы таяк белән сул кул өстендә йөртәсез дә, кинәт уч төпләрен ачып күрсәтәсез. Тәңкә тылсымлы таякның тылсымы белән юкка чыккан.

Пассировкалар күптөрле. Кулның уч төбенә карап, үзенә уңайлы вариантны сайларга кирәк. Репетицияләрне зур көзге каршында үткәрү – кимчелекләрне күреп төзәтү өчен бик кирәкле чара. Тәңкәләрне төрлечә тотарга була, бары тик серенне тамашачы гына күрмәсен. Кайбер фокусчылар тәңкәне кабыргасы белән ике бармак арасына кыстырып күчерәләр (7 нче рәс.).

Манипулятор ике кулы белән дә оста пассировка ясый белергә тиеш. Бигрәк тә сул кулга игътибар биреп, аны уң кул кебек эшләргә өйрәтергә кирәк.

Пассировка еш кына әйберләрне югалту өчен генә түгел, ә аларны сиздермичә икенче әйбергә (тәңкәгә) алыштырып кую өчен дә кулланыла.

Алыштыру – күз буу сәнгатендә киң таралган ысул. Әлеге алым белән бик күп фокуслар, трюклар башкарыла. Алыштыру вакытында «игезәк тәңкә» (шар, яулык һ.б. әйберләр) тамашачыларның күз алдында була. Ә шул вакытта алышынасы әйбер (тәңкә, яулык һ. б.), күренмичә , фокусчы кулында кала. Әй-

бер алыштыруны фокусчылар шанжировка (франц. *алыштыру*) дип йөртәләр.

Әйтик, тамашачыдан алып торган тамгалы тәңкәне алыштырып, ниндидер трюк күрсәтәсез. Тиз генә, тамашачыга сиздермичә, фокусчы өстәлдән (йә кесәсеннән) шундый ук тәңкә ала. Аны «игезәк тәңкә» дип атыйк. «Игезәк тәнкә»не, сиздермичә, сул кулга, имән бармак белән урта бармак арасына күчерәсез дә (пальмировать итәсез), тамашачыларга кул аркасын күрсәтеп, уйлаган трюгыгызны башкарасыз.

Теннис шарлары белән манипуляция

Пальмировка ясаганда, тәңкә урынына шарлар да кулланыла. Бу очракта шарны, тамашачы күзеннән яшереп, уч төбендә кысып тотасың. Ул вакытта кулны тамашачыга арты белән борасың. Шул рәвешле, тамашачы шарны күрми. Уңайлырак булсын өчен, шарларга бераз канифоль порошогы сибәләр. Шулай иткәндә, шар уч төбенә әйбәт ябыша. Канифольне нарат сумаласыннан ясыйлар. (Ул паяльник белән эшләгәндә кулланыла.)

8 нче рәсем

Шарны төшмәслек итеп уч төбенә куеп, бармакларны сузып, кулны хәрәкәтләндерәсез. Шулай итеп, шар учның мускуллары кысуы аркасында ябышып торыр (8 нче рәс.).

Рәсемдә күрәсез, кул аркасы иркен ачылган. Шарны уч төбендә шулай итеп тотарга өйрәнергә кирәк.

«Ни өчен кирәк соң шундый мәшәкатьле пальмировка?» дигән сорауга җавап бер генә: тамашачылар фокусчының уч төбенә яшерелгән әйберне күрмәскә тиеш. Бөтен сер – оста итеп яшерә белүдә.



9 нчы рәсем

Шар белән пассировка ясау бармак очындагы шарны уч төбенә күчерү һәм шулай ук бер кулдан икенче кулга күчерүдән гыйбарәт.

Тамашачыларга яшермичә күрсәтеп, күз алдында

10 нчы рәсем

кулдан-кулга күчерү ысулы: фокусчы, ялган хәрәкәт ясап, янәсе, күз алдында шарны кулдан-кулга күчерә. Ә чынбарлыкта шар уң кулда, уч төбендә кала.

Уч төбе ярдәмендә шарны күчерү. Уң кулның уч төбенә шарны куясыз. Сул кул, шарны алган кебек, ялган хәрәкәт ясый (9 нчы рәс.), учны ябабыз. Шар уң кулда кала. Кулларны аергач, фокусчы уң кулын үзенә таба әйләндерә, шулай итеп, тамашачылар күзеннән яшерә. Ә сул кулы, шар кысып тоткан кебек, ялган хәрәкәт ясый (10 нчы рәс.).

Тамашачылар шарның сул кулда булуына ышаналар. Чөнки уң кулдан сул кулга шарны яшермичә күчергән идек.

Хәзер инде, җиңелчә генә гәүдәне борып, шарны кесәгә саласы, яки тылсымлы таякны алган булып, өстәлдәге «сервантка» шарны төшерәсе кала. Шар тамашачының күз алдында «эреп» юкка чыкты.

Фокусчы кулы белән җиңел хәрәкәт ясауга, аның буш кулында шар пәйда була. Бу трюк нинди дә булса аппаратсыз күрсәтелә.

Моның өчен фокусчының пиджагы эченә, итәгенә кыстыргыч тасмалар тегелә. Артист, җиңелчә, гәүдәсе белән тамашачыларга каршы якка (сәхнә түренә) борылган арада, уң йә сул кулы белән пиджак итәгенә кыстырылган шарны, җиңел генә алып, учына сала, һавага чөйгән була (11 нче рәс.).

11 нче рәсем

Шарларны, яулыкларны пиджак итәгендә тоту җайланмасы

Юка латунь калай кисәгеннән тасмалар кисеп алып, шар зурлыгында бөгеп, элгеч калдырып, паяльник белән кургашка эретеп ябыштырырга. Ул шар форма-

сында булырга тиеш (12 нче рәс.). Шарлар ычкынып төшеп китмәсен өчен, кыстыргыч тасмалар очына юка гына итеп изолента урарга (13 нче рәс.).

Калай булмаса, эләктергечне нечкә корыч чыбыклардан да ясарга мөмкин. Андый чыбыкны рояль, пианиноларга куялар. Һич булмаса, иске тростан кирәк кадәр зурлыкта кисеп алып, сүтеп, һәр аерым чыбыкны чүкеп тигезләп, шуннан шар тоту җайланмасы ясарга була.

Яулыкларны тоту җайланмасын ясау өчен, зур булмаган түгәрәк резинка кирәк булыр. Ул җайланманы пиджак итәгенә булавка белән беркетергә була (14 нче рәс.).

Фокусчының кирәкле реквизиты – иллюзия өстәле. Алдан ук әзерләп, өстәлгә «серле» таяк янына шарны куясыз, тамашачылар күрмәсен өчен, кечкенә яулык белән капларга мөмкин. Фокусны күрсәтә башлаганчы, артист буш кулларын ялгыш кына күрсәтеп, өстәл янына килеп «серле» таягы белән бергә, тамашачыларга сиздермичә, сул кулы белән шарны ала да җиңел генә пальмировка ясый, ягъни икенче кулына күчерә. Хәзер инде тамашачылар күз алдында кулда шар пәйда булуы бик җиңел. Яхшылап кат-кат репетиция ясагач, бу трюк бик җиңел башкарыла. Шушы ысул белән бүтән трюкларны да эшләп була.

12 нче рәсем

13 нче рәсем

Фокусчының кулындагы шар ничек юкка чыга. Шарларны югалту өчен, алда язылганча, беренче чиратта ялган пассировка кирәк. Пассировка ясап, шарны, янәсе, уң кулдан сул кулга күчереп кулны күрсәтсән, шар юкка чыга. Шулвакыт эчендә фокусчы тиз генә сул кулындагы шарны пиджагының тышкы кесәсенә сала.

14 нче рәсем

Соңыннан ике кулын да тамашачыларга күрсәтә. Пассировка булган трюкларны автоматик рәвештә күрсәтү дәрәҗәсенә житәргә кирәк. Аның өчен көзге каршында, тирләгәнче, кат-кат репетиция ясау бик мөһим. Шул вакытта гына фокусчының уңыш көтә.

Шарны төрлечә югалтып була. Бу очракта өстәлдәге «сервант» ярдәм итә.

Югарыда күрсәтелгән ысуллар арасыннан үзегезгә уңайлысын эзләгез. Ул сезгә фикер йөртергә, яңа ысуллар уйлап табарга этәргеч ясар.

Фокус күрсәтү өчен җайланмалар



1 нче рәсем



2 нче рәсем

Фокусчының өстәле. Күз буу сәнгатендә махсус эшләнгән, үзенә җәлеп итә торган өстәл кирәк. Поездда, пароходта барганда, ял йортында ял иткәндә, тамашачыларга, дусларга вак реквизитлар (тәңкәләр, карталар, яулыклар) белән генә өстәлсез дә фокуслар күрсәтергә була. Барлык реквизитлар кесәләргә сыеп бетә. Ә инде сәхнәдә, кичке клубларда, корпоратив кичәләрдә чыгыш ясар өчен, өстәл бик кирәк. Ул өстәл фокусчыга зур ярдәм итә, кызыксынучан күзләрдән сер саклый.

Фокусчы өстәле артистның буена карап ясала. «Югалтасы» реквизитны җиңел генә төшерергә йә алырга уңай булырга тиеш. Ул өстәл, җиңел сүтелеп, чемоданга сыярлык булса яхшы. Хәзер кибеттә, базарда өч аяклы элгечләр сатыла. Менә шул элгечләрнең аягы өстәл ясау өчен бик кулай (1 нче рәс.).

Өстәл күптөрле вазифа үти, аннан төрлечә файдаланырга була. Өч аяклы элгечнең үзәк торбасын кыскартып, яңа зуррак диаметрлы торба беркетсән, чәчәкләр яшерү өчен өстәмә кесә-сервант була (2 нче рәс.).

Өстәлнең зурлыгы: буе 50 см, иңе 40 см булып, уртасына өчаяк беркетелә. Арткы өлеше сервант (кесә) вазифасын үти. Өстәлнең өсте дә, сервант та кара тукыма белән ябыштырыла.

Өстәлнең серванты күзгә ташланмасын өчен, аның дүрт ягына да озын кара төстә челтәр эләргә кирәк. Ул күзгә җиңел булып күренә, чөнки челтәр аша тамашачыга өстәлнең ялтыравыклы аягы гына күренә. Өстәлнең аяклары ялтырап торырга тиеш. Обой кибетләрендә үзе ябыша торган ялтыравыклы плёнкалар сатыла, торбаларны шулар белән пөхтә итеп бизәргә була (3 нче рәс.).

Өстәлгә торба аяк җиңел беркетелеп, тиз сүтелсен өчен, фанер өстәлгә торба беркетергә кирәк (4 нче рәс.).

Ул торбаны, каты калайны кисеп, үзәк торба тыгыз керерлек итеп, паяльник белән ябыштырып, кыска торба ясыйсыз да заклёпкалар белән өстәл өслегенә беркетәсез.

Өстәл өсте калынлыгы 4–5 мм фанера булса, авырлыктан бөгелмәс. Өстәл өстенең эчке ягын лобзик белән кисеп, сервант ясала һәм кара тукымадан «кесә» тегеп, төбенә фанер саласыз. Ә уртага, торба беркетелгән җирдә, түгәрәк сызып тишелә. Өстәл өстен кара тукыма белән ябыштырганда, уртадагы торба тишеген яшерү өчен, түгәрәк чүпрәк клапан каплавы калдырасыз.



3 нче рәсем



4 нче рәсем

Шулай ясалган өстәл, җиңел генә сүтелеп, чемоданга, йә зур сумкага сыяр, юлда йөртергә уңайлы булыр. Сервант янында нечкәреп калган фанер сынмасын өчен, аркылыга-буйга өстәмә калай пластинка кагып куйсагыз, өстәлегез озак хезмәт итәр (4 нче рәс.).

Бераз тәҗрибә туплагач, үзегез яңа өстәлләр, уңайлы җайланмалар уйлап чыгарырсыз. Иҗади эш һәрвакытта алга барырга тиеш. Хәзер яшь фокусчылар бик тә кызыклы трюклар уйлап табалар. Иске трюкларны танымаслык итеп яңартып, тамашачыларны гаҗәпләндерәләр.

Фокус сәнгате – бик мавыктыргыч жанр ул. Аңа бер кереп китсәң, гомерлеккә каласың.

Күз буучының тылсымлы таягы

Күз буучыга таяк – бик кирәкле реквизит. Таяк тамашачыларның игътибарын читкә юнәлдерергә ярдәм итә. Шуннан файдаланып, артист кулындагы «югалтасы» әйберне җиңел генә сервантка ташлый, йә өстәлдән тамашачыларга күрсәтмичә ала.

Мин, «коры» таякны тотып кына фокус күрсәтмәс өчен, таякны трюкларга баеттым, чынлап торып тылсымлы таякка әвереләдердем. Казан фотоплёнкалар заводы «лавсан» плёнкалар эшли башлагач, брак плёнкаларны сорап алдым. Алар, юмартланып, төрле калынлыктагы плёнкаларны күпме кирәк, шулкадәр бүләк иттеләр. Шул плёнкаларны тасма итеп кисеп (5 см киңлегендә, 1 м 20 см озынлыгында), торба-таяк ясап карадым. Ул торба-таяк, җиңел генә сүтелеп, яулык белән каплагач юкка чыкты. Әлбәттә, юкка чыкмады, уч төбендә яшеренеп калды. Ул гына аз булып тоелды. Башта ак төстәге таякны, яулык белән каплап, кызыл төскә үзгәртергә булдым. Ә кызыл таякны чәчәкле яулык белән каплагач, таякны чәчәк гөлләмәсенә (букетка) әверелдерәсем килде.

1 нче рәсем

Тылсымлы таякны ясау ысулы. Лавсан, хлорвинил плёнкадан 5 см киңлегендә, 1 м 20 см озынлыгында лента кисеп аласыз. Лентаны кызыл аэ-

розоль белән буяп киптергәч, түгәрәк рулон итеп төреп, бәйләп куясыз (1 нче рәс.). Ул һәрвакытта шулай төрелеп торырга тиеш. Шулай төрелгән килеш торса, җыелу формасын ала, тиз юкка чыгару өчен кирәкле тылсымлы таякка әверелә. Түгәрәк рулонның эчке ягына, агачны шомартып, тәләкә (очлым) беркетәсез. Шул агач тәләкәгә плёнка-тасманы урап менгезәсез (2 нче рәс.).

Таяк сүтелмәсен өчен, өске башына бөке (набалдашник) кидерәсез.

Бөке плёнка-таякның юанлыгына карап ясала. Юка калайны, таяк юанлыгында бөгеп, паяльник белән кургашны эретеп ябыштырасыз. Алтын, көмеш төсендәге, үзе ябыша торган плёнка белән урап бизисез (3 нче рәс.). Кызыл төстәге таяк әзер.

2 нче рәсем


3 нче рәсем

Ак таяк ничек итеп кызылга әйләнә? Шул кызыл таяк өстенә аның озынлыгында икенче плёнка әзерлисез дә ак төскә буяп киптерәсез. Җыелган (заряженный) кызыл таяк өстенә ак тасманы урап менгезәсез дә икенче зуррак бөке белән беркетеп куясыз (4 нче рәс.). *А* таягы кызыл төстә, *Б* таягы – ак плёнка, кызыл таяк өстенә җыела. *В* – җыелган ак таяк, аның астында кызыл таяк нокталар белән күрсәтелгән. Күз буучының кулында хәзер «серле ак таяк».

Трюкны күрсәтү рәвеше. Ак таякны кызыл яулык белән каплагач, яулык астында, тамашачыга күрсәтмичә, ак таяк башындагы бөкене алгач, ак тасма үзлегеннән аска шуып төшә дә яулык белән бергә бөкене һәм ак тасманы артист сервантка ташлый.

Хәзер артист кулында кызыл таяк пәйда булды. Ак таякны кызыл яулык белән каплагач, ул кызыл



4 нче рәсем

5 нче рәсем



6 нчы рәсем



7 нче рәсем

төскә буялды. Тамашачы шулай итеп кабул итә. Хәзер артистның кулында кызыл таяк. Ул өстәлдән чәчәкле рәсем төшкән яулык алып, кызыл таякны каплап, ачып-ябып күрсәткәч, тамашачыга сиздермичә, яулык астында таяк башындагы бөкене ала, кызыл тасма шуып төшә. Тәләкәгә беркетелгән **букет-чәчәк** пәйда була. Яулыкка төрелгән бөке белән кызыл тасманы вазага яулык белән бергә сала. Шулай итеп, таяк, төсен алыштырып, букетка әверелә (5 нче рәс.).

Букет әзерләү ысулы

Каз мамыгыннан, каурыеннан чәчәк, букет ясау. Каз каурыен буяу – бик мәшәкатьле эш. Шуның өчен каз, тавык мамыкларын буяп, биючеләргә, җырчыларга ясалган муенса-шарфларны махсуслашкан кибетләрдән йә инде бөтен товарны бер бәядән сату челтәрләреннән алырга мөмкин. Мамык-муенсаны сүтеп, төрле төстәге каурыйларны, мамыкларны төсен төскә аерып аласыз. Кызыл, сары, зәңгәр төстәгеләре чәчәккә барса, ә яшел төсле каурыйлар яфрак вазифасын үти.

Каурыйлар тырпаеп, купшыланып торсын өчен, һәрбер каурыйны кайчы аркасы белән сыпырып турайтырга була. Букеттагы каурыйлар формаларын югалта башласалар, аларны пар өстендә тотып алырга кирәк.

Иң элек сыгылмалы тимерчыбыклар әзерләгез (корыч булса әйбәт). Алар 0,1–0,5 мм диаметрлы булырга тиеш. 30–40 см озынлыкта кисеп алып, очларына җиңел бөгелүчән җиз чыбыкны паяльник белән ябыштырасыз (6 нчы рәс.).

Җиз чыбыкны ватык электродвигатель катушкасыннан алырга мөмкин. Буласы чәчәкнең сабагына БФ-88 йә «Момент» җилеме белән яшел тасма ябыштырасыз (7 нче рәс.).

Чүпрәк ураган тимерчыбыкка (сабакка) каурыйларны беркетү авыр түгел. Чәчәк буласы, әйтик, кызыл каурыйларны әзер сабакка аз-азлап кына җилем сылап ябыштырасыз. Алар, матур булып, чәчәк сыйфатын алырга тиеш. Чәчәк бөресен көлтәләп, җиз чыбык белән берничә кат урыйсыз (8 нче рәс.).



8 нче рәсем

Кулыгыз ясаган чәчәк «бөресе» күңелегезгә хуш килсә, чәчәкнең сабагына аз гына җилем сөртеп, яшел каурыйларны ябыштырып, җиз чыбык белән урап төшәсез дә чәчәкнең сабак төбенә җиз чыбыкны сүтелмәслек итеп чорныйсыз. Чәчәкне һавага чөеп идәнгә төшкәч аумасын өчен, сабакны (корыч чыбыкны) энә кебек нечкәртеп очлап, авырлык өчен кургаштан йөк – балансировка ясыйсыз.

9 нчы рәсем

Балансировканы ясау бик гади. Кургаш кисәген чүкеп, юкартып, тасма кисеп, чәчәкнең сабагына тыгызлап урап куясыз. Кургаш күзгә ташланмасын өчен, аңа яшел чүпрәк тасманы җилем сылап урап ябыштырасыз. Күз буучының таягы букетка әверелүен күз алдына китерү кыен түгелдер инде.

Шулай итеп ясалган төрле озынлыктагы 5–7 чәчәкне паяльник белән бер-берсенә ябыштырасыз. Агачтан ясалган тәләкәгә (очлымга) дрель белән тишек тишеп, БФ-88 җилеме белән ныгытып, чәчәкләрне төшмәслек итеп ябыштырасыз. Таяк очын (наконечникны) акка буйыйсыз (9 нчы рәс.). Букет тәләкәгә начар ябышса, букетка юка калайдан өстәмә беркетмәләр эретеп ябыштырып, тәләкәгә кечкенә кадаклар белән беркетергә мөмкин (10 нчы рәс.).

10 нчы рәсем

Чәчәкләрнең озынлыгы төрлечә булу мәҗбүри. Чөнки чәчәкләрне учлап тоткач, алар плёнка-таяк юанлыгында булып, таяк чәчәк сабагы булып та хезмәт итә. Тамашачыларга зур букет булып күренә. Сез хәзер фокусчы таягы өчен букет та, аерым чәчәк тә ясарга өйрәндегез.

Чәчәк ясауның икенче ысулы



11 нче рәсем

Шулай ук сыгылмалы корыч чыбыктан чәчәк сабагы әзерлисез. Шул сабакка биш нечкә корыч чыбык эретеп ябыштырасыз. Ул чыбыклар чәчәкнең төп өлгесе булыр. Аның очларын энә кererлек итеп бөгеп, эретеп ябыштырасыз. Шулай ук озын җиз чыбыкны да эретеп ябыштыру кирәк (11 нче рәс.).

12 нче рәсем

Ефәк тукыманы чәчәк рәвешендә кисеп алып, читләрен җеп белән читләп куясыз (12 нче рәс.). Шулай эшләсәгез, тукыма сүтелмәс. Тукыманы, анилин буявы белән буяп, чәчәк төсенә кертәсез, чәчәк сабагындагы чыбык беркетмәләргә тегеп куясыз (13 нче рәс.). Чәчәкнең уртасыннан җеп тарттырып сабакка бәйлисез. Шулай эшләсәгез, чәчәк матур, нәфис булып күренер. Ефәк тукымадан ясалган чәчәкләр зур булып, чын чәчәкләргә охшап тора. Чәчәкләрнең зурлыгын үзегезгә кирәгенчә ясыйсыз.

13 нче рәсем

Өстә күрсәтелгән ысул буенча, чәчәкнең сабагына яшел каурыйны җилем белән җиңелчә генә ябыштырып, соңыннан җиз чыбык белән урап төшерәсез. Балансировка өчен чәчәк сабагының очына кургаш-йөк урыйсыз. Чәчәкне идәнгә ташлагач, «утырып» торсын өчен, сабакның очын энә кебек очлыйсыз (13 нче рәс.).

Хәзер сез күз буучының тылсымлы таягын ясарга өйрәндегез. Аңа тагын ярдәмче, кечкенә тылсым-

лы таяк та кирәк булачак. Ул таякны гади каләмне алып, үзе ябыша торган ялтыравык плёнкалар белән пөхтәләп ябыштырсаң, кесәгә сыярлык бик матур тылсымлы таяк әзер булыр (14 нче рәс.).

Икенче таякның булуы бик кирәк. Һәр очракта тамашачыларның игътибарын үзенә җәлеп итеп, ялган хәрәкәт ясап, фокус күрсәтергә ярдәм итәчәк.

14 нче рәсем

Күз буучының костюмы

Фокусчының костюмы өстәлнең сервантын да алыштыра ала, моның өчен аңа уңайлы яшерен кесәләр, элгеч-каптырмалар тегеп куярга кирәк.

Узган гасырларда фокусчылар, сәхнәгә тамашачылар алдына, киң, гаҗәп кызыклы халатлар, тюрбаннар киеп чыгып, үзләрен бөек сихерче-тылсымчы итеп күрсәтергә тырышканнар. Кытай фокусчылары хәтта халатлары астына мичкә белән су яшерә алганнар.

Бүгенге күзлектән карасаң, бу – бик гади трюк. Хәзерге заман тамашачылары мондый костюмны күреп шикләнерләр иде. Фокусның тәэсире, юкка чыгып, көлкегә әйләнер иде. Шуның өчен хәтта үзешчән артистларга да андый көлке халат киеп чыгуны киңәш итмәс идем. Төрле фокуслар, манипуляцияләрне гади костюм кигән килеш күрсәтү кызыклырак булыр.

Урта Азия артистлары милли, ыспай тегелгән халатлар кисәләр, аларга килешер иде. Ул вакытта инде костюмыңа ятышлы фокуслар әзерләргә кирәк.

Кызыклы фокус күрсәткәндә, күз буучыга костюмы да ярдәм итә. Артистның костюмы иң кирәкле реквизит та, сәхнәнең махсус киеме дә була. Шуңа



15 нче рәсем

күрә костюмны уйлап тектерегез яисә сатып алыгыз. Күз буучы-манипуляторның костюмында нинди кесәләр, элгечләр булуын 15 нче рәсемдә күрәсез.

Пиджакның якасы астына, каптыргыч ясап, тәңкәләр яшерергә була (1, 6), капкачы эчкә тыгылган пиджак кесәләре (3, 5), резинка элмәк-яулыклар, шарлар эләр өчен җайланмалар (4, 7, 8) күрсәтелә. Һәр җайланманы «ялган» хәрәкәт ясаганда, реквизитны җиңел генә алырлык урынга тегеп куярга кирәк.

Реквизитлар әзерләү

Күз буучының бөтен әйберләре, аппаратлары, аңа кирәкле вак кына каптыргыч та реквизит дип йөртелә. Алар шулкадәр күп: аларны санаудан мәгънә булмас.

Өйрәнчек-фокусчыга катлаулы аппаратлар ясау, сатып алу иртәрәк. Өйрәнчек, тәмам остарып беткәнче, кечкенә реквизитлар белән күнегүләр ясарга, трюклар кабатларга тиеш. Аннан соң инде зур трюкларга, аппаратларга да күчәргә була.

Фокусчы, жонглёр кебек үк, көненә ике-өч сәгать буе манипуляция, күз буу хәрәкәтләре белән осталыгын чарларга тиеш. Ялкауланса, көлкегә калуы мөмкин.

Реквизитлар пөхтә, чиста һәм матур итеп эшләнергә тиеш.

Исегездә тотыгыз!

Музыка җиде нотадан торган кебек, фокусларның да үз «каталогы» бар.

1. Пәйда булу.
2. Юкка чыгу.
3. Урыннан урынга күчү.
4. Зураю, кечерәю, төс алыштыру, форма үзгәртү.
5. Зур әйбернең кечкенә әйбергә керүе, әйләнүе.
6. «Ватылган» әйберне төзәтү, торгызу.
7. Табигать законын «бозу» – һавада әйберләрнең очып, йөзеп йөрүе.

Шушы каталогка карап, үзегезгә ошаган тышкы тәэсир калдыручы әйбер белән фокус ясасагыз, яңа трюклар (франц. *хәйләкәр, оста хәрәкәт ясау*) уйлап чыгарыгыз.

Яулыклар белән фокуслар

Сихерләнгән кульяулык

Тәэсире: артист тамашачыларга кульяулык күрсәтә, анда бернинди дә сер юк. Яулыкның очларыннан тотып, селкеп бөтерә. Аның кулында бөтерелгән кульяулык таяк кебек катып кала. Артист кулы белән ишарәләүгә, яулык алга, артка таба бөгелә, тамашачыларга баш ия. Төз басып торган яулыкны артист уң кулы белән «изә», яулык яңадан торып үз хәленә кайта.

Чыгыш шуның белән тәмамлана. Артист яулыкны, чишеп, яңадан күрсәтә, анда бернинди дә сер юк.

Реквизит: калын тукымадан кульяулык.

Сере: Каты итеп төрелгән кульяулыкны сул кулның баш бармагы хәрәкәтләндерә. Яулыкның төрү ысуллары рәсемдә күрсәтелә:



1 нче рәсем



2 нче рәсем

3 нче рәсем

3 нче А рәсем

Яулыкны тамашачыга күрсәткәч, сул кулыгыз белән *А* почмагыннан, ә уң кулыгыз белән яулыкның урта *Б* почмагыннан тотасыз (1 нче рәс.). Икенче рәсемдә күрсәтелгәнчә, аны бөтерә башлыйсыз. (Рәсемдәге укларга игътибар итегез!) Яулыкны бөтергәч, тигезләү өчен, очларыннан тартып турайтасыз.

4 нче рәсем

5 нче рәсем

5 нче А рәсем

Сүтелмәсен өчен, тиз генә яулыкның уртасыннан сул кулыгыз белән тотасыз (3 нче рәс.). Хәзер яулык таяк кебек «үрә» басып тора. Баш бармак белән яулыкны 2, 3 нче бармакларга кыстырасыз (4 нче рәс.). Артистның уң кулы «боерыгы» буенча яулык алга-артка бөгелә, тамашачыларны сәламләп баш ия.

Яулыкны хәрәкәткә китерү өчен, баш бармак, тамашачы сизмәслек итеп, 2–3 нче бармакларга кыса. Шулай иткәндә, яулык хәрәкәткә килә. Ә инде яулыкны «изәр» өчен, сул кулдагы яулыкка уң кул белән баскач, яулык «изелә». Уң кул изелгән яулыкны сиздермичә күтәреп төзәтә (5нче һәм 5нче *А* рәс.).



1 нче рәсем

Тәңкә яулык аша чыга

Тәэсире: фокусчы залдан бер тамашачыны чакырып ала. Танышкач, аңа зур гына тәңкә күрсәтә. Тикшерергә бирә. Тамашачы тикшереп, серен тапмагач, артистның учына сала. Артист учындагы тәңкәне һавага чөеп җибәргәндәй хәрәкәт ясый. Аның кулыннан тәңкә очып китеп юкка чыккан. Фокусчы, тамашачы янына килеп, аның култык астыннан (йә якасыннан) «югалган» тәңкәне алып, тамашачыга тотып торырга бирә. Ә үзе, өстәлдән яулык алып, аны төрле яклап күрсәтә.

Тамашачыдан тәңкәне алып, яулык белән каплый.

Тамашачыга яулык аша тәңкәне тотып карарга куша. Тамашачы тәңкәнең яулык астында булуын раслый. Артист, яулыкны ачып, тәңкәне залга күрсәтә дә янадан төреп куя.

Тамашачыга, өстәлдән зур гына балдак алып, яулык эчендәге тәңкәне «бикләп» куярга куша. (1нче рәс.).

Тәңкә яулык эчендә, балдак, йозак кебек, яулыкны чишәргә бирми.

Фокусчы өстәлдән пыяла стакан йә киң авызлы фужер алып тамашачыга тоттыра, тылсымлы сүз әйтергә куша: «Бер, ике, өч, балдак, яулык эченнән чык!» – дип.

Тамашачы, тылсымлы сүзләрне кабатлап, фужерны тотып тора. Артист, кулындагы яулыкны фужер өстендә селкеп, тылсымлы сүзен кабатлый. Гаҗәеп хәл: тәңкә яулык аша чыгып, фужерга челтерәп төшә. Артист яулыкны балдагы белән тикшерергә бирә.

Реквизитлар: зур кулъяулык, тәңкә, фужер, балдак йә алюминий торбадан кисеп алынган кыршау-балдак.

Сере: артист тамашачы белән шаярып, тәңкә алып манипуляция ясый. Манипуляция белән сез алда танышып уздыгыз. Бу – манипуляция белән күз буу катыш фокус күрсәтү.

2 нче рәсем

3 нче рәсем

4 нче рәсем

5 нче рәсем

Артист уң кулы белән тәңкәне алып, баш бармагы белән имән бармагы арасында тотып (2 нче рәс.), сул кулы белән тәңкәне яулык уртасында калдырып каплый (3 нче рәс.). Сул кулы белән яулыкны тәңкә өстендә төзәткән булып, сиздермичә, тәңкә артында яулыкны күтәрә дә баш бармагын каплый (4 нче рәс.).

Яулыклар белән фокуслар

Сул кулын алып, яулыгын «куыш» рәвешендә калдырып, уң кулы тәңкәне кысып тота. Хәзер баш бармак белән тәңкә арасында ике кат тукыма була (5 нче рәс.).

6 нчы рәсем

7 нче рәсем

8 нче рәсем

Шуннан соң сул кулы белән яулыкның очыннан тотып, тамашачы күргән ягын күтәреп, тәңкә аша артка уздыра. Бу хәрәкәтне ясау, тәңкә әле һаман да яулык астында дип, тамашачыларны ышандыру өчен кирәк (6 нчы рәс.).

Хәзерге хәрәкәт фокусның иң кирәкле сере: сул кулыгыз белән яулыкның ике очыннан аласыз да тәңкә аша югарыга күтәрәсез (7 нче рәс.).

Тамашачыларга тагын бер мәртәбә тәңкәнең яулык астында булуын күрсәтәсез һәм яңадан яулыкны элеккечә каплыйсыз (8 нче рәс.).

9 нчы рәсем

10 нчы рәсем

11 нче рәсем

Ә хәзер сез, чынлап та, тәңкәне яулыктан башка тотасыз, бары тик тамашачылар күзеннән «башлык» кебек капланган тукыма гына яшереп тора.

Сул кулыгыз ике катлы тукыма аша тәңкәне тотып торганда, уң кулыгызны яулык астыннан чыгарасыз. Тамашачылар тәңкәне яулык аша тота дип уйлыйлар, чөнки ул шулай күренә (9 нчы рәс.).

Бушаган уң кулыгыз белән тәңкә ята торган (жирне) яулыкны бөтерәсез (10 нчы рәс.). Яулыкны бөтергәч, тәңкәнең формасы яхшы күренә, хәзер яулык эчендәге тәңкә аша балдакны уздырасыз. Тамашачыга, чынлап та, тәңкә яулык эчендә калып, балдак белән «бикләп» тә куелды кебек тәэсир калдыра (11 нче рәс.).

Тамашачыга фужерны тотарга биреп, тылсымлы сүз әйттергәч, уң кулыгыз белән тоткан яулыкны, тәңкәне аска каратып, акрын гына селкисез. Селкетүгә, яулык эченнән тәңкә шуып, чылтырап фужерга төшә (12 нче рәс.)

12 нче рәсем

Серле тартма һәм яулыклар

Тәэсире: күз буучының кулында кечкенә матур тартма, әйтик, зәңгәр төстә. Ул аны ачып, төрле яклап күрсәтә. Бернинди дә сере юк. Тартманың капкачларын япкач, артист кулындагы тартма өстендә тылсымлы хәрәкәтләр ясагач, тартманың өске тишегеннән берәмләп, төрле төстәге яулыклар, соңыннан зур гына муенса (гәрәбә) чыгарып өстәленә куя бара. Сере юкны исбатлап, соныннан яңадан тартманы ачып күрсәтә.



1 нче рәсем

Шуның белән трюк тәмамлана. Фокусны дәвам

итеп яулыклар белән үзегез кызыклы трюклар уйлап табыгыз. Бер реквизит ике-өч фокуста катнашса, ул бигрәк тә отышлы булыр.

Реквизитлар: серле тартма, яулыклар, муенса һәм башка төрле әйберләр дә чыгарырга мөмкин.

Сере: икенче рәсемдә күренә. Арткы ике ишеккә сервант беркетелгән. Тамашачыларга тартманы күрсәткәндә, башта арткы ишекләрне ачып, сервантлар артта яшеренәләр (2 нче рәсемдә *А* белән *Б* күренә). Соңыннан берәмләп алгы ишекләрне *В* белән *Г*ны ачасыз. Тартма буш, үтә күренмәле булып күренә.

Тартманы япканда, беренче алгы ишекләрне *В* белән *Г*ны, соңыннан сервантлы *А* белән *Б* ишекләрен ябасыз. Тартманың ишекләре ябылып беткәч, «пасс» ясап, яулыкларны, муенсаларны аласы кала. Өстә язып узганча, фокус күрсәтүне дәвам итәсез.

Тартманы ничек ясарга. Каты катыргы йә юка фанер кисәкләрен рәсемдәгечә кисәсез. Детальләрне үзе ябыша торган зәңгәр (яшел, сары) төсле плёнка белән ябыштырасыз. Булачак тартманың һәр кисәген «пластик угольник» белән беркетеп, БФ-88 җилеме ярдәмендә ябыштырасыз. Булачак ишекләрнең элмәге (петля) урынына җилем белән калын тасма беркетәсез. Алар җиңел генә ачылып ябылырга тиеш. Планкалар, ишекләр вакытсыз ачылмасын өчен, ишекләрнең бер ягына өстәмә планка ябыштырырга кирәк.

Рәсемгә игътибар белән карагыз.



2 нче рәсем

Буш яулык астыннан шәм пәйда була

Тәэсире: артист ак ефәк яулык алып, төрле яклап күрсәтә. Бернинди дә сер барлыгы күренми. Яулыкны очларыннан тотып тартуга, яулык астыннан шәм чыга (1 нче рәс.).

1 нче рәсем

Буш кулын селтәүгә, кулында янып торган шырпы пәйда була. Артист шәмне кабыза, шәм яна (2 нче рәс.). Яулыкны төзәтеп, шәмне каплауга, шәм юкка чыга. Яулыкны селкеп күрсәтеп, шәмнең юкка чыгуын раслап, яулыкны өстәлнең сервантына сала.

Реквизитлар: ак ефәк яулык, шәмгә охшаган җыелмалы торба, үзлегеннән яна башлый торган шырпы.

Сере: артист өстәлдән уң кулы белән яулык алганда, сул кулы пиджак итәгеннән, жайланмадан «шәм»не ала (3 нче рәс.). Уң кулы белән сул кулына яулык япкач, тиз генә яулыкны буйга тарта да яулык астыннан шәм пәйда була.

2 нче рәсем

Сул кулы шәмнең төбеннән, уң кулы очыннан тар-



3 нче рәсем

4 нче рәсем

тып, шәмне турайта, шулай итеп, шәм пәйда була. Уң кулы бушагач, пиджагының лацканы (алгы якасы) астыннан, тамашачы көтмәгәндә, аның кулында янып торган шырпы пәйда була. Шәмгә ут кабыза, шәм яна.

Шәмнең януын күрсәтеп «нокта» куйгач, артист уң кулы белән филтәне тотып утны сүндерә дә тиз хәрәкәт белән шәмне аска, сул кулына җыеп төшерә (4 нче рәс.), шәм юкка чыга. Артист яулыкны селкеп күрсәтә дә өстәлнең сервантына сала.

Җыелмалы шәм ясау



5 нче рәсем

Серле таякны ясау ысулы язылган битне яңадан укып, булачак шәм озынлыгында плёнка кисеп алып, ак аэрозоль буяу белән юка гына итеп буйыйсыз.

Буяу кипкәч, агачны кырып ясалган шәм формасына (калыбына) плёнканы урап, берничә мәртәбә кайнар суга тыгып алып суытасыз. Плёнканы суытып, агач калыптан алгач, ул шәм формасында калыр (5 нче рәс.).

Шәм-торбаның очына филтәле җайланманы беркетергә кирәк (6 нчы рәс.). Аны Б-88 җилеме белән ябыштырырга була.

Филтәле җайланманы ясау ысулын белер өчен, «Утта янмас яулык һәм серле шәм» язылган битләрне укыгыз.

6 нчы рәсем



7 нче рәсем



8 нче рәсем



9 нчы рәсем

Пиджак итәгендә җыеп куелган плёнканы махсус торбачык тота (7 нче рәс.). Аны юка калайдан ясап, пиджакның эчке ягына, уңайлы җиргә тегеп куясыз. Сул кул белән тиз генә җайланмадан алып, уч төбендә кысып торга кирәк. Кат-кат репетицияләр ясагыз.

Искәрмә: плёнка-шәм сузылган килеш сакланырга тиеш. Чөнки плёнка үзлегеннән сузылу формасын югалтырга мөмкин.

Артистның кулында яна торган шырпы пәйда булсын өчен кирәкле җайланма болай ясала. Калайдан 4 см озынлыкта, 2 см киңлектә ике калай кисеп алып, шунын берсенә паяльник белән булавканы беркетәсез (8 нче рәс.).

Шырпы кабының «кабызгычлар»ын кисеп алып ике калайга да БФ-88 җилеме белән ябыштырасыз. Ике калай «кабызгычлар» арасына зур башлы шырпыны куеп, калайларны тыгыз итеп ике резинка белән бәйлисез. Шырпыны кинәт кенә тартып алсагыз, кулыгызда яна торган шырпы пәйда булыр. Шушы җайланманы пиджакның лацканы астына, уңайлы җиренә булавка белән кадап куясыз (9 нчы рәс).

Шәм ялкыны уч төбендә

1 нче рәсем

Тәэсире: өч аяклы шәмдәлдә зур гына шәм (1 нче рәс.). Артист, шәмдәл «өстәленнән» шырпы кабы алып, шәмгә ут кабыза. Шәм зур ялкын чыгарып яна. Артист, ике кулы да буш булуын күрсәтеп, шәмнең ялкынын ике учлап каплый (1 нче рәс.). Гаҗәеп хәл: артист кулларын шәмнән аерса, аның уч төбенә ияреп ялкын да күтәрелә (2 нче рәс.). Артист шәмнән аерылып сәхнәдә бераз йөргәч, яңадан шәм янына килә дә ялкын янып торган кулларын шәмгә төшерә. Ялкын яңадан шәмдә яна. Фокусчы зур гына яулык алып, шәм алдында йөртә (3 нче рәс.). Яна торган шәмнең ялкыны яулык аша сүлпән генә булса да күренә (4 нче рәс.).

2 нче рәсем

Артист сул кулы белән тоткан яулык очы белән шәмне каплый. Яулыкны күтәрсә, анда зур гына чәчәк гөлләмәсе (букет) утыра. (5 нче рәс.).

Реквизитлар: җыелмалы серле шәм, чәчәк гөлләмәсе, шәмдәл, шырпы кабы, серле яулык, тимерчыбыктан, фильтр-гильзаны күтәрү өчен, ыргак-каптыргыч (крючок). Бу фокус күптөрле детальләрдән тора. Шуның өчен һәр детальнең төзелешен аерым язарбыз.

3 нче рәсем



4 нче рәсем

5 нче рәсем



6 нчы рәсем



7 нче рәсем

8 нче рәсем

9 нчы рәсем

Сере: зур шәм, фокусчы таягы кебек, плёнкадан ясалып, җыелмалы була. Шәм-торбаның эченә зур чәчәк гөлләмәсе беркетелә, аларны плёнка төреп ала. Яулыкка тегелгән уймак (напёрсток) белән шәмне каплап, ялкынны сүндергәч, яулык белән бергә шәмне тотып торган филтә салган гильзаны шәм-торбадан аласыз. Шәм булып торган плёнка, үзлегеннән аска шуып, шәмдәлгә төшә. Хәзер шәм урынына төрле чәчәкләрдән торган зур гөлләмә пәйда була.

Чәчәкләрдән гөлләмә ясагыз. Чәчәкләрне паяльник ярдәмендә бер-берсенә ябыштырасыз (5 нче рәс.). Чәчәкләр белән бергә 5 мм калынлыгындагы винтны да ябыштыру кирәк. Чөнки ул, шәмдәлгә беркетелеп, шәмне тотып торачак.



10 нчы рәсем



11 нче рәсем



12 нче рәсем

Аннан соң аңа плёнканы урыйсы була
(6 нчы рәс.).

Шәмнең өске өлешендә плёнканы тотар өчен аерым торбачык ясап, аңа филтәле гильза куясыз (7 нче рәс.).

8 нче рәсемдә конус рәвешендә гильза күрсәтелгән. Аңа парафинга манып катырган филтә кисәген тыгып куясыз.

Гильзаның төзелеше конус итеп ясала. Торбачыкка жиңел керсен өчен, аны конус рәвешендә ясарга кирәк. Конусның тимерчыбыктан «сабы» бар (9 нчы рәс.).

Конуссыман гильзаны (ялкынны) күтәрү өчен жайланма, ыргак сыман каптырма да ясарга кирәк. Ул уң кулның урта бармагына киелә (10 нчы рәс.).

Ыргак-каптырма шырпы кабының артына кыстырыла (11 нче рәс.).

Шырпы кабын алганда, жиңел генә ыргак каптырманы бармакка киясез. Шырпы сызып, филтәгә ут кабызгач, шырпы кабын читкә куеп, буш кулларыгызны күрсәтәсез. Ике кулыгыз (учларыгыз) белән ялкынны каплыйсыз. Шул вакытта ыргак белән ялкынлы гильзаны эләктереп алып, алда язылганча күрсәтәсез. Яңадан шәмгә куясыз.

Яулыкны алганда, бармактан ыргакны жиңел генә салып шәмдәлгә куясыз. Ялкынны куллар арасында сак һәм оста итеп тотарга, йөртергә кирәк. Әгәр ялгыш гильза-ялкын ыргактан ычкынып

идәнгә төшсә, фокус харап булды дигән сүз! Ялкын йөртүне, шәмнән күтәреп алуны, яңадан шәмгә куюны яхшылап өйрәнергә кирәк. Шул вакытта гына яхшы тәэсир калдырырсыз.

Шәмнең төзелеше 12 нче рәсемдә күрсәтелгән.

Янмас тасма

Тәэсире: күз буучының кулында буш тартма. Аның өсте дә, асты да юк. Ян-якларында түгәрәк тишекләр (1 нче рәс.).

Артист, озын тасма алып, аны тартманың тишекләре аша чыгара (1 нче рәс.). Тасма тартма аша шуып йөри. Зажигалка белән тартма эченә ут кабыза. Тасма дөрләп яна. (2 нче рәс.).



1 нче рәсем



2 нче рәсем

Артистның тартмага җиңелчә генә өрүе була — ут сүнә, тасманы тартып чыгарып, тамашачыларга күрсәтә. Тасма янмаган, тартманы да төрле яклап күрсәтә, анда да бернинди дә сер күренми.

Чыгыш шуның белән тәмамлана.

Реквизитлар: серле тартма, 1,5 м озынлыгында тасма, зажигалка, ацетон.

Сере: тартманың төзелешендә. Тартманың бер як стенасының сере бар, ул ике катлы (3,4 нче рәс.).

Беренче стенага филтә кадакланган һәм шарнирга капкач эленгән. Ул ачылып ябыла. Тамашачылар ул капкачны чын стена дип күрәләр. Артист кулындагы тартманы төрле яклап күрсәтә дә түгәрәк тишекләр аша тасманы уздыра.



3 нче рәсем



4 нче рәсем

Тамашачыларга тартманы күрсәтә, тасма тартма эчендә шуып йөри (1 нче рәс.).

Тартманы алгы ягы белән залга әйләндергән вакытта, сул кулы белән капкачны ача. Капкач артындагы филтәгә, концерт башланганчы, мул итеп ацетон сеңдерергә кирәк. Зажигалка алып, филтәгә ут кабызасыз. Тамашачыларга тартма эчендәге тасма янган кебек күренә (2 нче рәс.). Тасма капкач астында була. Утны сүндергәндә, артист яңадан капкачны яба, ут үзлегеннән сүнә. Капкач ябылу белән, тамашачыларга тартманы тәкъдим итә, тасма үз урынында, аны, акрын гына тартып чыгарып, тамашачыларга күрсәтә.

Тартманың якынча үлчәмнәре (5 нче рәс.) өстән караганда:



5 нче рәсем

Утта янмас яулык һәм серле шәм

Тәэсире: фокусчы өстәлендә матур шәмдәлдә шәм тора. Артист шәмгә ут кабыза, шәм ялкынланып яна. Артист кулы белән җиңел хәрәкәтләр ясауга, кулында яулык пәйда була. Аны тамашачыларга төрле яклап күрсәткәч, яулыкның ике читеннән тотып, шәмнең ялкынына китерә дә, ялкынны яулык өстендә калдырып, ялкын аша яулыкны чыгара. Гаҗәеп хәл: яулыкка ут капмый.

Артист яулыкны тамашачыларга күрсәтә, яулыкка хәтта шәм корымы да тимәгән. Трюкны дәвам итеп, артист яулыгы белән янып торган шәмне бөтенләй үк каплый да тиз генә күтәрә. Шәм урынына 3–4 чәчәктән торган кечкенә гөлләмә пәйда була (1, 2 нче рәс.).



1 нче рәсем



2 нче рәсем

Реквизитлар: шәмдәл, трюклы шәм-торба, чәчәкләр, яулык, шырпы.

Сере: манипуляция ярдәмендә артистның кулында яулык пәйда була. Белгәнегезчә, артистның пиджак итәгенең эчке ягына яулык кыстырып куела, ялган җиңел хәрәкәт ясап, сул кулы белән пиджак итәгеннән яулыкны ала һәм, селкеп, һавага чөя.

Шәмнең төзелеше: юка калайны бөгеп, 25 мм калынлыгында, 110–113 мм

3 нче рәсем

4 нче рәсем

5 нче рәсем

озынлыгында торба ясыйсыз. Аңа серле җайланманы паяльник белән ябыштыргач, ак кәгазь чорнап, җилем белән ябыштырып, эрегән парафин белән «коендырасыз» – буйыйсыз. Ул чын шәм кебек. Торбаны шәм рәвешенә китергәнче, аңа серле җайланма куярга кирәк (3 нче рәс.).

Шәмнең филтәсе аерым җайланмага куела, рәсемнәргә карагач, аңлавы җиңелрәк булыр. Шәмнең филтәсе торба юанлыгындагы сай савытка куеп, парафин эретеп катырыла.

Нечкә тимерчыбыкны бөгеп, шәм формасына китереп, паяльник белән ябыштырып, савытны торбага беркетергә кирәк (4 нче рәс.).

Хәзер яулык филтә белән торба-шәм арасыннан җиңел генә шуып чыгар. Тамашачыга яулык ялкын аша узган кебек тәэсир калдырыр (5 нче рәс.).

Шәмнең чәчәккә әверелүе: каз мамыгыннан шәм торбасы озынлыгын-



6 нчы рәсем



7 нче рәсем

да өч-дүрт чәчәк ясыйсыз. Торба эчендә иркен йөрүен тикшергәч, бөке ясап, чәчәкләрне шул бөкегә беркетәсез (6 нчы рәс.).

Шәм-торбаны яулык каплап шәмдәлдән тартып алгач, чәчәкләр «утырып» калсын өчен, бөкедә чикләгеч (фиксатор) бар. Һәм шулай ук шәмдәлдә дә чикләгеч була. Шәмдәлнең төбенә сыярлык итеп фанерны түгәрәкләп кисеп, шуңа шудырып кертү өчен калайдан чикләгеч куясыз. Ә фанерны шәмдәлгә БФ җилеме белән ябыштырып куярга була (7 нче рәс.).

Филтәне әзерләү: мамыктан үргән бауны сүтеп, шәм өчен 6 см озынлыгында филтә әзерлисез. Калай савытта парафинны эретеп, шунда буласы филтәләрне салып, парафинны сеңдерәсез дә, филтә булып катсын өчен, фанер кисәгенә тигезләп салып суытасыз. Һәрбер филтәне, икегә бүлеп, саклау өчен, кечкенә тартмага саласыз.

Филтәне кую җайланмасы 8 нче рәсемдә күрсәтелгән.



8 нче рәсем

Яулыклар белән фокуслар

Үзе чишелүчән яулыклар

Тәэсире: артистның кулында дүрт яулык. Ул аларны берәмләп аерып күрсәтә. Ике яулыкны алып, әйтик, кызыл белән зәңгәр яулыкларны күрсәтеп өстәлгә йә тамашачы күз алдындагы урындыкка куя. Калган ике (сары белән яшел) яулыкны бер-берсенә бәйли дә өстәлгә куя. Яулыклар өстендә кулы белән тылсымлы хәрәкәт ясап, кул чабып алса, әле генә төйнәлгән сары, яшел яулыклар чишелгәннәр. Бәйләмичә куйган кызыл яулык белән зәңгәр яулык үзлегеннән бәйләнгәннәр. Артист үзләре бәйләнгән яулыкларны яңадан өстәлгә куя да «тылсымландырып» кул чаба. Яулыкларны берәмләп күтәрсә, үзлегеннән чишелгәннәр. Артист өстәлдә калган сары белән яшел яулыкны кулына ала да, яулыклар астыннан берәмләп, чәчәкләр алып идәнгә ташлый, алар аумыйча утыралар.



1 нче рәсем



2 нче рәсем

3 нче рәсем

4 нче рәсем

Реквизитлар: төрле төстәге дүрт яулык, 6–7 чәчәк, чәчәкләрне төрү өчен махсус капчык.

Сере: кызыл белән зәңгәр яулыкның очларына каптырма (кнопка) тегелә (1 нче рәс.). Аларны аерып күрсәткәндә, тиз генә бер-берсенә каптырасыз да өстәлгә куясыз. Ә калган сары белән яшел яулыкны ике төенгә төйнисез. Төйнәлүнең сере шунда: әйтик, сары яулык үзәк-сабак вазифасын үтәп, яшел яулык төен хасил итә (3 нче рәс.).



5 нче рәсем



6 нчы рәсем

7 нче рәсем

8 нче рәсем

9 нчы рәсем



10 нчы рәсем

Яулыклар белән фокуслар

Яулыкларны йомшак кына ике төенгә төйнәгәч, сары яулыкны сул кулыгыз белән тотып, уң кулыгыз сары яулыкның очыннан тотып, тартып турайта. Сары яулык яшел яулыкның «төене» эчендә җиңел генә шуып йөри. Яулыкларны өстәлгә куйганда, уң кул төенне тотып, яулык белән кулны каплауга, сары яулыкны яшел яулык «төененнән» шудырып чыгарасыз. Шулай итеп, яулыклар чишелә.

Ә үзләре төйнәлгән кызыл белән зәңгәр яулыкны чишү бик ансат. Уң кулга «төенне» каптырмадан (кнопкадан) ычкындырып, яулыкларны өстәлгә куясыз, яулыклар үзләре чишелгән. Бу фокусны җиңелрәк аңлау өчен, рәсемнәргә карап өйрәнегез.

Яулык астыннан чәчәкләр чыгару

Башта чәчәкләрне төрү өчен, тукымадан махсус җайланма-капчык тегәргә кирәк (1 нче рәс.). Ике катлы тукыманы (яулык төсендә) тегү машинасында 2 см киңлегендә калдырып тегәсез. Шул тар гына «кесәләргә» чәчәкләрне берәмләп кертеп, булавка белән каптырасыз.

Чәчәкләрнең сабак очлары энә кебек очлы булгач, «кесәләргә» тыгуы кыенлаша, шуңа күрә агачтан кечкенә тәләкә ясап (2 нче рәс.), чәчәкләргә шуны кидереп, «кесәләргә» тыгасыз (2 нче рәс.).

Хәзер әзерләп куелган чәчәкләрне төреп, булавка белән каптырып, өстәлнең серле җайланмасына куясыз (3 нче рәс.).

Яулыкларның дүртесен бергә алганда төрелгән чәчәкләрне дә алып, яулыклар белән каплап, шулар астыннан берәмләп чәчәкләрне идәнгә ташлый барасыз, алар тезелеп утыралар.



1 нче рәсем

2 нче рәсем

3 нче рәсем

Чәчәкләр кую өчен җайланма. Өстәлнең артына тимерчыбыкларны бөгеп, чәчәкләр кую өчен махсус җайланма эшләгез. Анда төргән чәчәкләрне куйгач, тамашачы күзенә ташланмасын өчен, кара тукымадан (өстәл өсте кебек) «алъяпкыч» беркетергә кирәк, рәсемнәрдә күрсәтелә.



Өстәлнең яннан күренеше



Өстәлнең арткы яктан күренеше



Өстәлдә чәчәкләр төрелгән капчык, өстеннән «алъяпкыч» капланган



Өстәлдә җайланма куелышы

Кубиклар белән фокуслар

Елгыр кубик

Тәэсире: артистның кулында кубик. Фокусчы шакмакны әйләндереп күрсәтә дә өстәлдәге катыргыдан ясалган, асты-өсте булмаган тартмага сала (1 нче рәс.).

Газетадан кулёк ясап, тартма эченнән кубикны алып кулёкка сала. Икенче кулы белән тартманы күтәреп, анда кубик юклыгын күрсәтә. Кулёк эчендәге кубикны тамашачыларга яңадан күрсәтә дә кулёкны, кубигы белән бөгәрләп, өстәлнең сервантына ташлый. Әле генә күрсәткән буш тартманы күтәрсә, кубик шунда була.

Артист кубикны тамашачыларга карарга бирә, анда бернинди дә сер юк.

Реквизитлар: акка буялган, кызыл (кара) түгәрәкләр ясалган (йәябыштырылган) агач кубик, катыргыдан кубик сыярлык итеп ясалган, матур итеп бизәлгән тартма, ясалма кәгазь кубик, газета (1 нче рәс.).



1 нче рәсем

Сере: агач кубик җиңел генә сыярлык итеп, ватман кәгазеннән ялган кубик ясала. Аңа түгәрәкләр ябыштырыла. Агач кубикның бөтен ягына да түгәрәкләр ясалган. Ә кәгазь кубикның сере – бер ягы ачык кала (2 нче рәс.).

Чыгыш башланганчы, агач кубик ясалма кәгазь кубик эченә салына. Тамашачыларга күрсәткәндә, кубикның ачык ягы уч төбенә караган була.



2 нче рәсем

Күрсәтү: артист кубикны төрле яклап күрсәтеп өстәлгә куя да аны катыргыдан

3 нче рәсем





4 нче рәсем

ясалган төссез, төпсез тартма белән каплый (3 нче рәс.).

Газетадан кулёк ясап, тартма эченнән ялган кәгазь кубикны алып, басым ясап күрсәтеп, кулёкка сала. Буш кулы белән тартма эчендә калган агач кубикны күрсәтмичә, тартманы кысып тотып, өстәлдән күтәреп күрсәтә дә яңадан урынына куя. Тамашачы кубикны кулёк эчендә дип уйлый. Кулёктагы кәгазь кубикны төргәч, артист бераз уйланып торгач, җитез хәрәкәт белән кулындагы кулёкны, ялган кубик белән сытып, бөгәрләп сервантка ташлый да өстәлдәге тартманы күтәрә. Агач кубик өстәлдә тора.

Кәгазь кубик-тышлыкны ясау ысулы. Башта агачтан, яхшылап шомартып, кубик ясагыз. Аны ак буяу белән берничә кат буяп киптергәч, трафарет белән кызыл (кара) түгәрәкләр ясагыз.

Ә кәгазь кубик-тышлыкка кызыл плёнкалардан түгәрәкләр ясап ябыштырасыз. Агач кубиктагы кызыл төсле түгәрәкләр кәгазь кубик түгәрәкләре төсендә булырга тиеш.

Хәйләкәр кубик

Тәэсире: сәхнәдә җыйнак кына ике өстәл. Артист, тамашачыларга күрсәтеп, өстәлләргә буш катыргы тартма куя. Кубик алып, аны төрле яклап күрсәткәч, беренче тартмага төшерә дә, кулы белән «тылсымлы» хәрәкәт (пасс) ясап, тылсымлы таягы белән тиеп алгач, тартманы күтәреп күрсәтә: кубик юкка чыккан. Тартманы үз урынына куеп, икенче тартманы күтәрсә, кубик шунда күчкән. Кубикны алып күрсәтә (1 нче рәс.).

Артист беренче өстәлдәге тартма өстенә органик пыяла куеп, шуның өстенә икенче өстәлдән буш тартманы алып, басым ясап күрсәтеп, пыяла өстенә куя.



1 нче рәсем

Кубикны алып, акрын гына беренче тартма эченә төшерә дә «тылсымлы» хәрәкәт ясап күтәрә. Тартма буш, кубик юкка чыккан.

Пыяланы алып, икенче тартманы күтәрә. Кубик, пыяла аша үтеп, астагы тартма эченә төшкән.

Реквизитлар: ике кечкенә өстәл, матур итеп бизәлгән ике катыргы тартма, ике серле кубик һәм органик пыяла.

Сере: кубикларның икәү булуын тамашачылар белми. Кубикларның ике башы ачыла торган (4 нче рәс.).



2 нче рәсем

Кубикның *А* башы – тышка, ә *Б* ягы эчкә таба ачыла. Хәзер тартманы тамашачыларга күрсәтсәң, тартма эче буш, үтә күренмәле була. Тартманы кубиклар тыгыз керерлек итеп ясарга кирәк. Әмма җиңел шуып йөрергә тиеш.



3 нче рәсем

Артист, трюкны күрсәтә башлаганда, тамашачыларга асты, өсте булмаган ике тартма күрсәтеп, өстәлләргә куя. Тартмаларның икенчесенә кубик яшерелгән була. Тылсымлы таягы белән селтәнүгә, беренче өстәлдәге кубик юкка чыга. Икенче өстәлдәге тартманы күтәрүгә, кубик шунда пәйда була.

Беренче өстәлдәге тартмага кубикны салганда, алгы ягы ачыла, ә арткы ягы кубик эченә ава, янәсе, юк була (2 нче рәс.).

Икенче өстәлгә тартманы куйганда, җиңелчә өстәлгә суккач, кубикның өсте үзлегеннән ачыла, ә аскы ягын кул белән этәргәч, ул да, ябылып, бер «бөтен» кубикка әверелә.

Кубикның пыяла аша узып аскы тартмага төшүенең сере. Беренче өстәлдә юкка чыккан кубик белән тартма тора. Тамашачылар ул тартманы буш дип уйлыйлар. Тартма эчендәге кубикны кысып тотып, өстәлдән күтәреп күрсәтәсез. Тартма буш булып күренә. Тартма өстенә органик пыяла куясыз (3 нче рәс.). Пыяла өстенә икенче тартманы куеп, кубикны төшерәсез. Кубик төшкәндә (4 нче рәс.), аскы өлеше аска таба ачыла, ә өсте кубик эченә ябыла. Артист, таягы белән тиеп алгач, икенче тартманы күтәрә, әле генә салган кубик юкка чыга. Тартманы (яшерен кубигы белән) алып читкә куясыз да, беренче тартма өстеннән пыяланы алып, беренче тартманы күтәрәсез, кубик өстәлдә ята. Тамашачыларга пыяла аша узган кебек тәэсир калдыра.



4 нче рәсем

Фокусчының кулы кубик аша чыга

Тәэсире: артист кулында төссез, төпсез тартма, аны тамашачыларга күрсәтеп өстәлгә куя (1 нче рәс.). Тартмага җиңел генә сыярлык кубик алып, аны төрле яклап күрсәтеп, тартма эченә тыга (2 нче рәс.). Тамашачы тартма эчендә кубик барлыгын күрә. Артист, тылсымлы таягы белән тартма өстенә сугып алгач, аны акрын гына тартма эченә тыга да икенче башыннан чыгара.

Алай гына да түгел, җиңен сызганып, кулын тартма эченә тыгып, кубик аша узып, тартманың икенче башыннан бармакларын күрсәтә. Кул да кубик аша тоткарлыксыз уза (3 нче рәс.).

Реквизитлар: өсте, асты булмаган, юка фанердан ясалган тартма (1 нче рәс.), серле кубик, фокусчы таягы.

Сере: кубикта. Кубик каты калайдан йә юка фанердан ясала. Кубикның *А* һәм *Б* яклары ачыла торган.

Рәсемнән күренгәнчә, *А* ягыннан *Б* ягына кулны тыксаң, алар бер якка ачыла һәм пружиналар ярдәмендә тиз ябыла да. 4 нче рәсемдә кубикның серле төзелеше күрсәтелә.

Ачылып ябыла торган *А*, *Б* яклары элмәкләргә беркетелеп, гел ябылып торсын өчен пружиналар куялар.

Тартманың да сере бар. Кубикны тартмага тыккач, икенче ягыннан чыгып китмәсен өчен, аңа чикләгеч (фиксатор) куярга кирәк (5 нче рәс.).



1 нче рәсем



2 нче рәсем

3 нче рәсем





4 нче рәсем



5 нче рәсем

Оча торган шарлар

Оча торган шарның беренче төре

Тәэсире: артистның сул кулында кечкенә матур тартма. Уң кулы белән тартма өстендә «тылсымлы» хәрәкәтләр ясый. Тартма эченнән ялтырап торган шар акрын гына (тартма эченнән чыгып) өскә күтәрелә, төрле хәрәкәтләр ясагач, янадан тартмага төшә (1 нче рәс.).

Артист шарны, алып, тамашачыларга күрсәтә, анда бернинди дә сер юк.

Реквизитлар: яңа ел чыршысын бизи торган кечкенә шар, матур итеп ясалган тартма, нечкә леска – кармак җебе һәм чыбык элмәк.

Сере: 2 нче рәсемдә яхшы күренә. Шарны нечкә борау белән тишеп, леска уздырыла. Лесканың бер башына кечкенә сәйлән бөртеге *А*, ә икенче башына түгәрәк сәдәп *Б* бәйләнә. Леска, шарның ике тишеге аша узып, өске ягында элмәк хасил итә. Шар аша лесканы нечкә тимерчыбыктан ясалган җайланма – элмәк тартып ала (2 нче рәс.).



1 нче рәсем



2 нче рәсем



3 нче рәсем

Артист, тартманы алганда, сул кулы белән сәдәп-не кысып тота, йә лесканың сәдәпле башын тарт-мага кыстырып куя. Пасс ясаган булып, шарнын икенче ягыннан чыккан *А*, леска элмәкне бармагы-на кия дә акрын гына тартмадан кулын читкә – өскә таба күтәрә башлый. Шар тартма эченнән үзлеген-нән очып чыга кебек тәэсир ясый. Артист бик сак һәм оста хәрәкәт итеп шарны очыра, берничә матур хәрәкәт ясагач, шарны тартмага төшерә.

Леска элмәктән бармагын алып, лесканы шардан тартып чыгара да тамашачыларга тикшерергә бирә. Тикшерүче шарда ике нечкә тишектән башка бер-нинди дә сер тапмый.

Оча торган шарның икенче төре

Тәэсире: өстәлдә шар тора (1 нче рәс.). Артист шарны алып тамашачыларга күрсәтә дә яңадан өстәлгә куя. Шул ук өстәлдән зур яулык алып, аны төрле яклап күрсәтеп, шарны каплый. Ике кулы белән яулык астындагы шар өстендә «тылсымлы» хәрәкәтләр ясагач, яулыкның ике читеннән тотып селкеткәләгәч, шар күтәрелә башлый (2 нче рәс.).

Яулык астындагы шар күптөрле хәрәкәтләр ясый. Яулыкның бер очы уң кулында гына калып, шар һаман да очуын дәвам итеп югарыга күтәрелә. (3 нче рәс.).

Артист сул кулы белән яулык аша шарны очудан туктата, уң кулы белән яу-лыкның очыннан тотып, ике куллап шарны өстәлгә куя. Аннары, шарны яулык аша күтәреп, сәхнә алдына килә дә кинәт яулыкны селки, шар юкка чыга. Шар, конфеттига (түгәрәкләп киселгән төрле төстәге кәгазь кисәкләре) әйләнеп, вак кисәкләргә тарала (4 нче рәс.).

Оча торган шарлар



1 нче рәсем

2 нче рәсем



3 нче рәсем

4 нче рәсем

Реквизитлар: диаметры 15 см лы шар, шарны тоту өчен 45–50 см озынлыгында корыч чыбык, зур матур яулык, сервантлы (кесәле) өстәл һәм конфетти.

Сере: өстәл кара тукыма белән капланган. Аның өстендә яшерен сервант урнашкан (5 нче *А* рәс.). Ул – шар сыярлык кесә. Тамашачылар күзенә ташланмасын өчен, кесә өстенә каты юка поролоннан кесә өсте беркетелә. Ул, рәсемдә күрсәтелгәнчә, кара тукыма белән тышлана. Шар сыярлык итеп өстәл сигез җирдән киселә (5 нче *Б* рәс.).

Өстәл өсте кара бәрхеттән яки кара плюш тукымадан ясала. Шар өстәлдән тәгәрәп төшмәсен өчен, кечкенә түгәрәк балдак-кыршау куела. Ул да, поролоннан ясалып, кара тукыма белән тышлана 5 нче *В* рәс.).

Оча торган шарлар



5 нче А рәсем



5 нче Б рәсем



5 нче В рәсем

6 нчы рәсем



7 нче рәсем



8 нче рәсем

Шарның төзелеше. Шарны тишеп, аңа калайдан киселгән тимерчыбык сыярлык җайланманы БФ-88 җилеме белән ябыштырасыз (6,7 нче рәс.). Җайланма озын булып шарның каршы ягына терәлергә тиеш. Шулай эшләнсә, шар тимерчыбыкта яхшы эленеп торыр. Шарны күтәрү өчен, тимерчыбыктан 45–50 см озынлыгында җайланма эшләнә (8 нче рәс.).

Күрсәтү ысулы: артист шарны алып күрсәтеп, яңадан урынына куя. Яулыкны алып селкегәч, шарны каплаганда, өстәлдә яткан тимерчыбык җайланманы яулык астында шарга тыга. Куллары белән өстәлдә яткан шар өстендә «тылсымлы» хәрәкәтләр ясагач, сул кулы белән яулыкның бер читеннән тота. Ә уң кулы белән, яулык астында калган тимерчыбык җайланманы алып, акрын гына шарны күтәрә.

Шар яулык астында очып йөри. Төрле хәрәкәтләр ясап очкач, сул кулы белән яулык аша шарны тотып (очып китмәсен дип), уң кулы ярдәмендә шарны өстәлгә куя. Шул вакытта шардан тимерчыбык җайланманы алып өстәлгә куя, ә шарны сервант-кесәгә төшерә.

Җитез хәрәкәт белән яулык астында калкып торган шарны ике куллап тотып, тамаша залына килеп селки, шар юкка чыккан. Шарны куйганда, сул кулы белән салфеткага төрелгән конфеттины алып, сытып-ертып яулык белән бергә селки. Шар вак кисәкләргә таралган тәэсир калдыра.



9 нчы рәсем

Яулыкның да сере бар. Яулык ике катлы. Шуның уртасына каты поролоннан ярымшар формасында тәлинкә тегелә (9 нчы рәс.). Яулык эчендә җәелеп ятсын өчен, тәлинкә 10–12 кисәккә киселә. Кулны яулык астына тыгып, шарны тоткан кебек, шул ялган түгәрәкне күтәреп (10 нчы рәс.), сәхнә алдына килеп селкетә, шар ватылып таралган тәэсир калдыра.

10 нчы рәсем

Оча торган шарның өченче төре

Тәэсире: сәхнәдә, 1 нче рәсемдә күрсәтелгәнчә, озын аяклы шәмдәлдә ялтыравыклы зур шар тора. Шар өстенә зур үтә күренмәле (газ) яулык капланган. Артист яулыкны ике кулы белән, ике почмагыннан алып, алгы ягын күтәреп күрсәтә. Тамашачы берниндидә сер күрми.

Яулыкны яңадан каплап, үзе басып торган ягында, яулыкның ике почмагыннан тотып, аны җәя. Шәмдәлдәге шар, акрын гына үзлегеннән күтәрелеп, яулык астында төрле хәрәкәтләр ясый башлый. Уңга, сулга авышып оча, аска, өскә күтәрелә. Хәтта яулыктан аерылып, өскә күтәрелеп, яулык алдына ук очып чыга. Шар яулыктан аерылып, идәнгә төшә. Артист яулыкның очын уң кулында гына калдыргач, шар үз-

1 нче рәсем

Оча торган шарлар



2 нче рәсем

3 нче рәсем



4 нче рәсем



легеннән югарыга таба шуып менә. Фокусчы сул кулы белән яулыкның икенче почмагыннан тоткач, шар югары күтәрелеп, шәмдәлгә очып барып төшә. Артист яулыкны куеп, ике кулында күтәреп, трюкның тәмамлануын белдереп баш ия.

Реквизитлар: озын аяклы шәмдәл, шар сыярлык матур кесә-савыт, серле шар, үтә күренмәле серле газ яулык, леска (кармак җебе).

Сере: шар уртадан тишелеп, аңа нечкә тимерчыбыктан «кендек» уздырып, ике башы да түгәрәкләнә, алка ясала. Ул алкаларга ике ягына да леска бәйләнә (4 нче рәс.).



5 нче рәсем



6 нчы рәсем

7 нче рәсем

Яулыкның сере: үтә күренмәле (газ) яулыкның өске ягына, ике почмагына да органик пыяладан кечкенә җайланма тегелә (5 нче *А* һәм *Б* рәс.). Шул тишекләр аша леска узып бер башы шарга, икенче башы ыргакка бәйләнә. 5, 6 нчы рәсемдә лесканы үткәрү тәртибе күрсәтелә. Леска ике өлештән тора. Лесканың бер башы шарга, ә икенче башы, яулык почмагына тегелгән органик пыяла аша узып, ыргакка бәйләнә.

Ике леска да (бертигез озынлыкта) өстә язылганча узгач, ыргакны, тамашачыга сиздермичә, чылбырга эләктереп куярга кирәк. Трюкны күрсәтергә әзерлек тәмамлана.

Күрсәтү: артист, шәмдәл белән шарны кулына алып, тамашачыга арты белән борылгач, тиз генә ыргакны чалбарына каптыра. Тамаша залына борылып, шәмдәл белән шарны идәнгә куеп, ике кулы белән алгы яктан яулыкны күтәрә. Тамашачы серне күрми, чөнки үтә күренмәле яулыкның ялтыраган җепләре аны яшерә (7 нче рәс.).

Шарны яңадан каплагач, артист яулыкны төзәткәләп ала да, ике кулы белән яулыкның органик пыяла тегелгән почмакларын кулына алып, акрын гына яулыкны тартып җәя. Шар җепкә тартылып хәрәкәт итә башлый. Бу трюкны күрсәтүдә саклык һәм пөхтәлек кирәк. Күнегүләрне көзге каршында кат-кат ясасагыз, фокус уңышлы булыр.

Оча торган өстәл

Тәэсире: кечкенә генә нәфис өстәл матур, зур ефәк яулык белән капланган (1 нче рәс.). Артист, яулыкны алып, өстәлне күрсәтә, анда серле җайланмалар күренми (2 нче рәс.).

Артист өстәлне яңадан яулык белән каплый. Өстәл өстендә, кулы белән «тылсымлы» хәрәкәтләр ясагач, яулыкның ике почмагыннан тотып, селкеп дулкынландыргач, өстәл акрын гына идәннән күтәрелә, артистның гәүдәсеннән дә югары күтәрелеп чайкала, як-якларга хәрәкәт ясагач, үз урынына төшеп утыра (3 нче рәс.).

1 нче рәсем



2 нче рәсем



3 нче рәсем



4 нче рәсем



5 нче рәсем

Реквизитлар: матур зур ефәк яулык, кечкенә генә нәфис өстәл.

Сере: өстәл өсте түгәрәк, юка фанердан ясала. Ак төскә буялып, үзе ябыша торган төрле төсле плёнкалардан түгәрәкләр кисеп ябыштырып бизәлә. Ул җыелмалы (4 нче рәс.).

Өстәл аягы – хлорвинил торба (су торбасы). Өстәлне тотып торыр өчен, ясалма чыршылар утырта торган әвернә кулланырга мөмкин. Ул җиңел дә, тиз дә сүтелә.



6 нчы рәсем

Өстәл өстенә аерым жайланма куела. Ул — өстәл аягы озынлыгындагы каты тимерчыбык. Торба да, чыбык та бер төстә, ялтыравыклы (яки кара) плёнкаларга төреләә, ябыштырыла (5 нче рәс.). Торбага чикләгеч (фиксатор) куелып, ул тимерчыбыкны яшереп, тотып тора.

Чыгыш ясау: артист, өстәлне күрсәтеп куйганда, тимерчыбыкны уң кулы белән яулык аша ала. Сул кулы белән яулыкның икенче почмагыннан тотып, яулыкны дулкынландырып (селкетеп) тора. Уң кулы яулык астындагы чыбык белән өстәлне акрын гына күтәрә. Тамашачыларга яулык үзе күтәрелгән шикелле тоела. Көзге алдында кат-кат күнегүләр ясаганда, уңышларга ирешерсез. Хаталарыгызны күреп төзәтегез.

Карталар белән фокуслар

Магнитлы карталар

Тәэсире: артистның кулында бер колода карта. Ул аларны астан да, өстән дә сыпырып күрсәтә. Карталар бер-берсенә ябышмаганнар. Сул кулына карта колодасын алып, уң кулы белән беренче картаны тарта башлый. Аңа ияреп, ике-өч карта күтәрелә дә туктап кала. Артист өстәге беренче картаны тартуын дәвам итә, алар тезелешеп шуышалар (1 нче рәс.). Барлык карталар да «асылынып», бер-берсенә ябышып торалар.

Артист карталардан латинча «S» хәрефе, түгәрәк ясап, яңадан сузып тота да, колоданы җыеп, берәмләп өстәлгә ташлый. Соңгы картаны бигрәк тә яхшылап күрсәтә, анда бернинди дә сер юк.

Реквизитлар: бер колода серле карта.

Сере: һәрбер карта артына «тел» ябыштырыла. Ә алгы ягына, аскы өлешенә БФ-88 җилеме белән шундый ук картадан кисеп алып, аркылы тасмалар ябыштырыла (2 нче рәс.).

Һәр картаның король, дама, валет рәсемнәре икенче, шундый ук төсле колодадан кисеп алып, буласы трюклы картаның дәвамы итеп, пөхтә итеп ябыштырыла.

Ике-өч адымнан караганда ул өстәмә тасмалар күренми. Кирәкмәгән карталар-



2 нче рәсем

1 нче рәсем

ның «күлмәкле» яклары бертөсле булган карталардан «телләр» – тасмалар кисеп алып, трюк ясаучы карта артына, нәкъ уртасына ябыштырыла.

Күрсәтүне тәэсир өлешендә язганча эшлисез. Бу катлаулы фокус түгел, күнекмәләр ясасаң, барысы да килеп чыга.

Карталарны сүтү өчен, «S» хәрефе яки түгәрәк ясаганда, колода тасманы астын өскә алыштырырга кирәк. Ул вакытта тасма карталарны сүтү җиңел булыр.

Киселмәс карталар

Тәэсире: артистның кулында өч карта. Черви алтысы, пики тузы һәм кресли дүрте (1 нче рәс.). Артист һәр картаны берәмләп күрсәтә. Урталарында пычак сыярлык ярык. Ул карталарны уенчык зур пычакка кидерә (2 нче рәс.). Аларны яңадан пычактан чыгарып, тезеп, кресли дүртен уртага куеп, өскә таба бераз күтәреп пычакны тыга (3 нче рәс.). Пычак аша узган карталарны төрле яклап күрсәтә дә, кинәт кенә карталарны тезенә куеп, өскә калкып торган дүртле крестига кулы белән җиңелчә суга. Карта киселеп, калган ике карта белән тигезләнә. Пычакны алып карталарны берәмләп күрсәтә. Кресли дүрте әле генә киселгән иде, ул да элеккечә киселмәгән.

Реквизитлар: өч карта, уенчык пластмасс пычак.

Сере: кресли дүртенең сере бар. Карта өч катлы (4 нче рәс.), ул рәсемдә яхшы күренә. Икенче картаның эчендә (кресли алтыда), карта шуып йөрерлек бушлык бар. Беренче мәртәбә пычакны карталардан алгач, өч картаны да тигезләп куеп, уртадагы кресли эченнән «серле» картаны беркетелгән җебеннән тартып чыгарасыз. Тамашачылар бу картаны үзләре күргән кре-



1 нче рәсем



2 нче рәсем



3 нче рәсем *4 нче рәсем*

сти дүрте дип уйлыйлар. Карталарны тезгә куеп, сугып тигезләгәч, пычакны акрын гына карталар эченнән алгач, аларны берәмләп күрсәтәсез. Кресті дүртенә берни дә булмаган.

Карталарның мастьлары юкка чыга

Тәэсире: артист тамашачыларга зур дүрт данә – кресті, буби, пики, черви мастьлы, биш санлы карталар күрсәтә (1 нче рәс.). Шулар арасыннан черви бишен алып өстәлгә куя да, черви тузын алып, колоданы каплый. Тамашачы-



1 нче рәсем *2 нче рәсем* *3 нче рәсем* *4 нче рәсем*



5 нче рәсем



6 нчы рәсем

ларга нинди карта алганын, куйганын күрсәтеп бара. Хәзер тамашачылар өч бишле һәм бер черви тузы дип уйлыйлар.

Артист карталарны җилпәзә итеп җәеп «өреп җибәрсә» алар барысы да тузга әйләнгәннәр (2 нче рәс.). Фокусчы черви тузын алып, күрсәтеп, өстәлгә куеп, рәсемсез буш карта ала. Аларны бергә куеп күрсәтә (3 нче рәс.). Алда буш карта. Артист кулындагы калган карталарны җәйсә өч картаның да мастьлары юкка чыккан (4 нче рәс.).

Реквизит: барлыгы алты карта, шунын өчесе серле.

Сере: зур карталар. Бер карта, әйтик, черви бише, бер карта черви тузы, бер карта буш – рәсемсез (5 нче рәс.). Ә калган өч картага барлыгы өч кенә масть ясалган (6 нчы рәс.). Калган өч картаның сере шул: аскы өлешендә икешәр масть юк. Оста итеп каплагач, алар җиңел генә тузга да, буш картага да әверелә. Өстә язылганча, күнегүләр ясасагыз, серенә тиз төшенерсез.

Картаның масте уч төбендә югала

Тәэсире: фокусчы буби сигезен күрсәтә. Тамашачылар аны гади карта итеп күрәләр. Артист берәмләп картадагы мастьларны учына сыпырып ала, алар «өреп» юкка чыгалар.

Картадагы дүрт масть югалып, сигезле урынына дүрт кенә масть кала. Соңгы мастьне алганда, масть кечкенә ефәк яулыкка әверелә (1 нче рәс.).

Реквизит: бер серле карта.

Сере: картадагы дүрт масть, шуып йөреп, бер-берне каплыйлар. Ә карта



1 нче рәсем



2 нче рәсем

эчендә газ яулык сыярлык бушлык бар, яулыкны шунда алдан ук тыгып куясыз. Яулыкны тартып чыгару өчен, бер читкә җепкә сәйләнбөртеге кидереп яулыкка тегәсез.

Картаның шуып йөрү рәвеше 2 нче рәсемдә күрсәтелә. Картаның мастьлары, тегелгән нечкә леска буйлап шуып йөреп, хәрәкәтсез торган мастьлар өстенә менә. Тамашачыларга сер күренми. Сигезле буби карта дүртлегә әверелә. Картаның артын бертөсле плёнка белән ябыштырырга онытмагыз. Ул лескаларны яшереп торыр.

Баулар белән фокуслар

Үзеннән-үзе төйнәлүче, чишелүче бау

Тәэсире: артистның кулында бер метр озынлыктагы кер бавы. Ул аны төрлечә күрсәтә, тарта, суза – бернинди дә сере юк. Сул кулының учына өч мәртәбә урап, кесәсеннән тылсымлы таяк алып кулына өч мәртәбә кагылып алгач, таягын кесәсенә тыгып, кулындагы бауны сүтә.

Бауда өч төен хасил булган. Төеннәр каты төйнәлгәнен исбат итеп, бауны берничә мәртәбә, көчле итеп тартып күрсәтә. Төенле бауны яңадан учына урап, кесәсеннән тылсымлы таягын алып, кире якка әйләндереп, өч мәртәбә бауга тиеп алып, таягын кесәсенә сала. Бауны акрын гына сүтә. Гаҗәеп хәл: баудагы өч төен дә юкка чыккан, үзлекләреннән чишелгәннәр (1, 2 нче рәс.).

Реквизит: бер метр озынлыктагы серле бау, тылсымлы таяк, эскәк (медицина пинцеты).



1 нче рәсем



2 нче рәсем

3 нче рәсем

4 нче рәсем

5 нче рәсем

Сере: бер метр кер бавы. Бауның бер очына ясалма өч төен кидерелә (3, 4 нче рәс.). Ул төеннәр бау буйлап җиңел генә шуып йөриләр. Артист, бауны күрсәткәндә, төеннәрне уң кулының учына җыеп тота. Тамашачы ул ясалма төеннәр барлыгын белми. Фокусчы бауны күрсәткәч, сул кулы белән уң кулы уч төбенә яшеренеп торган беренче төенне алып, учына урый. Икенче кат ураганда, уч төбеннән икенче төенне алып, сул кулына урап, соңгы төенне шул ысул белән сул кулының учына ала. Кесәсеннән тылсымлы таягын алып, өч мәртәбә «тылсымлагач», таягын кесәсенә салып, бауны сүтә. Бауның уртасында өч төен күренә. Төенле бауны тартып күрсәтә. Төеннәр чишелерлек түгел. Артист яңадан бауны сул кулының учына урый, шул вакытта төеннәрне берәмләп уң кулының учына җыеп бара. Кесәсеннән тылсымлы таягын алганда, аларны кесәсенә салып, таякны ала. Сул кулына уралган бау өстендә тылсымлы таягы белән серле хәрәкәтләр ясап, таякны кесәсенә тыккач, бауны сүтә — төеннәр юкка чыккан, кулда баудан башка бернәрсә дә юк.

Бу фокусны җиңел, оста башкарганда, бик әйбәт тәэсир калдыра. Тамашачының хәтта бернәрсәгә дә ышанмаучысы да аптырап, гаҗәпләнеп кала.

Төеннәрне ясауның сере бик гади. Шундый ук кер бавыннан берничә төен ясап алыгыз. Энә белән җеп алып, төеннәр сүтелмәсен өчен, очларын тегеп куегыз. Үзәк бау шуып йөрсен өчен, төен уртасы ачык кала (5 нче рәс.).

Төеннәрне бауга кертү өчен, эскәк (пинцет) кулланырга мөмкин.

Киселгән бау яңадан ялгана

Тәэсире: артистның кулында кер бавы. Ул, аны тамашачыларга күрсәтеп, сул кулы белән тотып, ике катлы түгәрәк ясый (1 нче рәс.). Кайчы алып, уртасыннан кисә. Бауның дүрт очы да күренә. Бауның сул кулында калган очларын төйни. Бау уртасындагы төенне тамашачы да күрә. Артист, бауны сул кулының учына урап, уң кулы белән кесәдән тылсымлы таягын алып, уралган бау өстендә серле хәрәкәт ясый. Таякны кесәсенә салып, бауны сүтә — төен юкка чыккан. Ә бау киселмәгән. Артист бауны тикшерергә бирә. Бернинди дә сере юк.



1 нче рәсем



2 нче рәсем



3 нче рәсем



4 нче рәсем

Реквизитлар: бер метр озынлыктагы кер бавы, үткен кайчы һәм тылсымлы таяк.

Сере һәм күрсәтү рәвеше: бауны ике катлы итеп ураганда, бер ягында элмәк ясалып кала. Тамашачылар аны белмәскә тиеш.

Бауны алып урталай бөкләгез. Бауның ике башын да сул кулга алып, баш бармак белән тотып, уртасын асылындырып калдырасыз. Уч төбе үзегезгә караган була. Тамашачылар бауны яхшылап күрергә тиеш (1 нче рәс.). Соңыннан бауның уртасыннан алып, баш бармак белән имән бармак арасына, уч төбенә куеп, очларын тотасыз (2 нче рәс.).

Тамашачыларны ышандыру өчен, шушы хәрәкәтне тагын бер мәртәбә кабатлагыз.

Өченче мәртәбә кабатлаганда, бауның уртасыннан алып, очы янына куегыз да баш һәм имән бармаклар белән кысыгыз (3 нче рәс.). Шушы вакытта бауның уртасын уң кулыгызның ике бармагы тартып ала. Шулай итеп, «хәйләкәр» элмәк ясала (4 нче рәс.).

Ул ялган элмәкне кайчы белән кискәч, кулыгызда бауның дүрт очы күренә. Сул кулдагы элмәкне уч төбендә калдырып, ике очын аска сузасыз (5 нче рәс.). Алар асылынып тора. Артист кулында урталай киселгән бау, дүрт очы да күренә. Сул кулыгызда калган ялган очларны элмәкләп ике кат



5 нче рәсем



6 нчы рәсем



7 нче рәсем

8 нче рәсем

9 нчы рәсем

төйнисез. Бау уртасы төйнәлеп, тамашачылар төенне күрәләр.

Төеннең яхшы төйнәлүен исбат итеп, тартып күрсәтәсез. Бауны сул кулның учына ураганда, ялган төенне шудырып барып, уң кул белән кесәдән тылсым таягын алганда, ялган төенне кесәгә салыгыз. Тылсымлы таяк белән серле хәрәкәт ясагач, таякны өстәлгә куеп, бауны сүтәсез — төен юкка чыккан!

1–8 нче рәсемнәрдә бауның йөреше, элмәк калдырып, ялган төен ясау рәвеше күрсәтелә.

Тылсымлы бау

Тәэсире: артистның кулында кер бавы. Ул аны кулына урап, төйнәп күрсәтә. Тамашачы гади кер бавы дип кабул итә (1 нче рәс.). Бауны учына урап торайткач, бау чыбык кебек катып кала (2 нче рәс.).



1 нче рәсем

Фокусчы бауны төрлечә боргалап, төрле фигуралар ясагач («Г» хәрефе, түгәрәк, куб кебек фигура-

лар), бау элекке хәленә кайта. Артист шуның белән чыгышын тәмамлый.

Реквизит: серле кер бавы.

Сере һәм күрсәтү: бу трюк өчен 50–55 см озынлыктагы түгәрәк киҗе-мамык кер бавы кирәк. Эчендәге җепләрне алып, бауның тышлыгы гына кала. Агачтан йә пластмассадан дистәләгән кечкенә цилиндрлар ясала. Озынлыгы 1,5–2 см, калынлыгы 0,1 см булып, бау эченнән шуып йөрерлек булырга тиеш (3 нче рәс.). Цилиндрларны тишеп, алар аша леска уздырыла (4 нче рәс.). Шушы гәрәбә кебек цилиндрларны, бау эченә керткәч, бау яңадан үз хәленә кайтып, түгәрәк булып күренә.

Бау эчендәге цилиндрлар бер-берсеннән читтәрәк булып, җиңел сыгылырга тиеш. Бауның очы леска белән бергә төйнәлеп, нык итеп тегелә. Ә икенче башына кечкенә ак сәдәп беркетелә. Ул цилиндрдан бераз зуррак, бау эченә кереп китәрлек булмасын.

Күрсәтү: артист бауның сәдәп беркетелгән башыннан алып, сул кулының чәнти бармагы белән кысып тотып, баш бармак белән имән бармагы цилиндрны тарта. Бау чыбык кебек төз тора (2 нче рәс.). «Г» хәрефен күрсәтү өчен, уң кул белән җиңелчә генә бөгеләсе җиргә кагылуга, ул бөгелә. Шулай итеп, теләгән фигураларны ясарга була.



2 нче рәсем

3 нче рәсем



4 нче рәсем

Су белән фокуслар

Буш кәсәләрдә су пәйда була

1 нче рәсем



2 нче рәсем



3 нче рәсем

4 нче рәсем

Тәэсире: артистның кулында буш кәсә. Ул аны яулык белән сөртеп өстәлгә куя. Икенче кәсәне алып, шулай ук яулык белән сөртеп, яулыгын өстәлгә куеп, беренче кәсәне ала. Кәсәләрне бер-берсенә каплап күрсәтә (1–2 нче рәс.), алар буш.

Кулындагы кәсәләрне җиңелчә хәрәкәт ясап чайкый. Тамашачыларга арты белән борылып, сәхнә түренә берничә адым атлый да кире борылып килә. Буш кәсәләрнең чайкалуы дәвам итә, кинәт беренче кәсәдән су чайкалып идәнгә түгелә. Артист, кәсәдәге суны эчеп, кәсәнең бушаганын күрсәтә.

Сул кулындагы икенче кәсәне түгәрәк хәрәкәт ясап чайкый башлый, ул кәсәдән дә су идәнгә түгелә. Артист икенче кәсәдән дә су эчеп, яңадан «тылсымлы» хәрәкәтләр ясап, сәхнә түренә уза да борылып сәхнә алдына килә. Кәсәләрдән су идәнгә сибелә. Икенче кәсәдәге суны да эчкәч, артист кәсәнең эчен дә күрсәтә. Кәсәләрне берсе эченә икенчесен тыгып, өстәлдәге подноска куеп, яулык белән каплый.

Реквизитлар: ике пластмасс кәсә (берсе – серле), поднос, яулык, шешә белән су.

Сере һәм күрсәтү: беренче кәсәнең сере бар (3 нче рәс.). Пластмасс кәсәгә үлчәп, өске кырыеннан 2 см калдырып, ялган төп әзерләргә кирәк. Юка ак пластиктан яки органик пыяладан түгәрәк кисеп, кырыйларын кәсәгә тыгыз ятарлык итеп шомарткач, 1 см түгәрәк киселә (4 нче рәс.). Булачак ялган

төпнең кырыйларына да, кәсәгә дә, пөхтә итеп БФ-88 жилеме сылап, бераз жилләткәч ябыштырырга була.

Ялган төпне ябыштыру өчен, иң яхшы жилем – эпоксид сумаласы. Ул ике составтан гыйбарәт. Ябыштыру ысулын техник паспортыннан укып белергә була. Яхшы, тыгыз ябышсын өчен, ялган төпкә авыр тимер кисәге куегыз. Жылы жирдә торып, бер тәүлек киптергәннән соң, кәсәгә су салып тикшерегез, жилем суны үткәрмәсә, тоташкан жирләрен ак эмаль буяуга буягыз.

Күрсәтү: тамаша башланганчы, артист серле кәсәгә су сала. Ул кәсәне икенче кәсә эченә салып, подноска куеп, яулык белән каплый. Артист чыгышын серле кәсәне алып, серле ягын өстә калдырып, яулык белән жиңелчә генә сөртеп, подноска куя. Икенче кәсәне алып, әйләндереп-әйләндереп, иркенләп сөртә. Тамашачы гади кәсәләр дип кабул итә.

Кәсәләрнең бушлыгын исбатлап, аларны бер-берсенә ян белән дә каплап күрсәтә (2 нче рәс.). Ә хәзер тәэсир өлешендә язылганча, күнегүләр уздырыгыз.

Кәсәләрдән су матур итеп сибелергә тиеш. Икенче кәсәгә суны, тамашачыларга артыгыз белән борылгач, серле кәсәдән саласыз. Суы ике мәртәбә кабатларга житсен өчен, кәсәне саклабрак чайкагыз. Күнегүләр вакытында уңайлы ысулын табарсыз.

1 нче рәсем

2 нче рәсем



3 нче рәсем



4 нче рәсем

Хәйләкәр стакан

Тәэсире: артист кәгазь стакан күрсәтә. Анда шикләнерлек сер юк. Сулы шешәдән кәгазь стаканга су сала. Өстәлдән берәмләп өч пычак алып, кәгазь стаканны, су салган җирен чамалап, пычаклар белән тишеп чыгып, пычакларны кадап калдыра (1 нче рәс.). Ике пычак ян-якларга кадала, өченчесе стакан төбен тишеп чыга. Гаҗәеп хәл: су түгелми. Пычакларны стаканнан берәмләп ала да стаканны яткызып күрсәтә. Су юкка чыккан.

Реквизитлар: серле стакан, өч озын тар пычак, шешә белән су.

Сере: стаканның икенче төбе бар. Ләкин ул бер ягыннан киселгән. Су салганда, шул киселгән җирдән су төпкә кадәр төшә. (Кәсәнең ялган төбе кебек.) Тик монда пычакларны тыгар өчен махсус тишекләр ясала.

Юка калайдан кәгазь стакан өлгесе ясап, башта калай стакан ясарга кирәк (2 нче рәс.). Калай стаканның як-якларына пычак сыярлык дүрт кырлы торбачыклар паяльник белән эретеп ябыштырыла (3 нче рәс.). Башта калай стаканны эретеп ябыштырасыз. Пычаклар керәсе тишекләрне пөхтәләп әзерләгәннән соң, торбачыкларны кертеп, эчке һәм тышкы яктан кургаш эретеп ябыштырасыз. Артык җирен наждак белән шомартыгыз. Стаканның төбендә дә шулай яссы торбачык беркетелә (4 нче рәс.).

Серле стакан ясалып беткәч, кәгазь стаканны (кока-кола, пепси-кола) сүтеп, БФ-88 җилеме белән тышлап ябыштырасыз. Стаканның эчке ягын ак эмаль буяу белән буйыйсыз.

Күрсәтү: тәэсир өлешендә язылганча башкарыла.

Тере су

Тәэсире: артист газета алып, аны төрле яклап күрсәтә дә кулёк ясый (1 нче рәс.). Өстәлдән бер стакан ала, тамашачыларга күрсәтеп, кулёкка тыга. Кулёк эченнән стаканны алып, өстәлгә куя. Шешә белән су алып, аны серле итеп күрсәтеп, кулёкка су сала. Кулёк эчендәге су түгелми.

Өстәлдәге стаканны алып, кулёк эчендәге суга сала да кулы белән «тылсымлы» хәрәкәтләр ясый. Кулёк эченнән стаканны алса, кулёкка салган су стакан эченә күчкән.

Сул кулы белән кулёкны чишеп җибәрсә, кәгазь коры, ә суы стаканга үзлегеннән күчкән. Фокус шуның белән тәмамлана.

1 нче рәсем

Реквизитлар: газета, серле ике стакан, шешә белән су.

Сере һәм күрсәтү: органик пыяладан (пластмассадан) ясалган ике стакан. Алар бер-берсе эченә бик тыгыз һәм шул ук вакытта җиңел керергә тиеш. Өске (беренче) стаканның төбен 5–6 урыннан тишәсез. Икенче стаканның өске кырыена төсле изолента (кызыл, сары) ябыштырыла (2 нче рәс.). Тамашачы бер генә стаканны күрә. Стаканнарны бер-берсенә кидерсәң, бер генә стакан булып күренә.

2 нче рәсем

Күрсәтү: артист, кулёк ясагач, ике стаканны да кулёкка сала. Тамашачыларга кулёк эчендәге стаканны күрсәтә дә өске тишекле стаканны алып өстәлгә куя. Кулёкны астын өскә әйләндереп күрсәтә, шул вакытта кулёк эчендәге стаканны сиздермичә, җиңелчә генә кысып тота. Өстәлдә торучы шешәдән кулёкка су алып сала. Кулёктан су акмый. Шешәне өстәлгә куеп, тишекле стаканны кулёктагы сулы стакан эченә сала. Кулёк өстендә «тылсымлы» хәрәкәтләр ясагач, уң кулы белән сулы стаканны ала, ә сул кулы шул вакытта кулёкны селкеп җибәрә. Стаканга «пута» ясау өчен изолента, яки алтын төсендәге, үзе ябыша торган плёнканы алырга була, затлы стакан булып күренер. Ул пута икенче стаканның өске кырыен яшерер өчен кирәк.

Кәгазьдән акча ясау

Кәгазьдән акча ясауның беренче ысулы

Тәэсире: артист каләм сыярлык кечкенә торба күрсәтә. Өстәлдән каләм алып, аны җиңел генә торба аша уздыра (1 нче рәс.). Торбаны өстәлгә куеп, акча зурлыгында ак кәгазь алып, каләменә урый да, акрын гына боргалап, торба аша чыгара.

1 нче рәсем

Торбаның икенче башыннан каләм белән әле генә бөтереп тыккан кәгазьне ала. Торбаны, тагын күрсәтеп, өстәлгә куя. Каләмне, кәгазь торба эченнән алып, өстәлгә куя. Кулындагы кәгазь кисәген акрын гына сүтә, ул йөз сумлык акчага әверелгән.

Реквизитлар: калынлыгы 12–13 мм, озынлыгы 150 мм булган, матур итеп бизәлгән кәгазь торба, кечкенә фокусчы таягы (каләм), акча зурлыгында ак кәгазь һәм йөз сумлык акча.

2 нче рәсем

Сере һәм күрсәтү: йөз сумлык акчага лескага эленгән сәйлән бөртеген үтә күренмәле плёнка-скотч белән ябыштырасыз (2 нче рәс.). Акчаны каләмгә урап (чыгыш алдыннан), торба эченә кертеп, сәйлән бөртеген аз гына күренерлек итеп калдырасыз (3 нче рәс.)



3 нче рәсем

Ак кәгазь кисәген каләмгә урап, таякның буш башыннан сак кына кертеп, каләмне торба аша чыгарганда, сәйлән бөртеге белән бергә акчаны тартып чыгарасыз. Ак кәгазь торбаның өске өлешендә кала. Торбаны, өстә язылганча күрсәтеп, өстәлгә куясыз да, бик кәефләнеп, йөз сумлык акчаны сүтәсез.

Кәгазьдән акча ясауның икенче ысулы

Тәэсире: артистның кулында газетадан кисеп алынган тасма (1 нче рәс.). Ул аны төрлечә сыпырып күрсәтә дә ерткалап ташлый. Соңгы кисәген учында угалагач, кәгазь кисәген җәйсә, ул акчага әверелгән.

Реквизитлар: газетадан 5 см киңлектәге, 30–35 см озынлыктагы тасма һәм йөз сум акча.

Сере һәм күрсәтү: тасма-газетаның сул кул белән тота торган башында «конверт-кесә» сыман сер бар. Акчаны шул кесә эченә алдан ук сүтәргә уңайлы итеп бөкләп салырга кирәк (1 нче рәс.)

Тасманы әзерләгәч, бер башын бөгеп, җилем белән ябыштырып, рәсемдәгечә, «конверт-кесә» ясала. Акча, рәсемдәгечә бөкләп, шул кесәгә салына. Акча кесәдән күренмәскә тиеш. Сул кул кесәне һәрвакыт каплап тора.

Акчаны гармун кебек итеп төрегез, сүтәргә җиңел булыр (2 нче рәс.).



1 нче рәсем



2 нче рәсем

Янган газета кисәге акчага әверелә

Тәэсире: артист, ертып ташлаган кәгазь тасманың бер зур кисәген алып, тамашачыга күрсәткәч, өстәлдән шырпы кабы алып, кәгазь кисәгенә ут кабыза. Шырпы кабын өстәлгә куеп, яна торган кәгазьнең көлен ике куллап учына җыеп бара да көлгә өрә. Артист кулындагы көл йөз сумлык акчага әверелә.

Реквизитлар: кәгазь тасманың ярты өлеше, йөз сум акча, шырпы кабы.

Сере һәм күрсәтү: идәннән алган кәгазь тасма кисәген алып, аны яхшылап күрсәткәч, шырпы кабы аласыз. Шырпы кабы ярым ачык була. Шырпы кабының буш урынына акчаны «гармошка» итеп тыгасыз. Шырпы кабыннан шырпы алгач, тартмасын ябып, акчаны артка этәреп чыгарасыз да уч төбендә яшереп калдырасыз. Кәгазьгә ут кабызып, шырпыны өстәлгә ташлагач, ике куллап

яна торган кәгазьне тотасыз, көлен учка җыйган кебек тәэсирлисез. Кул пешмәсен өчен, утка җиңелчә генә өргәләп, көлне тарата барып, соңгы кисәген идәнгә ташлап, сүндерү өчен өстенә баскач, уч төбендәге акчаны сүтәсез һәм төрле яклап күрсәтәсез. Бераз мактанып: «Менә шулай кәгазь кисәкләреннән тиз генә акча ясыйм. Хәзер инде сез дә өйрәнгәнсездер?!» – дип, чыгышыгызны тәмамлыйсыз.

Микромагия

1 нче рәсем

2 нче рәсем

Кечкенә реквизитлар ярдәмендә фокуслар күрсәтү микромагия дип атала.

Тегүчеләр бармакларына кия торган уймакны фокусчы, үзгәртеп, үзенә яраклы реквизитка әвереллергән: аны озынайтып, ясалма бармак ясаган (1 нче рәс.).

Ясалма бармак баш бармакка иркен керергә тиеш. Чөнки аның эченә юка ефәк яулыкны яшереп, баш бармакка киясе була (2 нче рәс.). Андый бармакларны үзегез дә ясый аласыз. Әйтик, папье-машедан. Папье-маше дип кәгазьләр, чүпрәкләр ябыштырып эшләнгән театр реквизитларына әйтәләр.

Иң элек агачны юнып, үзегезнең баш бармакка охшатып, бераз зурайтып, бармак-калып ясыйсыз. Аңа вазелин сөртеп, вак кәгазь, ак чүпрәк кисәкләрен ПВА-М (кәгазь өчен) җилеменә манып, агач калып бармакка алты-сигез кат ябыштырып киптерәсез.

Папье-маше бармак кипкәч, агач калыптан салдырып, наждак белән шомартып, эчен, тышын кул төсенә кертеп, майлы буяу белән берничә кат буйыйсыз.

Агач калыпка вазелин сөртсәң, кипкән папье-маше ватылмыйча төшәр. Мөмкинлеге булганнар ясалма бармакны Мәскәүдә, Санкт-Петербург шәһәрләрендә фокуслар күрсәтә торган реквизитлар сата торган кибетләрдән кайтарта ала.

Ясалма бармакны ясау серләрен өйрәндек, инде эшкә тотыныйк.

Ясалма бармак белән фокуслар

Тәэсире: артист кесәсеннән кечкенә кәгазь кисәге ала. Сере юкны исбатлап, аны төрле яклап күрсәткәч, баш бармагына урап торба ясый. Кәгазь торба өстендә «тылсымлы» хәрәкәт ясагач, әкрен генә торба эченнән ефәк (эксцельсиор) кызыл яулык чыгара. Осталыгын күрсәтеп, яулыкны һавага чөя. Шул вакытта кәгазь кисәген кесәсенә сала. Яулыкны тотып алып, сул кулының очына ашыкмыйча җыя да, йодрыклап, тамашачыларга күрсәтеп тота.

Уң кулы белән пиджак кесәсеннән кечкенә тылсымлы таяк алып, яулыкны тоткан сул кул өстендә, «тылсымлы» хәрәкәт ясап, йодрыгын ача. Бармакларын җәеп, кулының ике ягын да күрсәтә. Яулык юкка чыккан.

Реквизитлар: ясалма бармак, 7x10 см зурлыгында кечкенә кәгазь (4 нче рәс.), зурлыгы ясалма бармакка сыярлык ефәк (эксцельсиор) кызыл яулык, кечкенә тылсымлы таяк.

Сере: уң кулыгыз белән пиджак кесәсеннән кәгазь кисәген алганда, яулык тыгылган ясалма бармакны баш бармагыгызга киеп, кәгазь кисәге белән бергә кесәдән аласыз. Кәгазьне төрле яклап күрсәткәндә, серле баш бармак һәрвакыт артта кәгазьгә капланып кала (3, 4 нче рәс.). Кәгазьне серле баш бармакка урыйсыз да, ясалма бармакны кәгазь торба эчендә калдырып, «тылсымлы» хәрәкәт ясап, яулыкны, кәгазь эченә төрелгән ясалма бармактан, ашыкмыйча, тәэсирле итеп, тартып чыгарасыз (5 нче рәс.). Та-



1 нче рәсем

2 нче рәсем

3 нче рәсем

4 нче рәсем

5 нче рәсем

машачыларның игътибарын җәлеп итеп, яулыкны һавага чөясез.

Шул вакытта ясалма бармакны кәгазь кисәге белән бергә кесәгә саласыз.

Уч төбеннән яулыкның югалуы



1 нче рәсем

Тәэсире: әле генә күрсәткән фокусны дәвам итеп, һавага чөелгән яулыкны тотып алып, ашыкмыйча, пөхтә итеп, сул кулыгызның учына җыясыз. Уң кулыгыз белән пиджак кесәсеннән тылсымлы таякны алып, сул кулдагы кызыл яулык өстендә «тылсымлы» хәрәкәтләр ясыйсыз. Учны ачып, бармакларны җәеп күрсәтәсез, яулык юкка чыккан (манипуляция). Ике кулыгызны да күрсәтеп, баш иеп, шул ук трюкны дәвам итәсез.

Артист өстәлдән 20х30 см зурлыкта ак кәгазь ала. Аны төрле яклап күрсәтеп, кулёк-фунтик ясап, сүтелмәсен өчен, очын бөкләп куя (1, 2 нче рәс.). Тылсымлы таягын алып, аңа кулёкны кидерә дә, бераз бөтереп уйнагач, кулёкны сул кулына алып, таякны да сул кулының култык астына кыстыра. Ашыкмыйча, серле итеп кулёк эченнән югалган кызыл яулыкны ала.

2 нче рәсем

Яңадан таякны кулёк эченә тыгып, кулёкны бөтереп алгач, таякны кесәсенә сала.

Кулёкны бөтенләй үк сүтеп, тамашачыларга төрле яклап күрсәтә. Бернинди дә сер юк. Тамашачыларга кәгазьне карарга бирә.

Реквизитлар: 20х30 см зурлыгында ак кәгазь, икенче тылсымлы таяк, «игезәк» кызыл яулыкның берсе.

Сере: трюк вакытында һавага чөелгән яулыкны тотып алып, сул кулның уч төбенә акрын гына җыясыз. Ул шар формасын хәтерләтә. Ялган хәрәкәт ясап, янәсе, сул кулда яулыкны калдырып, ә чынбарлыкта төрелгән кызыл яулыкны уң кулның уч төбенә яшерәсез. Тиз генә пиджак кесәсенә яулыкны салып, таякны аласыз, яулыкны таякка алыштырасыз. Тамашачылар фокусчы кулын кесәсеннән таягын алырга тыкты дип хис итә.

Ә сул кул һәрвакытта йодрыкланган килеш тамашачыларга күренеп тора. Тылсымлы таяк белән сул кул өстендә «тылсымлы» хәрәкәтләр ясыйсыз, аз гына сулыш алып, тамашачыларга карап алгач, учыгызны ачасыз. Яулык юкка чыккан.

Буш фунтикка яулык ничек барып кергән

Тылсымлы таяк ясарга кирәк. 2 см калынлыктагы (катыргыдан, ватман кәгазеннән, полиэтилен) торбаны, 25 см озынлыкта кисеп алып, яхшылап шомартасыз.

Ике башына да бер үк зурлыкта агач бөкеләр ясыйсыз (1 нче рәс.). Алар торба белән бер калынлыкта булырга тиеш. Таякны кара төскә буяп, алтын төсендәге, үзе ябыша торган плёнка белән бизәргә кирәк.

Бер бөкегә 10–12 см озынлыгында антенна кебек тимерчыбыкны беркетәсез (2 нче рәс.).

Искәрмә: таякны буяу бик җиңел. Үзе ябыша торган кара төсле плёнка алып, кирәк кадәр кисеп ябыштырасыз. Таяк башындагы бөкеләр күзгә ташланмасын өчен юка итеп эшләнергә тиеш.

Кулёк-фунтикны җиңел генә ясарга өйрәнгәч, күнегүләргә күчәбез. Хәзер тылсымлы таякның серен беләсез инде.



1 нче рәсем *2 нче рәсем* *3 нче рәсем* *4 нче рәсем*

Сере: чыгыш ясарга әзерләнгәндә, таякны алдан ук әзерләп куясыз. Ягъни бөкедәге «антенна»га икенче кызыл яулыкны урап, таяк эченә тыгасыз. Яулыкны бөкегә (антеннага) уратсаң, чыгыш вакытында торба эчендә калуы мөмкин. Шуның өчен яулыкны ничек итеп «антенна»га урау ысулын эзләгез (3 нче рәс.).

Чыгыш тәэсире: кулёкны ясагач, аны тылсымлы таякка элеп әйләндергәч, сул кулга кулёкны алып, тышкы яктан таякның бөкесеннән тотып, таякны алып, култык астына кыстыргач, кулёк эченнән югалган кызыл төсле яулыкны аласыз да күккә чөясез. (4 нче рәс.)

Яулыкны тотып, таякны кулёкка тыгасыз, шул вакытта антенналы бөкене яңадан таякка кидерәсез. Хәзер таяк элекке хәленә килә. Кулёкны сүтеп тамашачыларга күрсәтәсез.

Шырпы кабы белән «микромагия»

Кечкенә аудиториядә, ял иткәндә дачада, дусларга шырпы белән күп кенә кызыклы фокуслар күрсәтергә була.

1 нче трюк. **Шырпылар, борылыгыз!**

Гади шырпы кабыннан ике шырпы аласыз. Учыгызга салып, сере юклы-

1 нче рәсем



2 нче рәсем



3 нче рәсем

гын күрсәтәсез. Сул кулыгызны йодрыклап, аңа беренче шырпыны күкертле башын өстә калдырып, уң кулыгыз белән этеп төшерәсез (1 нче рәс.).

Уң кулыгызны йодрыклап, аңа икенче шырпыны күкертле башы белән сул кулыгыз этеп төшерә.

Артист ике йодрыгын да бер-берсенә сугып ала да: «Шырпылар, минем сүзне тыңлагыз, икегез дә бер якка борылыгыз!» – дип, учларын ача. Ике шырпы да бер якка борылганнар (3 нче рәс.).

Сере: бу – бик гади фокус, әгәр осталык белән күрсәтсәң, яхшы гына тәэсир калдыра. Өстә язылганнарны дикъкать белән укып, шул хәрәкәтләрне кабатларга гына кала.

2 нче трюк. **Шырпылар, аерылыгыз!**

Шырпылар белән фокус күрсәтүне дәвам итеп, шырпыларны кабына саласыз да, икенче трюк исегезгә төшә.

Тәэсире: яңадан ике шырпы аласыз, баш бармак белән имән бармак аларны тотып тора (4 нче рәс.). «Шырпылар, бер-берегездән аерылыгыз!» – дип, боерык бирүгә, шырпылар ике якка аерылалар. Шырпыларны яңадан бергә куеп, трюкны берничә мәртәбә кабатлап күрсәтергә мөмкин. Сере гади булса да, тамашачыга яхшы тәэсир калдыра. Шырпыларны кабына саласыз.

Реквизитлар: шырпының күкертле башлары зуррак булган ике шырпы, 2 см озынлыгында резин нипель.



4 нче рәсем



5 нче рәсем

Сере: зур башлы (күкертле) ике шырпы сайлап аласыз. 2 см озынлыгында резин нипель кисеп алып, ике шырпыны беркетәсез. (Резин торбаны велосипедларның тәгәрмәченә һава тотар өчен нипельгә кидереп куялар. Нипель урынына теләсә нинди җиңел бөгелә торган шырпы сыярлык торба (шланг) булса да ярый.) (5 нче рәс.)

Шырпы кабыннан, алдан әзерләнгән ике шырпыны алып, баш бармак белән имән бармак арасына куясыз. Бармаклар нипельне каплап тора (4 нче рәс.). Тамашачылар гади ике шырпыны бармак арасына кысылып тора дип күрәләр.

Фокусчы, ике серле шырпыны янәшә тотып: «Тыңлагыз, минем боерыкны. Шырпылар, аерылыгыз!» – дип, боерык бирә. Бармакларны бушайткач, шырпыларны резин шланг (нипель) турайта. Күз алдында шырпылар хәрәкәткә киләләр.

Көзге каршында яхшылап күнегүләр уздырсагыз, фокус уңышлы тәэсир калдырыр. Фокус тәмамлангач, серле шырпыларны, сиздермичә, кесәгә саласыз.

3 нче трюк. **Шырпы биетү.**

Тәэсире: фокусчының кулында ике шырпы ята. Ул бер шырпыны, уң кулына алып, баш бармагы белән имән бармагы арасында кысып тотып, күкертле башы белән урта бармак тырнагына куя (5 нче рәс.).

Сул кулындагы шырпының бер башын баш бармагына куеп, күкертле башын уң кулындагы шырпы өстенә куя. «Шырпылар, биегез!» – дип, боерык бирүгә, сул кулдагы шырпы уң кулдагы шырпы өстендә сикерә (бии)

6 нчы рәсем



7 нче рәсем

башлый.

Сере: шырпы кабыннан ике шырпы аласыз. Беренче шырпыны баш бармак белән имән бармакны кысып тотып, урта бармакның тырнагына кырлы ягы белән тыгызлап кысасыз (6 нчы рәс.). Беренче шырпыны, ул кулның урта бармак тырнагында, күзгә күренмәслек хәрәкәт ясагач (ышкыгач), шырпы тырнакка ышкылып дерелди башлый. Уң кулдагы беренче шырпы өстенә икенче шырпыны куйгач, ул да селкенә.

Икенче шырпының бер башын сул кулның баш бармагына иреклe куясыз, ә күкертле башын уң кулдагы шырпы өстенә саласыз (7 нче рәс.). «Шырпылар, биегез!» – дип, боерык биргәч, уң кулдагы беренче шырпыны бик сак кына селкетә башлыйсыз. Гаҗәп хәл: икенче шырпы да үзлегеннән сикерә, дерелди башлый.

Бу трюкны яхшылап өйрәнгәч, курыкмыйча, берничә мәртәбә кабатларга була.

4 нче трюк. **Шырпы, үр-рә-ә кат!**

Тәэсире: артист шырпы кабыннан бер шырпы алып тамашачыларга күрсәтә. Шырпы кабын учына тигез итеп яткырып куя да шуның өстенә шырпыны бастыра. Шырпы төз басып тора. Артист, кулын күтәреп, шырпыга сак кына өрә, шырпы ава (8 нчы рәс.).

Реквизитлар: серле шырпы кабы, нечкә тимерчыбык, калай, магнит кисәге.

Сере: шырпы кабы төбенә магнит кисәге салып, өстенә шырпы куела



8 нче рәсем



9 нчы рәсем



10 нчы рәсем

(9 нчы рәс.). Басып торасы шырпы бераз юанрак булып, күкертсез башына нечкә тимерчыбык кертелә. Тимерчыбык башына кечкенә юка калайдан паяльник белән дүрт кырлы «тәңкә» эретеп ябыштырыла (10 нчы рәс.).

Шырпы кабының көчле магнитлы ягын, өскә калдырып, учка куясыз (8 нче рәс.). Шырпыны күрсәтеп, шырпы кабы өстенә куеп, «Шырпы, үр-рә-ә кат!» – дип боерасыз. Шырпы боерыкны тыңлап басып тора.



11 нче рәсем

5 нче трюк. **Шырпы кабы, үр-рә-ә бас!**

Тәэсире: гади шырпы кабын төрле яклап, ачып-ябып күрсәткәч, уң кулыгызның (сул кулга да мөмкин) аркасына ипләп кенә шырпы кабын куясыз.

«Шырпы кабы, үр-рә-ә бас!» – дип, боерык биргәч, шырпы кабы үзлегеннән кулның аркасына торып баса. (11 нче рәс.) «Ә хәзер ял ит, ят!» – дигәч, шырпы кабы акрын гына кул аркасына ята. Трюк тәмамлангач, кул белән шырпы кабын төрле яклап күрсәтәсез, анда бернинди дә сер юк.

Реквизитлар: каты яңа шырпы кабы кирәк булачак.

Сере: шырпы кабын ачып-ябып күрсәткәч, шырпылы ягын, бераз ачык калдырып, кул аркасындагы тирегә кыстырасыз (11 нче рәс.). Тамашачы-

лар шырпы кабы кысылганны күрмәскә тиешләр. Фокусчы кул аркасындагы тирене, сизелмәслек итеп, акрын гына тарттыра. Тире астындагы мускулларның күзгә күренмәслек хәрәкәте шырпы кабын «үрә» бастыра.

Башта шырпы кабын, кул аркасының уңайлы җиренә кыстырырга, акрын гына хәрәкәт итәргә күнектерергә кирәк. Бармакларны бөкләмичә, төз калдырып, шырпы кабын бастыру, шулай ук яңадан мускулларны бушатып яткыру өчен күп кабатларга кирәк. Тырышканда, бу трюк, һичшиксез, дикъкатьсез калмас, тамашачыларны кызыксындырыр.

Шырпы кабы уч төбендә мәтәлчек ата



1 нче рәсем

Тәэсире: фокус күрсәтүче шырпы кабын ачып-ябып күрсәтә. Тамашачыларга карарга бирә. Аннан соң капны алып сул кулының учына сала. Шырпы кабы өстендә тылсымлы хәрәкәтләр ясагач, кап үзлегеннән торып баса да, мәтәлчек атып, яңадан урынына ята. Артист шырпы кабын, учыннан алып, яңадан тамашачыларга карарга бирә. Бернинди дә серен тапмыйлар.

Реквизитлар: гади шырпы кабы, кармак җебе белән резинкадан ясалган тарту җайланмасы (1 нче рәс.).



2 нче рәсем

Сере: артист шырпы кабын алып, ачып-ябып күрсәтә. Аны тикшерергә тамашачыларга бирә. Аларның дикъкате шырпы кабында булудан файдаланып, фокусчы сул кулының җиң эченнән нечкә кармак җебенә кечкенә гәрәбә тагыл-

ган тарту җайланмасын тартып чыгарып (3 нче рәс.), сул кул аркасы аша уздырып, гәрәбәне урта бармак белән атсыз бармак арасына уч төбенә кыстыра.

Тикшергәннән соң, шырпы кабын бераз ачык калдырып, гәрәбәле лесканы шырпы кабына тыгып яба да капны кармак җебенә бер мәртәбә уратып ала. Бу хәрәкәтләр җиңел булырга, шик тудырмаска тиеш.

Артист шырпылы кулын алга сузгач, кармак җебе тартыла, аңа чорналган кап сикереп торып, кармак җебен бушайткач, яңадан урынына ята. Тамаша тәмамлангач, артист, шырпы кабын кесәсенә салганда, капны ача, кармак җебе белән гәрәбә яңадан җиң эченә кереп китә.



3 нче рәсем

Шырпы кабы астында тәңкә юкка чыга

Тәэсире: артист кесәсеннән бер карта алып, төрле яклап күрсәтә дә шырпы кабы чыгара. Ике шырпыны янәшә, 2–3 см ара калдырып, өстәлгә куя. Ике шырпы уртасына тәңкә сала. Шырпы кабының капкачын ачып, каптагы шырпыларны күрсәткәч, өстәлдә ике шырпы өстенә салынган карта өстенә куя. Тылсымлы таягы белән тиеп алып, әле генә ясалган «пирамиданы» сүтә башлый. Иң элек шырпы кабының капкачын алып күрсәтә. Аның бернинди дә сере юк. Шырпылы тартманы карта белән бергә күтәрә дә картаны яңадан шырпылар өстенә куя.

Шырпылы тартманы каплавычына кидереп янәшә куеп, картаны күтәрә. Ике шырпы арасындагы тәңкә юкка чыккан (1 нче рәс.).

Реквизитлар: шырпы кабы, магнит кисәге, бер карта һәм тәңкә (1 нче рәс.).

Сере: шырпы кабына шырпылар астына магнит кисәге ябыштырыла. Магнитны яшерер өчен, аның өстенә шырпыларны пөхтә итеп «Универсальный» җилеме белән ябыштырасыз. Берничә шырпы ябышмаган була. Шулардан



1 нче рәсем



2 нче рәсем



3 нче рәсем

ике данә алып янәшә куясыз (1 нче рәс.). Магнитка ябыша торган тәңкә (10 тиен) алып, аны ике шырпы арасына куеп, карта белән каплыйсыз. Шырпы тартмасын, өске кабыннан чыгарып, карта өстенә куясыз. Магнит карта аша тәңкәне үзенә ябыштыра. Серлерәк булсын өчен, шырпылы тартма өстенә аның капкачын да куясыз (2 нче рәс.). Тылсымлы таяк белән пасс ясап, пирамиданы сүтәсез.

Капның буш өстен күрсәтеп өстәлгә куйгач, шырпылы тартманы карта белән бергә аз гына күтәрәсез. Тәңкә магнитлы тартма астына ябыша (3 нче рәс.).

Картаны яңадан ике шырпы өстенә куясыз. Магнитлы тартмага ябышкан тәңкәне аста калдырып капкачын кидерәсез. Шырпы кабы эченә магнит яшерелгәнне тамашачылар белмәскә тиеш. Шырпы кабын, картаны төрле яклап күрсәтәсез. Тәңкә юкка чыккан. Шырпы кабын кесәгезгә саласыз.

Менталь магия

Ментализм сүзе, латин сүзеннән алынып, башка телләргә тәрҗемәсез дә киң таралган. Ул фикер йөртү көче, игътибарны туплау, искә төшерү, серле, рухлы дигәнне аңлата.

Ментализм күз буу сәнгатенең бер төре булып, истә тотуны, хәтер үстерүне, психологиянең кирәкле өлкәләрен белүне файдаланып, бик мавыктыргыч тәэсир калдырырга мөмкинлек бирә. Ментализм – хорафатка ышануга, дини, идеалистик карашларга каршы көчле корал.

Фокусчы үзе эшеннән кала, фәнне дә яхшы белеп, оккультизмны фән аша аңларга, белергә тиеш.

Ментализмның формасы һәм аны күрсәтү мөмкинлекләре күп. Тамашачы концертта никадәр гаҗәпләнсә дә, соңыннан дөньяда могҗиза, гадәттән тыш көч бар дип ышанмасын өчен, чыгышны җиңелчә, шаярып алып барырга кирәк.

Менталь номерларны күңел ачу программасында күрсәтү авыр. Чөнки тамашачыларның дикъкатен җәлеп итү кыенлаша.

Менталь техниканың таянычы – кешенең баш мие, сизү органнары, тиз фикер йөртүе – теләсә нинди көтелмәгән очрактан да җиңеп чыгарга ярдәм итүе.

Менталь техниканың күз буунын башка техникаларына караганда өстенлекләре зуррак. Аңа озак күнегү ясап тору кирәкми, реквизитлар кечкенә генә сумкага да сыя. Шуңа күрә дә менталь магияне теләсә кайда – өстәл артында, кунаклар салонында, сәхнәдә һәм башка җирләрдә дә кулланырга мөмкин.

Менталь чыгыш – гаҗәеп тәэсир калдыра торган нәрсә. Тамашачының артистка карата мөнәсәбәте күз алдында үзгәрә, хөрмәте арта.

Менталь магиядә ***нәрсә*** күрсәтүгә караганда, аны ***ничек*** аңлату мөһимрәк.

Исегездә тотыгыз!

– Купшы реквизитлар алмагыз, әзерләмәгез.

– Чыгышларыгыз импровизация шикелле булырга тиеш.

– Уңышсызлыклар килеп чыкса: «Тамашачы фикерен туплый алмады», – дип акланырга була, тамашачылар чынлап торып ышанырлар.

– Катлаулы трюклар күрсәтергә ашыкмагыз, барысы да тәҗрибә белән килә.

Кагыйдә

1. Менталь магия чыгышы ясаганда, кеше кесәсендәге, сумкасындагы, өендәге гади әйберләрне кулланыгыз. Әзер реквизитны тамашачылар күрергә дә, белергә дә тиеш түгел.

2. Кулыгызның оста хәрәкәтләнүе тамашачыда шик уятмасын.

3. Менталь магиядә бер генә алмаштыру ысулын куллану яхшы булыр, шик тудырмас. Ә күз буу сәнгатендә, киресенчә, алмашынулар күп булуы мөһим.

4. Чыгышыгызда катнашучы тамашачыга командир булып, аңа төрле күрсәтмәләр бирергә тартынмагыз, сәхнәдә хуҗа булыгыз.

5. Сәхнәдә үзегезне иркен, инсафлы тотып, төгәл сөйләшергә өйрәнегез. Сөйлисе сүзләрне яхшылап ятлагыз, шулай да тамашачы аны табигый кабул итәрлек булсын.

6. Күз карашы белән сүзне, җөмләне укырга өйрәнегез.

7. Тамашачыдан мөмкин кадәр күбрәк белешмә алырга омтылыгыз.

8. Тамашачыларчың игътибарын киметү өчен, кулларыгызны серле итеп хәрәкәтләндерергә, ымларга, мимика белән эшләргә өйрәнегез.

Мнемотехника турында кыскача аңлатма

Мнемотехника – ментализмның иң катлаулы төре. Шуңа да менталист югары интеллектлы, культуралы булырга тиеш, сөйләме дефектсыз булу зарур. Мнемотехниканы ике кеше башкара. Бигрәк тә ир-ат белән хатын-кыз чыгышы күркәм була. Менталистлар чыгышыннан соң тамашачыда гадәттән тыш көчкә, гыйлемгә ия булган кеше тәэсире кала.

Тамашачылар могҗиза юклыгын белсә дә, артистлар читтән торып та уйларын, фикерләрен бер-берсенә җибәрә, хәбәр итә ала дип ышаналар.

Мнемотехника сәнгате турында кечкенә аңлатманы тәмамлап, менталь магия серләренә күчик.

Тамашачының уен белү

Тәэсире: артист-менталист, бер карта колодасы алып бутый да тамашачылар арасыннан чыккан ярдәмчесенә бер картаны алырга куша. Ярдәмчесе, картаның ниндилеген истә калдырып, тамашачыларга да күрсәтеп, масть ягын аста калдырып, өстәлгә куя. Артист бу вакытта арты белән борылып тора.

Борылырга рөхсәт булгач, ярдәмгә чыккан тамашачы янына килеп, кулыннан ала, күзләренә карап, нинди карта алуы турында фикерен тупларга куша.

Артист:

– Уйлагыз, уйла! Өстәлдә ята торган картаның төсен исегезгә төшерегез!

Тамашачы уйланып, артистка карап тора.

Артист:

– Дөрес уйлыйсыз. Карта кызыл төстә. Ул нинди мастьта?

Тамашачы сүзсез уйлый. Артист:

– Дөрес уйлыйсыз, карта буби мастенда. Ашыкмагыз! Ә хәзер уйлагыз, исегезгә төшерегез! Нинди карта?

Тамашачы уйлый. Артист, шатланып:

– Бик дөрес, карта саны буби уны. Ә хәзер өстәлдән картаны алып, тамашачыларга күрсәтегез!

Тамашачы картаны, өстәлдән алып үзе карагач, залда утыручыларга да күрсәтә. Артист ярдәмчесенә, рәхмәт әйтеп, сәхнәдән озата.

Реквизитлар: бер үк мастьтагы (әйтик, буби) 10–15 карта, башка төрле бер карта (әйтик, пики дамасы).

Сере: 10–15 карта бер мастьта булып, шул кечкенә колоданың астына пики дамасын куясыз. Колоданы бутаганда, тамашачыга пики даманы күрсәтеп алып гел аста калдырасыз. Карталарны җилпәзә итеп җәеп, пики дамасын сул якта, колода астында калдырып, тамашачыга колода уртасыннан теләсә кайсы картаны алырга тәкъдим итәсез.

Билгеле инде, бөтен карталар да буби уны булгач, тамашачыга буби картасын күрсәтеп, истә калдырып, өстәлгә куя. Артист-менталист серле кыяфәттә, тамашачыны үзенә буйсындырып, сөйләштермичә уйларга куша һәм «менталь магия» тамашасы күрсәтә.

Кул бармаклары белән төсләрне белү

Тәэсире: артист-менталист төрле төстәге биш катыргы кисәге күрсәтә: ак, кызыл, сары, яшел, зәңгәр. Залдан бер тамашачыны чакырып, ярдәм итүен сорый. Аңа квадрат формасындагы төрле төсле катыргы кисәкләрен күрсәтеп, конверт эченә сала.

Тамашачы бернинди дә сер тапмый, конвертларны бутап, өстәлгә тезеп куя. Артист, тамашачыга кара төстәге тасманы күрсәтеп, үзенең күзләрен бәйләргә куша. Тамашачы, тасманы тикшергәч, артистның күзләрен бәйли. Күзләр бәйләнеп, тикшерү беткәч, артист конвертларны, өстәлдән берәмләп алып, аңа бирүне сорый. Тамашачы үзе теләгән конвертны, алып, артистның учына сала.

Артист сул кулы тоткан конверт өстендә уң кулын йөртеп ала да конвертта нинди төстә катыргы барлыгын әйтә:

– Минем бармакларым сизә, бу конверт эчендә кызыл төстәге катыргы, – ди. Икенче, өченче һәм башка конвертларны ярдәмче тамашачы аңа бирә тора. Артист бар төсләрне дә бармаклары белән тоеп ялгышмыйча әйтеп бирә. Соңгы катыргының нинди төстә икәнен әйткәч, күзен каплаган тасманы чишә.

Реквизитлар: ак, кызыл, сары, яшел, зәңгәр төстәге квадрат формасындагы катыргы кисәкләре, биш конверт, күзне бәйләү өчен кара тасма.

Сере: бу менталь трюкның ике төрле сере булырга мөмкин. Беренчесе: һәр конвертның бер почмагына (шартлы) кызыл квадрат дип алыйк, кечкенә сәйлән бөртеге ябыштырыла. Аның өстенә ике яклап, кызыл кәгазь ябыштырасыз.



1 нче рәсем



2 нче рәсем

Әйтик, ак катыргы серсез, буш кала, бер бөртек сәйлән – кызылга, ике сәйлән – сарыга, өч сәйлән – яшелгә, дүрт сәйлән зәңгәргә ябыштырыла.

Шул ук сәйлән бөртекләрен конвертларга ябыштырып, алдан уйланган катыргы кисәкләрен салырга мөмкин (2 нче рәс.). Болай иткәндә, ялгышып, конвертлардагы катыргыны алыштырып, трюкны бозып кую куркынычы бар. Шуңа күрә бик игътибарлы булырга кирәк. Артист конвертны алгач, серле хәрәкәтләр ясап, катыргыга яки конвертка ничә сәйлән бөртеге ябыштырылганын бармаклары белән капшап белә дә кулында нинди төстәге катыргы кисәге булуын әйтә.

Икенче вариант: һәр катыргыга төрле исләр сеңдерәсез.

Мисал өчен, ак төс катыргы иссез була, кызыл төсле катыргыдан – керосин (бензин), сарысыннан – сабын, яшеленнән – духи, одеколон исе, зәңгәреннән ацетон исе килергә мөмкин.

Артист, кулына конвертны алып, баш очына күтәргәндә, сиздермичә иснәп кала. Әгәр ис начар сизелсә, конверт эченнән катыргыны алып, яңадан баш очына күтәргәндә исне сизеп кала да тамашачыларга кулында нинди төсле катыргы икәнен әйтә.

Бу трюкларны бик җитди өйрәнергә кирәк, шул вакытта гына тамашачылар «чынлап та, шулай була икән» дип кабул итәр.

«Күзле» бармаклар

Тәэсире: артистның кулында 12x15 см зурлыгындагы кара тукымадан тегелгән ике катлы янчык. Ул янчыктан төрле төстәге дүрт-биш кубик алып күрсәтә дә, аларны яңадан салып, янчык авызын бау белән бәйләп куя.

Сәхнәгә тамаша залыннан ярдәмче чакыра һәм аңлатып бирә:

1 нче рәсем



2 нче рәсем

– Мин сәхнәдән чыгып киткәч, йә булмаса, артка борылып торганда, капчыкны чишеп, шуннан бер кубикны алып тамашачыларга күрсәтәсез дә яңадан капчыкка салып бәйлисез! – ди. Тамашачы кушканны эшләгәч, артист сәхнәгә чыгып, өстәлдәге капчыкны чишеп, бераз карап, уйлап торгач, тамашачы тоткан кубикны алып күрсәтә.

Реквизитлар: ике катлы кара тукымадан тегелгән 12x15 см зурлыгында капчык (1 нче рәс.), ак, кызыл, сары, яшел, зәңгәр төсләргә буялган биш кубик (2 нче рәс.).

Сере: кубикларның барысы да флюоресцент буяуларга буялган. Акварель буяуларын изеп, аңа фосфор кристалларын һәм ПВА җилемен кушып та буярга мөмкин.

Тамашачы бер кубикны капчыктан алып тамашачыларга күрсәткәндә, фосфорлы кубик үзенә яктылык җыеп өлгерә. Капчыкка салгач, караңгыда ул җемелдәп тора, ә бүтән кубиклар яктыртмый. Артист, капчыкны чишеп, янып торган кубикны алып күрсәтә. Ярдәмчесенә рәхмәт әйтеп, сәхнәдән озата.

Тамашачының күзенә карап төсне белү

Тәэсире: артист кәгазь капчыктан (каптан) дүрт кырлы, дүрт төстә катырргы кисәге ала. Уен карталарын кулланырга да мөмкин. Карталарның масть ягына кызыл, сары, зәңгәр, яшел төстә плёнкалар ябыштырыла, ә арткы ягы шул килеш кала (1 нче рәс.). Залдан бер тамашачыны ярдәмгә чакыра. Аңа карталарны карарга бирә. Тамашачы, карталарны дикъкать белән карагач, бернинди дә сер тапмавын әйтә. Артист, кулындагы кәгазь капның

буш икәнен күрсәтеп, тамашачыга дүрт картаны капка салырга куша. Тамашачы карталарны капка салгач, артист капны тамашачыга тоттыра. Артист бераз уйланып торгач, тамашачыга капны ачып, бер картаны алып, үзе генә карап, конвертка салырга куша.

Тамашачы бер картаны алып, үзе карап, тамаша залына да күрсәтеп, конвертка салып өстәлгә куя. Тамашачыларның күз алдында конвертка салган, ярдәмче тамашачы сайлап алган карта ята. Артист рәхмәт әйтеп, капны алып читкә куя. Тамашачының кулын үзенең кул өстенә куеп, күзләренә текәлеп карап, конверт эчендәге картаның нинди төстә булуын уйларга куша.


1 нче рәсем

Артист:

– Уйлагыз, ашыкмагыз! Конверттагы картаның төсе нинди? Уйлагыз, кычкырып әйтмәгез!

Тамашачы сүзсез уйлый.

Артист:

– Сез сайлаган төс – зәңгәр. Конвертта зәңгәр төстәге карта ята. Конвертны ачып, картаны залдагы тамашачыларга күрсәтегез.


2 нче рәсем

Тамашачы конверттан картаны алып күрсәтә.

Реквизитлар: кибеттә сатыла торган зур булмаган кәгазь пакет, бер конверт, сигез катыргы кисәге, уен карталары булса да ярый. (Аларның бишесе бер төстә, калганнары төрле төстә.)

Сере: дүрт катыргы кисәгенә, йә гади карталарның масть ягына кызыл, сары, зәңгәр, яшел төстә үзе ябыша торган плёнка ябыштырасыз (2 нче рәс.).

Ә калган дүрт картага бертөсле, әйтик, зәңгәр плёнка ябыштырыла. Карталарның арткы ягы шул килеш кала.



3 нче рәсем



Пакетның эченә, ачып ябылырлык итеп, ясалма төп (кесә-клапан) ябыштырасыз. Ул пакетның эче төсендәге ватман кәгазе булырга мөмкин. Әлеге серле төп бик пөхтә итеп эшләнергә тиеш (3 нче рәс.).

Фокусчы пакетны тамашачыларга күрсәткәндә, бертөсле дүрт (зәңгәр) картаны ясалма кесә-клапан белән каплап күрсәтә. Янәсе, анда бернинди дә сер юк (4 нче рәс.).



4 нче рәсем

Ярдәмче тамашачы карталарны дикъкать белән карагач, бутап, пакетка сала. Төсле карталар пакетның чын төбенә салына. Артист кулы белән тотып торган кесә-клапанны җибәрә дә тигезләп куя. Хәзер бертөсле (зәңгәр) дүрт карта өстә кала. Тамашачы ясалма төпнең ябылганын сизмәскә тиеш.

Артист тамашачыны сүз белән мавыктырып, кулын пакетка тыгып клапанны, карталарны төзәтеп ала да, тамашачыга пакеттан бер карта алып, үзе карагач, конвертка салып, өстәлгә куярга куша.

Залдагылар артистның хәйләсез эшләгәнен үз күзләре белән күрәләр.

Конвертта нинди карта булуын ярдәмче белә дә залдагы тамашачылар белә. Артист пакетны алып читкә куеп, тамашачының кулын үз кулы өстенә куярга кушып, күзләренә төбәп карап, нинди картаны сайлавы турында уйларга, әмма кычкырып әйтмәскә куша.

Артист, бераз уйлап торгач, зәңгәр картаны сайлавы турында әйтә. Тамашачы конвертны ачып, залдагыларга күрсәтә. Анда, чынлап та, зәңгәр карта була.

Зирәк чыгыш



1 нче рәсем

Тәэсире: иллюзия өстәленә артист кара төскә буялган дүрт торбачык тезә. Кечкенә матур кәсәдән дүрт әстерхан чикләвеге алып, берәм-берәм шул торбалар өстенә куя (1 нче рәс.).

Тамаша залыннан бер ярдәмче чакыра да, үзе сәхнәдән чыгып киткәч, йә арты белән борылып торганда, бер торба белән чикләвекне, аерым-аерым тамашачыларга күрсәтеп, өстәлгә куярга куша. Ярдәмчесе яхшы аңласын өчен, шушы хәрәкәтне артист үзе дә ясап күрсәтә.

Артист арты белән борылгач, тамашачы торба белән чикләвекне алып, аерым-аерым күрсәтә. Бернинди дә сер юк. Тамашачы чикләвекне торбага куя, аннары артистны чакыра.

Артист тамашачы янына килеп, күзләренә игътибар белән карагач, тамашачының баш өстендә кулын йөрткәч, өстәл янына килеп, бераз карап торгач, кулларын чикләвекләр өстендә тотып, тамашачы алган чикләвек белән торбага туктала.

Артист:

– Менә әле генә сез кулыгызга алган чикләвек белән торба, – ди.

Тамашачыга рәхмәт әйтеп, аны сәхнәдән озата.

Реквизитлар: дүрт катыргы торба, бертигез зурлыктагы дүрт әстерхан чикләвеге.

Сере: бу менталь магиянең беренче сере чикләвектә. Чикләвекләр ике ярымшардан тора. Чикләвекләрнең бөтенесен дә торба өстенә горизонталь (буйга) куярга кирәк. Аларның җөйләре буйга куелуын тамашачы абайлап бетерми. Торбалар катыргыдан ясалган була. Аларны кара төстәге (бүтән төсләр дә ярый), үзе ябыша торган плёнка белән тышлыйсыз. Ул обой-плёнканы ябыштырганда, билгеле инде, җөй хасил була.



2 нче рәсем



3 нче рәсем

Торбаларның җөйле ягын артист үзе йөри торган якка (артка) каратып куя (2 нче рәс.).

Тамашачы дүрт чикләвекле торбадан берсен сайлап алып тамашачыларга күрсәтә дә, өстәлгә куйганда, аларның торышына игътибар итеп тормый (3 нче рәс.).

Артистка башкалардан аерылып торган чикләвек белән торбаны тану кыенлык тудырмый.

Уй-фикерне күз карашы аша тапшыру

Тәэсире: артист-менталист тамаша залыннан бер тамашачыны сәхнәгә чакыра. Аңа бер карта колодасын карарга бирә. Анда бернинди дә сер юк.

Артист карта колодасын кулына алып, җилпәзә итеп җәеп күрсәтә. Берничә мәртәбә бутагач, «күлмәкле ягын» өскә калдырып, яңадан җилпәзә кебек җәеп, тамашачыдан җилпәзәнең теләсә кайсы җиреннән, ике бармагы белән чеметеп кенә тотып, бер картаны сайлап алырга, үзе карагач, тамашачыларга да күрсәтергә кушып, үзе арты белән борыла. Тамашачы бармак очлары белән генә тотып, бер картаны сайлап алып карагач, тамашачыларга да күрсәтә дә, артист аның ягына борылгач, кулындагы картаны яңадан җилпәзә эченә сала. Артист, карталарны тагын бер мәртәбә бутагач, колода тоткан кулына тамашачының сул кулын куйдырып, күзләренә карап, нинди картаны сайлаганын уйларга куша. Тамашачы артистның кулына кулын куеп, күзләренә карап, сайлап алган картасын исенә төшерә.



2 нче рәсем



1 нче рәсем

Артист сул кулындагы колода өстенә уң кулы белән серле хәрәкәтләр ясап, тамашачы сайлаган картаны тартып чыгарып, тамашачыларга күрсәтә. Алкышлардан соң артист ярдәмче тамашачыга рәхмәт әйтеп, аны залга озата.

Реквизитлар: бер колода тылсымлы карта.

Сере: бер карта колодасын, берәмләп, махсус ясалган җайланма-калыпка салып, конус-сыман итеп ике ягыннан да 1 әр мм га кисәргә кирәк (1 нче рәс.). Карталарның бер башы үзгәрешсез кала, икенче башы 2 мм га тарая. Тамашачы карталарның тарайганын сизми.

Күзгә дә андый гына тараю чалынмый. Шуның өчен карталарның киселгән яклары һәрвакыт аска юнәлдерелгән булырга тиеш. Тамашачы җилпәзәдән ике бармак очы белән генә бер картаны сайлап алып, ничек алган, шулай үзгәрешсез тотарга һәм яңадан коло-



3 нче рәсем



4 нче рәсем

5 нче рәсем

дага куярга тиеш. Бу бик мөһим. Шул вакыт эчендә артист кулындагы колоданың тар башын өскә әйләндереп өлгерә.

Тамашачы картаны киң башы белән өскә каратып сала. Шулай итеп, ул башка карталардан аерылып торачак. Артист тиз хәрәкәтләр белән колоданы бутый. Аны тигезләп, сул кулының учына салып, сиздермичә, тамашачы сайлаган картаның дөрес куелуын тикшерә.

Әгәр карта дөрес салынмаса, трюкны күрсәтеп булмый.

Трюкның иң мөһим сере: тамашачы картаның киң башы белән колоданың киселгән тар башына куярга тиеш. Трюкның әзерлеген тикшергәч, тәэсир бүлегендә язылганча чыгыш ясауны дәвам итәсез һәм тәмамлыйсыз.

Карталарны әзерләү җайланмасы: 10–15 см озынлыгында, тигез, калын фанер кисәге кирәк була. Карта зурлыгында агач рейкалар кисеп, фанерга кагып куясыз. Рейканың аскы ягы 2 мм га тар була. Карта зурлыгында ике ягы да 1 мм га киселгән конус калай шаблон ясыйсыз. Картаны җайланмага салып, өстенә калай шаблонын пөхтә итеп куеп, үткен, «итекче» пычагы белән карталарны кисәсез. Колодадагы карталар тигез булсын өчен, аларны яхшылап кысып бәйлисез (2, 3, 4, 5 нче рәс.).

Шуннан соң киселгән карталарның аскы өлешләрен түгәрәкләп кискәч, бик вак наждак белән шомартасыз.

Алдан күрү

Тәэсире: артист-менталист сәхнәгә тамаша залыннан бер хатын-кызны чакыра, урындыкка утыртып, аның кулына зур гына конверт тоттыра. Конверт сургучлап ябылган, эчендәге хатның текстын артисттан башка беркем дә белми.

Артист өстәлдән папка алып, аның эченнән 4–5 открытка чыгарып тамашачыларга күрсәтә. Открыткаларга төрле рәсемнәр, портретлар ясалган. Артист аларны берәм-берәм күрсәтеп чыга да яңадан папкасына сала. Тамашачыларга шушы папка эченнән бер открытканы сайлап алырга тәкъдим итә. Папканы ача, бөтен открыткалар да капланган, кайсы открыткада нинди рәсем, сурәт төшерелгәнен беркем белми. Тамашачы бер открытканы сайлап

ала. Артист, комачауламасын өчен, папкасын читкә алып куя. Тамашачы кулындагы открытканы тамаша залына күрсәтә дә открытканы баш очына күтәреп тора (кыз сурәте булсын, ди). Артист конверт тотып утырган хатын-кыздан конверттагы хатны ачып укырга куша. Хатта язылган текст:



1 нче рәсем

«Хөрмәтле тамашачылар!

Мин сезгә чыгыш ясарга килгәндә үк, шушы кыз бала рәсемен сайлап алуыгызны алдан күргән идем. Ялгышмаганмын. Барыгызга да рәхмәт! Сәламәт булыгыз!

Хөрмәт белән: (артистның исеме).»



2 нче рәсем

Реквизитлар: серле папка, ун открытка (шуларның алтысы бертөсле), артына ясалма сургуч пичәт ябыштырылган зур конверт (1 нче рәс.).

Сере: пөхтә итеп эшләнгән зур конверт. Артына ясалма сургуч пичәтне хәтерләткән кәгазь ябыштырыла һәм эченә алдан ук язылган хат салына (1 нче рәс.). Папканың да сере бар. Тышкы яклары ачык төсле булса, эче куе зәңгәр яки кара төстә булу шарт. Папканың серле бите (клапаны) бар. Шул бит артына бер үк төрле рәсем төшерелгән биш открытка яшерелә (2 нче рәс.).

Артист тамашачыларга папканы ачып, серле бит астына салынган биш төрле открытканы күрсәтә (3 нче рәс.). Тамашачылар аларны күреп, исләрендә калдыра. Артист «ялгыш кына» папканы яба да яңадан ача. Ул, бу вакытта әле генә күрсәткән открыткаларны серле бит белән каплап, икенче кесәне ача. Андагы открыткаларның да рәсемле ягы аста була. Тамашачылар әле генә күргән биш открытка дип


3 нче рәсем



4 нче рәсем

кабул итә. Тамашачы, кайсы гына открытканы сайласа да, шул бер үк рәсемне ала. Трюкның иң мөһим сере, шушы биш бертөсле открытка булганга, аны серле папкасыз эшләп булмый. Шуның өчен хәзер серле папканы ясарга өйрәнәбез.

Серле папканы ясау: 15х30 см зурлыгында ике каты катыргы әзерләгез (юка фанер булса да ярый). Бу катыргылар папканың тышлыгы була.

Ике катыргыны чүпрәк тасма салып, «Момент» җилеме беләнябыштырасыз (4 нче рәс.).

Эчке ягына серле бит итеп каты ватман кәгазе яки юка фанер аласыз. Кәгазьнең баш-башларына ике ягына да юка гына калай пластинка беркетеп, кара тукыма ябыштырасыз. Кара яки куе зәңгәр киҗе-мамык тукыма булуы мәҗбүри, чөнки тукыма ялтырамый, открыткалар да шуып йөрми.

Тамашачы папканың эчендә тагын бер бит барлыгын сизмәскә тиеш. Папканың эчке якларына юка гына кайма ябыштырып, шуның эченә сыярлык итеп бит-клапан ясыйсыз (5 нче рәс.).

Кайма ягына дүрт почмакка да пластик магнит ябыштырып, өсләрен бертөсле үк тукымалар белән каплыйсыз.

Магнит пластинкаларны сувенирлар артына ябыштыралар. Шуннан алып, кечкенә кисәкләргә бүлгәләп, папканың өстенә дә, астына да ябыштырасыз. Ул магнитлар битне ябыштырып торырга ярдәм итәчәк.

Кирәк вакытта гына битне ачып, сезгә кирәкле открыткаларны күрсәтәсез. Тамашачы шулар арасыннан берсен сайлап ала.



5 нче рәсем

Дәрвиш уеннары

Дәрвиш уеннарының туган иле дип Һиндстан санала. Европалылар Һиндстанда дәрвишләрнең чыгышларын күреп хәйран кала торган булганнар. Һиндстанның сәнгать тарихчылары күз буу сәнгатен XV гасырлардан да элегрәк иҗат ителгән дип раслый.

Күз буу сәнгате йога өйрәнүләренә, күнегүләренә тыгыз бәйләнгән. Йогларның өйрәнүе – чиксез куәткә ия булу, яшерен психиканың көче «прана»сы, янәсе, йоглар, озак шөгыльләнү нәтиҗәсендә, үзләренең ирекләре белән төрле могҗизалар эшләргә, күрсәтергә сәләтле булалар. Билгеле инде, иллюзия алымнарын да кулланганнар.

Дәрвишләр, базар фокусчылары чыгышларын шулкадәр бирелеп, оста итеп күрсәтәләр, иллюзия трюклары, чынлап та, психиканың серле көче белән башкарылган кебек тәэсир калдыра. Дәрвишләрнең «акылга сыймаслык» трюкларын рекламада да кулланалар.

Дәрвиш уеннары катлаулы, зур түземлек һәм чыдамлык таләп итә. Үз-үзеңне ышандыру көченә ия булганда гына, уттан, үткен кылычтан, пыяла ватыкларыннан курыкмаска мөмкин. Үзеңне психологик яктан әзерләргә кирәк. Шуларга өстәп, оста итеп иллюзия трюкларын да куллансаң, бик зәвыклы программа ясарга була.

Дәрвишнең, билгеле инде, башына чалма чалынган, күлмәксез тәненә җиңсез камзул һәм киң чалбар (шаровар) киелгән. Хәзер дәрвиш уеннарының серләрен дикъкать белән укып, практик күнегүләргә күчегез.

Баш бармак аша энә-без уздыру

Тәэсире: артист өстәлдән 20 см озынлыкта, 2 мм калынлыктагы энә кебек очланган тимерчыбык ала. Ул ялтырап тора. Спиртлы мамык яки тампон белән бармагын, аннан соң энә-безне яхшылап сөртеп, өстәлгә куя да, 25х25 см зурлыгында яулык алып, сул кулының баш бармагын каплый. Яулык астындагы бармакны, тамашачылар күрсен өчен, резинка белән урап та куя. Яулык каплаган бармагын селкетеп күрсәтә. Яулыкның читен күтәреп,

1 нче рәсем

2 нче рәсем



3 нче рәсем

4 нче рәсем

баш бармакның яулык астында булуын тагын раслый. Тимерчыбыкны баш бармагының очына куеп, акрын гына бармагына кадый. Яулык астыннан энә-безнең үткен очы күренә, артист бармагын хәрәкәтләндерә...

Трюкны тагы да катлауландырып, дәрвиш икенче энә-безне дә яулык астындагы баш бармакка кадый. Бер бармакта ике зур энә. Артист бармагын селкетә, яулыкның бер ягын күтәреп, ике энәнең дә бармак аша узганын раслый (1 нче рәс.).

Артист бераз пауза ясап «хәл алгач», акрын гына энәләрне кире тартып ала. Уралган резинкаларны ашыкмыйча гына сүтеп, яулык астыннан энә кадалган сул кулын чыгарып күрсәтә. Бармак хәтта канамаган да. Яулыкны селкеп, яңадан ике кулы да буш булуын, бернинди дә сер юклыгын раслап күрсәтә.

Реквизитлар: 20 см озынлыктагы, 2 мм калынлыктагы, бер башы энә кебек үткенләнгән-очланган, икенче башы божра кебек бөгелгән ике шома тимерчыбык (2 нче рәс.), 25x25 см зурлыгындагы кызыл яки зәңгәр төсле яулык, резинка, ясалма бармак, спиртлы шешә.

Сере: сихри музыка яңгырый. Дәрвиш өстәленнән ике энә-безне алып, шулай ук сул кулының баш бармагын спирт белән сөрткәч, өстәлдән яулык алганда, ясалма бармакны (напальчникны) җиңел генә кия. Яулыкны селкеп, ике ягын да күрсәткәндә, ясалма бармак, сул кулда яшеренеп, яулык астында кала. Ясалма бармакның тырнак очында һәм ян-ягында энә сы-

ярлык тишекләр бар. Ясалма бармакны, яулык астында җиңел генә киеп, энәләр шуның аша уза. Бу вакытта чын бармак бераз аскарак төшә (4 нче рәс.).

Дәрвиш уеннарын башкарганда, артист үзе дә шуңа чынлап ышанырга тиеш.

Беләк аша пычаклар уздыру



1 нче рәсем

Тәэсире: дәрвиш өстәлдә яткан озын пычакларны берәм-берәм алып күрсәтә. Кара төскә буялган, терсәк озынлыгындагы тартманы төрле яклап күрсәтеп, һәр ике ягына да дүртәр пычак кадап, яңадан тамашачы хозурына чыгара. Тартма эче күренә, анда беләк түгел, бармак сыярлык кына урыннар калган (1 нче рәс.).

Дәрвиш пычакларны, яңадан чыгарып, өстәлгә тезә. Тартманы сул кулының терсәгенә кадәр кия.

Дәрвиш уеннары



2 нче рәсем

3 нче рәсем



4 нче рәсем



5 нче рәсем

Тартмалы кулына кызыл яулык ала да пычакларны, берәмләп кадап, тартма аша чыгара. Сигез пычак кадалган кул хәрәкәтләнә, ниндидер ялган сер юклыгын раслый.

Дәрвиш кулын төрле якка боргалый, пычакларны алып өстәлгә куя. Кулын тартмадан чыгарып, шәрә беләген күрсәтә, бернинди дә яра юк.

Реквизитлар: озынлыклары 250 мм, йөзенең киңлеге 15 мм булган тар йөзле сигез данә пычак, фанердан эшләнгән тартма, 25х25 см зурлыктагы яулык.

Сере: җиде пычак та күгәрмәс тимердән эшләнеп яхшылап шомартылганнар (2 нче рәс.). Сигезенче пычакның сере бар. Ул үлчәү рулеткасыннан кисеп алынып, пычак рәвеше кертеп, яхшылап шомартылган булырга тиеш (3 нче рәс.). Җиңел сыгыла-бөгелә. Трюкны күрсәтү өчен, иң мөһиме – пычак.

Тамашачыга пычакларны күрсәткәндә дикъкатьле булып, серле пычакны, тиз генә күрсәтеп, аерыбрак куярга кирәк. Юка фанер кисәкләреннән ясалган тартманың зурлыгы артистның кулына, беләге юанлыгына карап эшләнә. Кул белән тартма арасында бераз бушлык булырга тиеш. Иң элек тартманы катырак катыргыдан ясап пычак керәсе тишекләрне үзегезгә ярашлы итеп билгеләп тишәргә, кулны тыгып үлчәп, сынап карарга киңәш итәр идем. Һәр тишеккә номер язып, шул тәртиптә генә, кулны тартмага тыккач, пычакларны тишекләр аша уздыра башлыйсыз.

Катыргы тартма яраса, шуның үрнәгендә фанер кисәкләреннән реквизит әзерлисез. Тартманы ясаганда, дюралюминий почмаклык кулланып, почмакларга фанерны заклёпка белән беркетәсез. Тартма җыйнак, матур булып күренергә тиеш (4 нче рәс.).



Рулеткадан ясалган серле пычак, икенче булып, кулны әйләнеп, аскы тишек аша чыгарга тиеш. Ул серле пычакны тыкканда, тартма эчендәге кул, боргаланып пычакны уздырып, аскы тишеккә керергә ярдәм итә (4 нче рәс.).

Калган пычакларны да уздырганда, кулны төрлечә боргалап, пычакларны тыгып, каршы яктагы тишеккә кертергә кирәк. Тамашачылар алгы яктан күрмәсен өчен, тартмадан чыгып торган кул, яулыкны йомарлап тотып, серне яшерә (5 нче рәс.).

Магнитлы дәрвиш

1 нче рәсем

Тәэсире: дәрвиш тамашачыларга сигез гарәп пычагы күрсәтә. Берәмләп идәнгә ташлый, пычакларның барысы да үткен очлары белән идәнгә кадала (1 нче рәс.). Дәрвиш пычакларны җыеп алып ярдәмчесенә бирә дә, күзләрен йомып, бөтен тәне белән көчәнә. Ярдәмчесе дәрвиш күкрәгенең уң, сул якларына пычакны куя, алар ябышып калалар. Маңгаена да бер пычак ябыша. Ярдәмчесе җилкәләренә, терсәктән югары ике беләгенә дә пычаклар куя. Алар биомагнит ярдәмендә тәнгә ябышып кала. Дәрвиш тәнендәге көчәнешне бетергәч, пычаклар тәннән кубып төшә. Ярдәмче идәнгә 60х120 см зурлыгында тукыма җәя. Дәрвиш аңа чалкан ята. Яңадан тәнен, бигрәк тә корсагын көчәндергәч, ярдәмче өч пычак алып, пычакларны очлы башы белән дәрвишнең корсагына ташлый. Пычакларның өчесе дә, туп шикелле дәрвишнең тәненнән атылып, идәнгә төшә. Дәрвиш, торып, тәнен күрсәтә, бернинди дә яра юк.



Реквизитлар: 6–8 гарәп пычагы, 60х120 см зурлыгындагы тукыма.

Сере: пычакларның шулай киң булуы тән бүлеп чыгара торган биомагнитның тәэсир итү көчен киңәйтеп, тәнгә ябышу урыны арта.

Дәрвиш сәхнәгә чыгар алдыннан, көчле физик күнегүләр ясап, тәнен көчәндереп биомагнит эшләп чыгара. Тән тиресендә биомагнит чаткылары көчәеп, тимерне, кәгазьне, калай кашыкларны үзенә тартып тора ала. Мускулларны бушайтуга, тәнгә ябышкан әйберләр үзләре төшеп бетә.

Өйрәнчек дәрвишкә кечкенә киңәш. Тәнгә ябышачак пычакларның бер ягын «Тройной» одеколонда эретелгән канифоль порошогын сыекчасын мамык белән берничә мәртәбә сөртеп киптерәсез. Көчәйтелгән магнитлы тәнгә алар тиз ябыша, ә тәннән начар төшә. Тамашачыларның серне сизүе бар. Бу хәйләне репетиция вакытында гына кулланырга ярый. Корсакка ташланасы өч пычакның очлары бераз тупасрак, аннан соң ярдәмче белән пычакларны корсакка ничек ташлауны репетициядә яхшылап өйрәнергә кирәк.

Кылыч кисмәс кул

Тәэсире: дәрвиш кулына кылыч ала (үлчәмнәре 1 нче рәсемдә күрсәтелгән), җитез сугышу хәрәкәтләре ясап уйнагач, өстәлдән кәгазь кисәге алып үткен кылыч белән җиңел генә кискәли. Теләүчеләргә дә үткерлеген сынап карарга бирә. Кылычның йөз ягын өстә калдырып, сул кулы белән кысып, йодрыклап ала да кылыч тоткан кулын бинт белән кысып урый (2 нче рәс.).

Тамашачылар күрә: кылычны кул кысып тота, өстәвенә бинт белән каты итеп бәйләнә. Дәрвиш кечкенә паузадан соң акрын гына кылычны йодрыктан тартып чыгара башлый.

Шомлы музыка, трюкны ашыкмыйча башкару, тамашачыларны тынсыз калдырып гаҗәпләндерә дә, сокландыра да. Кылыч уч төбеннән тулысынча шуып чыккач, кылычны идәнгә кадап, бәйләнгән бинтны сүтеп, уч төбен күрсәтә. Бернинди дә яра да, кан да юк.

Реквизитлар: яхшы шомартылган, күгәрмәс тимердән ясалган кылыч, йодрык зурлыгына карап әзерләнгән медицина бинты.



1 нче рәсем

Сере: кылычны яхшылап, йон тукыма (сукно) белән сөртегез, ышкыгыз. Кулыгызны да чиста сөлге белән корытып, уч төбенә бераз гына тальк сибегез. Кул коры булырга тиеш. Бинт белән кулны ураганда, кылычның йөзе ягында, өстә, бармаклар белән кылыч арасында, аз гына бушлык калырга тиеш. Бинт ныгытып уралган кебек булырга тиеш. Әгәр кылыч та, кул да коры булсалар, шомартылган тимер (кылыч) кулда җиңел шуып торыр. Кул киселмәсен өчен, кат-кат репетиция ясарга кирәк.



2 нче рәсем

Үзегез белән кечкенә аптечка йөртегез, анда йод, зелёнка булырга тиеш. Кулыгыз яраланса, чыгыштан соң йод сөртеп, стериль бинт белән бәйләгез.



Тәндә ут йөртү

Тәэсире: дәрвиш полиэтилен капчыкларга (сөт пакетлары бик уңай) төргән ике факел ала. Зажигалка белән ут кабыза, факеллар дөрләп яналар. Дәрвиш факеллар белән уйнап, сихри хәрәкәтләр ясагач, утлы факеллар белән беләкләреннән сыпырып уза. Уң, сул як кабыргаларына да факел уты кагыла.

Ярдәмчесенә бер факелны бирә дә, үзе тамашачыларга ян белән борылып билен бөгә. Шул вакытта ярдәмчесе аның аркасыннан утлы факелны йөртә. Дәрвиш елмая гына, тәне пешми.

Ут йоту

1 нче рәсем

Тәэсире: дәрвиш дөрләп яна торган факелларны алып, аларга тәэсирле итеп карагач, акрын гына сул кулындагы факелны авызына якын китерә дә утлы факелны каба. Ут авызда сүнә.

Янып торган икенче факелдан сүнгән факелга яңадан ут кабызып, дәрвиш икенче факелны да авызына алып сүндерә.

Кул чабулар паузасыннан файдаланып, дәрвиш өстәлдән стаканга салган керосинны авызына ала. Ут кабу куркынычы булмаган урынга басып, факелларга бер-бер артлы авызыннан керосин өрә. Шулай итеп, һавада дүрт-биш мәртәбә ут көлтәсе пәйда була. Дәрвиш шушы трюк белән чыгышын тәмамлый.

Реквизитлар: бер стакан керосин, махсус мамыктан уралып, тегәрҗеп (юан җеп) белән чорналган ике факел (1 нче рәс.). Аларны ацетонга манып, полиэтилен капчыкка тыгып, резинка белән бәйләп куясыз. Шулай эшләсәң, ацетон җилләми озак торыр.

Факелны тимерчыбык белән урамагыз. Чөнки тимерчыбык, нык кызып, тәнегезне пешерер.

Сере: беренчедән, тәндәге көчне тупларга өйрәнергә, икенчедән, уттан курыкмаска кирәк. Сак булу да зыян итмәс.

Тәндә ут йөртү өчен, берничә секундка мускуллар белән көчәнергә өйрәнгәч, бер факел белән генә репетиция ясап карагыз. Факелны ацетонга манып, артык сыекчаны идәнгә селкеп төшергәч, зажигалка белән ут кабызасыз. Беләк мускулларын көчәндереп, факелны тәнгә тыгыз басып йөртегез. Тән белән факел арасында бушлык булмаска тиеш. Факелны тәннән аз гына аерсаң да, тән пешә.

Ут йотуның сере: шул ук факеллар. Алар инде бераз сүлпәнләнә башлаган, чөнки озак яндылар.

Дәрвишнең кулында ике факел да яна. Ул аларга «сихерләп» карагач,

беренче факелны авызына каба. Ә чынбарлыкта дәрвиш, факел белән төрле хәрәкәтләр ясап йөргәндә, теленә селәгәен җыя. Тирән итеп сулыш ала. Факелны авызына тыга башлагач, алган сулышын көчле итеп өреп чыгара. Факел юеш телдә сүлпәнләнә төшә, тел пешми кала. Эчке сулышны өрдергәч, факел бөтенләй үк сүнә. Тамашачылар фокусчы утны йотты дип кабул итә. Факел белән «ут йоту» шактый тәвәккәллек сорый. Кашка, керфекләргә, чәчләргә ут кабу куркынычы бар. Шуңа күрә бик сак эшләргә кирәк.

Авыздан ут фонтаны

Тәэсире: дәрвишнең сул кулында ике факел. Уң кулы белән өстәлдәге стаканнан су эчеп ала да факелларның берсен икенче кулына күчерә. Дәрвиш, әле бер, әле икенче факелга таба борылып, сулышын өрә, һавада ут көлтәсе барлыкка килә.

Сере: стаканда – су түгел, керосин. Дәрвиш аны мул итеп авызына ала. Утлы факелны битеннән егерме сантиметр ераклыкта тота. Бер порция керосинны авызыннан факелга өрә. Ут көлтәсе пәйда була. Икенче кулындагы факелга да авызыннан ике-өч мәртәбә керосин өреп, ут фонтаны ясый.

Авызга күп итеп алган керосинны авыз эчендә өлешләп бүләргә өйрәнегез. Шул вакытта фонтан көлтәсе чыгышыгызны бизәр.

Керосинны авызда булгаләргә су кабып өйрәнегез. Чыгыш тәмамлану белән, авызыгызны яхшылап чайкагыз, битләрегезне, кулларыгызны сабынлап юыгыз. Соңыннан бер стакан сөт эчсәгез, төкерек белән йотылган керосинны сөт зарарсызландырыр.

Ут өстендә йөрү

Тәэсире: дәрвиш сәхнәгә 2 м 10 см озынлыгындагы брезент җәймә һәм 2 м лы такта алып чыгып, брезент җәймәне идәнгә җәеп, аның өстенә тактаны сала. Шырпы сызып, тактага ут кабыза. Ут тактаның буеннан-буена дөрләп яна. Дәрвиш, аяк киемен салып, «тылсымлы» хәрәкәтләр ясагач, чалбар (шаровар) балагын күтәреп, ашыкмыйча ут өстеннән уза...

Идәнгә баскач, аякларын сөлге белән сөртеп, аяк киемен кия дә, башын иеп, рәхмәтен белдерә. Ярдәмчесе утлы тактаны брезентка төреп алып кереп китә.

Реквизитлар: 1 әр м лы ике такта, шешә белән ацетон, шырпы, дымлы брезент кирәк булыр.

Сере: утта янасы тактаның төзелешен өйрәник. Йөрергә уңайлы булсын өчен, 12 см киңлектә 1 м озынлыктагы ике тактаны элмәк белән беркетәсез. Тактаның уртасына киң филтә кадаклана. Филтәнең ике ягына да тар рейкалар беркетелә. Ул рейкалар мул салынган ацетон агып чыкмасын өчен кирәк. Такта астына, уттан саклану өчен, суга манчылган брезент җәелә (1 нче рәс.).

Утта йөрер алдыннан, юеш чүпрәккә басып алырга кирәк. Филтә белән аяк табаны астында бушлык булмаска тиеш. Аяк бармаклары тыгыз кысылып, бармак арасына ялкын кермәслек булсын. Чөнки бармак араларын-



1 нче рәсем

дагы тире бик нәзберек, сизгер, утта тиз пешә. Янып торган тактаны дымлы брезент белән каплагач, ут тиз сүнәр.

Өйрәнчек дәрвишнең табаннары «калын тиреле» булырга тиеш. Аның өчен җәй көне күбрәк яланаяк йөрергә кирәк; аяк табаны тупасланса, сизүне, авыртуны җиңелрәк кичерә. Күнегер өчен, су буенда комлыкта яккан учактан көйрәп торган күмерләрне комга җәеп, шуның өстеннән йөреп өйрәнергә була.

Үткен кылычлардан баскыч

Тәэсире: дәрвиш сәхнәгә 1 м 50 см биеклегендә пирамида чыгара. Аңа калын корычтан ясалган, ялтырап торган үткен 4–5 кылычны баскыч итеп куя (1 нче рәс.). Уң кулы белән пирамидадагы кылычларны бердәмләп алып, сул кулындагы тал чыбыгын кискәли.

Кылычларның барысы да үткен, прожектор нурларында ялтырап, шом салалар. Дәрвиш кылычларны баскыч итеп, пирамидага яңадан тезеп чыга. Кечкенә пауза ясап, таянырга таяк ала. Шомлы музыка тавышына, кәкре башлы чүәген салып, аяк табаннарын сөлге белән сөртеп, серле хәрәкәтләр ясагач, акрын гына кылычларга басып, пирамидага күтәрелә.

Пирамида өстенә менеп житкәч, бераз тын алып, яңадан акрын гына төшә. Табан асларын күрсәтә, бернинди дә яра юк. Трюк шуның белән тәмамлана.

Реквизитлар: биеклеге 1 м 50 см булган агач рейкалардан ясалган пирамида, корычтан эшләнгән шома, бер якка гына үткенләнгән 4–5 кылыч, 1 м 80 см озынлыгында җиңел таяк.

Сере: рейканың алгы ягына, кылычларны куяр өчен, рәсемдәгечә итеп ярык (паз) киселә. Кылычлар, тыгызлап, яссы хәлдә пазларга куела (2 нче рәс.). Кылычлар үзенчәлекле итеп, бер ягы гына үткенләнә (3 нче рәс.).



1 нче рәсем



2 нче рәсем



3 нче рәсем

Пирамидага куйганда, кылычларның йөзе аска каратыла. Дәрвиш яланаяктан кылыч йөзенә түгел, ә яссы ягына басып менә. Кылычларны итекче пычагы кебек үткерлиләр.

Чылбыр-богаудан котылу

Тәэсире: сәхнәдә өч кисәккә бүлеп эшләнгән, матур итеп бизәлгән ширма (1 нче рәс.). Дәрвиш зур гына капчык алып, бауларыннан тартып, капчык авызын бәйләп күрсәтә. Дәрвиш ярдәмчесе сәхнәгә залдан тикшереп торырга бер кешене чакыра. Аңа капчыкның сере юклыгын күрсәтә. Дәрвиш озын чылбыр алып залдагы тамашачыларга бирә, аларны тикшергәч, ярдәмчесе алып, урындыкта утыручы дәрвишкә бирә. Дәрвиш утырган килеш, аяк киемен салып, ике аягын да чылбырның бер башына

1 нче рәсем



2 нче рәсем

урап богаулый. Тамашачы тикшергәч, дәрвиш ярдәмчесе тамашачыга йозак бирә дә, богауланган дәрвиш аякларын йозакка бикләргә куша. Тамашачы, чылбыр бәйләнешен тикшереп, йозакка бикли.

Дәрвиш чылбырның икенче очын кулына богау итеп урый. Тамашачы тикшерә. Бернинди дә ялган, хәйлә тапмый. Икенче йозак белән дәрвиш кулын богаулаган чылбырны йозакка бикләп, ачкычларын күз алдына, кечкенә өстәлгә куя. Ассистент әле генә күрсәткән зур капчыкны дәрвишнең аяк очына куя. Дәрвиш ассистент белән тамашачы ярдәмендә капчыкка кереп баса.

Ассистент, капчыкның бауларын күрсәтеп, тамашачы белән бергәләп, капчыкның авызын бәйлиләр. Капчык авызы нык бәйләнгән. Тамашачы, үз кулы белән бәйләп, шикләнергә урын калдырмый. Капчык эчендәге дәрвишне ширма артында калдыралар. Музыка көчәя.

Ассистент кычкырып бер, ике, өч дип санагач, ширманы алсалар, чылбыр богаудан ычкынган, бәйләнгән капчыктан чыккан дәрвиш елмаеп ба-

сып тора.

Капчык бавы чишелмәгән, капчык эчендә чылбыр-богау бикләнгән килеш калган. Тамашачы ассистент ярдәмендә капчыкның бавын чишә, чылбырны алып тамашачыларга күрсәтә.

Реквизитлар: ике метрга якын озынлыктагы зур капчык, өч рамлы ширма, ике метрлы вак чылбыр, ике йозак.

Капчык кара яки куе зәңгәр төстәге калын тукымадан тегелә. Сере бик гади, әмма бик акыллы. Капчык рәсемен өйрәнеп, язылганны игътибар белән укыгыз (2 нче рәс.).

Капчыкның өске ягы 2 см киңлегендә калдырып тегелгән. Шуңа кер бавы кертелгән бау *В* өске кырыйдан барып *Б* ноктасына тегелгән (эчке яктан). Әгәр бауны тартсак, капчыкның өске кырые бөрмәләнеп җыела, бау аз гына «тышка» чыга.

Икенче бау – *Г1* – капчыкның өске кырыеннан узып, *А* ноктасында борылып, капчык төбенә төшеп, *Г2* ноктасына яхшылап тегелә. Әгәр бауны тартсаң, капчыкның өске кырые гына түгел, бөтен сул ягы да җыерылып менәчәк. Бөтен сере дә шушы бауда инде. Капчыкның *А* ноктасы эчке яктан 10–15 см тегелмәгән, ә тышкы якта ялган җөй тегү җепләре күренә. Шушы тегелмичә калган урыннан, ике бармакны тыгып, бауны капчык эченә *А* ноктасына тартасыз.

Капчыкны тикшерергә биргәнче (концертка кадәр) бау *Г1*не *А* почмагына, бер кат җеп белән, җиңелчә генә тегеп куясыз. Көчле тарткач, җеп өзелерлек булсын. Тамашачы бу җепләрне күрмәскә тиеш.

Дәрвиш капчыкка керү белән, ул җепне өзәргә тиеш. Кулы белән шул җирдән каты итеп тотып, бауны бәйләүчеләргә капчыкның авызын бәйләргә ярдәм итеп, серне саклый.

Ширма белән дәрвишне каплауга, ассистент бауны сул яктагы җөйдән *А*, *Г2* эчке якка 40–50 см озынлыгында тартып чыгара. Шуннан дәрвиш җиңел генә ачылган капчык авызыннан чыгып, капчыкның тышкы ягыннан, *Г2* ноктасына басып, бауны тартып, капчык авызын җыерып куя, капчык элекке хәленә кайта.

Сере: 2 м лы вак чылбырны аякка богау итеп урарга өйрәнергә кирәк. Ике аяк арасында чылбыр, ике катлы булып өч мәртәбә бөтерелгәч, уң

аякка тыгыз итеп тартылып, чылбыр очы уралган чылбырга йозак белән бикләнә. Кулларны да шулай ук, башта сул кулны әйләндереп, ике-өч мәртәбә бөтереп (ишеп), чылбырны уң кулга каты итеп тартып урап, йозакка бикиләр.

Капчыкның бавын бәйләүгә, дәрвиш сул кулын чылбыр үргән якка каршы бора, әйләндерә. Чылбырның бәйләнгән – үргән жире бушый, сул кул богаудан җиңел генә чыга да уң кулны тартып аласы гына кала.

Дәрвиш капчык эчендә, урындыкка капчык аша утырган. Сул аякны чылбырның бәйләнеше ягына, көчәнеп, кул ярдәме белән борып чыгарсагыз, чылбыр бушая. Сул аякны тартып алгач, уң аяктагы чылбыр да бушый. Хәзер инде куллар да, аяклар да бушады. Капчыкның серле бавын тартып, капчык авызын ачып чыгып, чылбырны капчык эчендә калдырып, яңадан капчыкның *Г2* почмагына басып, *А* ноктасыннан капчык авызын тартсаң, капчык авызы бөрмәләнеп бәйләнгән килеш кала.

Чылбыр-богау белән кат-кат күнегүләр уздырып богауларга һәм аны тиз генә чишәргә өйрәнү бик мөһим. Капчыктан, богаудан ничек тизрәк котыла алсагыз, чыгышыгыз шулкадәр уңышлы булыр.



уклар аякларны богаулауны күрсәтә

3 нче рәсем

кулларда чылбыр йөреше

4 нче рәсем

Пыяла ватыкларында йөрү



1 нче рәсем

Тәэсире: дәрвиш йә аның ассистенты идәнгә брезент җәймәгә төрелгән шешә ватыклары алып чыгып җәя (1 нче рәс.). Дәрвиш пыяла ватыкларын тамашачыларга күрсәтә. Аяк киемен салып, ашыкмыйча гына пыяла ватыкларына баса һәм шунда йөри. Камзулын (жилетын) салып, аркасы белән пыяла ватыклары өстенә ятып, як-ягына боргалана. Дәрвиш чыгышын тәмамлап торып басКач, ярдәмчесе аның тәненә ябышкан пыяла китекләрен ала.

Реквизитлар: биш-алты шешә ватыгы, брезент җәймә, йод белән аптечка.

Сере: алда әйтелгәнчә, дәрвишнең табан аслары тупас булырга тиеш. Башта вак чуерташларга басып йөрергә, күнегүләр үткәрергә кирәк. Табан асты катылыкка күнегергә тиеш. Шуннан соң сакланып кына пыялаларга басып күнегүләр уздырасыз. Иң мөһиме: һәрбер пыяла кисәгенең очлы кырыйларын игәүләргә кирәк. Вак кыйпылчыклы үткен пыяла кисәкләре булырга тиеш түгел. Чыгыш ясаган вакытта яңа шешә ватсагыз, аның китекләрен читкәрәк куярга тырышыгыз.

Чыгыш вакытында табан каты җәрәхәтләнсә, йод растворы сөртеп, чиста бинт белән бәйләгез. Аспирин порошогы сибеп бәйләсәгез, яра тизрәк төзәлер.

Кадакка яту

Тәэсире: дәрвишнең ярдәмчесе йөзләгән кадак кагылган такта алып чыгып идәнгә куя. Дәрвиш серле хәрәкәтләр ясап, кадаклы тактага ята, ассистенты аңа ярдәм итә.

Дәрвиш тактага сузылып ятканнан соң, ассистент аның күкрәгенә такта куеп, саклык белән генә менеп баса да «нокта куйгач» төшә. Үзе баскан тактасын читкә куеп, дәрвишне кулыннан тартып торгыза. Дәрвиш аркасын тамашачыларга күрсәтә, тәнендә бернинди дә яра юк.

Реквизитлар: кадак кагылган калын такта.

Сере: тактаны әзерләү ысулында. 3 см калынлыкта, 1 м озынлыкта, 45 см киңлектәге шомартылган тактага, араларын 2 см калдырып, квадратлар сызасыз (1 нче рәс.). Дрель белән кадак юанлыгында бишәр тишек тишәсез. Почмакларда дүрт һәм уртада бер тишек тишеп калдырасыз, такта өслегенә тыгыз итеп 4–5 мм юанлыгында кадаклар кагып чыгасыз.

Кадак кагып бетергәч, тактаның артына, кадаклар тигез ятсын өчен, такта зурлыгында фанерны шөрепләр белән беркетәсез. Кадакларның



1 нче рәсем



2 нче рәсем



3 нче рәсем

озынлыгы 100–120 мм, юанлыгы 4–5 мм булса, йөртергә җиңел булыр (2 нче рәс.). Тактаны көрән төскә буясагыз, кадаклар ап-ачык күренеп, тактадан аерылып торыр.

Очлы кадакларның тәнне тишмәвенең сере бик гади. Һәрбер кадакның очын игәүләп яхшылап шомартасыз. Сәхнәдән кадаклар ялтырап күренергә тиеш. Наждак кәгазе белән шомартып чыкканнан соң, күгәрмәсен өчен кадак очларына җиңелчә генә вазелин (солидол) сөртергә була. Ә эшләпәле башыннан 30 мм озынлыгында зубила белән «тешләндереп» чыгарга кирәк. Шулай эшләсәгез, кадаклар какшап, борылып йөрмәсләр (3 нче рәс.).

«Ни өчен тән җәрәхәтләнмәде?» дигән сорауга беренче җавап: кадакларның очлы башлары ерактан караганда сизелмәслек итеп игәүләнгән. Икенчедән, кадаклар еш кагылып, 20 мм^2 өслеккә биш кадак туры килә, шуның өчен тән яраланмый. Бу трюкны бик яхшылап өйрәнергә, күп итеп күнегүләр үткәрергә кирәк.

2нче рәсемдә кадакларның кагылу рәвеше күрсәтелә.

Искәрмә: тамашаны сузу өчен, дәрвиш кадаклы тактада яланаяк йөрергә мөмкин. Моның өчен вак чуерташ өстендә йөреп, аякны күнектерә аласыз.

Эстрада гипнозы

Гипноз кешелек дөньясына элек-электән билгеле. Борынгы Мисыр, Бабил, Грециядә дин әһелләре гипноз белән таныш булганнар. Каһиннәр (жрецлар) гыйбадәт вакытында, гипноз кулланып, гади халыкны гаҗәпләндерә, Аллага ышануны, аның кодрәтенең нинди көчле икәнен күрсәтергә тырышканнар. Меңәр еллар буена халык гипноз көченә ышанып, инанып яшәгән. Христианнарда икона елау күренеше бүген дә яши. Иконаның елавы ул – бик гади фокус. Тарихтан билгеле: Пётр I, икона елавын күргәч, попка әйткән: «Тагын шулай иконаң еласа, попның арт саны елаячак», – дип, чиркәүдән кәефсезләнеп чыгып киткән.

Гипнозда сүз белән мәҗбүр ителүне яхшы белеп, каһиннәр төрле иллюзия, саташу алымнарын киң кулланганнар. Дингә ышанучыга каһин сүз белән тәэсир итеп, янәсе, ул храмда түгел, ә теге дөньяда – ахирәттә йөри, үлгән туганнары белән очраша, Аллаһыны күрә, аның тавышын ишетә дип ышандырган. Уянгач, билгеле инде, кеше гаҗәпләнеп, көчле тәэсир астында, чынлап та, теге дөньяда булдым дип ышанган, якыннарына сөйләгән. Бу ысул, билгеле инде, дингә бирелүчеләрнең күңелен юаткан, киләчәктә оҗмахка керү мөмкинлегенә ышандырган, чиркәүнең данын күтәргән. Ә ислам динендә дин әһеленең өшкерүе гипнозга мисал була ала.

Мөселман дин әһелләре — өшкерт мулла, өшкерт абыстай — сүз белән төрле догалар укып, авыруларга ярдәм иткән. Өшкерт мулла ирләрне дәвалаca, өшкерт абыстай хатын-кызларны, балаларны дәвалый. Авыру кеше, өшкерүченең һәр сүзен дикъкать белән тыңлап, аңа буйсына. Гипноз ярдәмендә, өшкерүче кул астында, авыру кеше үзен үзе дәвалый.

Гипноз грекчадан (һипнос) «йокы» дип тәрҗемә ителә. Чынлап та, йокы халәте белән гипноз бик охшаш. Гипноз йокысының тирәнлеген өчкә бүлсәк: кече, уртача һәм тирән гипноз була. Кече гипнозда сыналучының бөтен тәне йомшап көчсезләнә, авырая. Башында җиңелчә томан, аның хәрәкәтләнәсе дә, уйныйсы да килми, хәтта күзен ачарга да көче булмый. Ә фикер йөртүе саклана, уянгач, сеанста нәрсә булганын яхшы хәтерли.

Уртача гипнозда шушы хәл көчәя барып, аңын югалтып, хәрәкәт итә алмас була. Уянгач, үзе белән нәрсә булганын исенә төшерә алмый.

Эстрада гипнозы

Тирән гипнозда сыналучының аңы бөтенләй югала. Тән тиресе авыруны, эссене, салкынны сизми. Тирән гипнозны операция ясаганда кулланалар. Сыналучы бу очракта сеанс, операция вакытында нәрсә булганын хәтерләми.

Галимнәр гипнозчы бүтән кешеләрдән берни белән дә аерылып тормый, теләсә кемне гипноз сеансы үткәрергә өйрәтеп була дип исбатлый. Гипнозның техникасы да, ысулы да сер түгел, барысы да физиология кагыйдәләренә буйсына.

Гипнозлауның күптөрле ысуллары бар. Шуларның берсе – күз карашын ялтыравыклы әйбергә төбәү. Сыналучыны дикъкать белән ялтыравыклы шарга яки гипнозчының күзләренә карарга кушып, гипноз халәтенә кертәләр, тамашачы ялыккач, гипнозның тәэсире дәвам итә. Шул тәэсир баш миенең калган почмакларына да барып җитә. Шулай итеп, гипноз ясалма йокыны хасил итә.

Гипнозчының йокы турында сөйләве дә уңай тәэсир ясый.

Мисал өчен: «Тыныч кына сулыш алыгыз! Тигез итеп, тирән сулыйсыз... Хәзер сезнең тәнегез авырая, сезгә герләр элеп куйган кебек авыр, хәрәкәтләнәсе, уйлыйсы килми... сез үзегезне тыныч тотасыз... рәхәтләнеп ял итәсез... йокыгыз килә, тирә-ягыгызда тынычлык... сез йокыга китәсез... тирән йокыга китәсез...»

Шулай итеп, акрынлап тамашачыны йокы баса. Бу йокы — гади йокы түгел, ә гипноз йокысы. Сыналучы кеше бары тик гипнозчының гына тавышын ишетә, аңа буйсына.

Гипнозчының, куллары белән йоклатасы кешенең гәүдәсе буенча хәрәкәт ясап, җиңелчә генә тән тиресенә кагылып алуы, аңа көчле тәэсир итә. Гипнозчының кагылуы җиңелчә генә нервның очларын ярсыта. Нервларның очлары баш мие кабыгына һәм шулай ук нервларның үзәгенә дулкыннар җибәрә. Озак тәэсир итү аркасында, баш мие кабыгы талчыга, йокы килә башлый – гипноз йокысы. Гипноз халәтенә кертү өчен, сыналучы тамашачыга, тыныч кына, тәненә кагылмыйча, кулларны гәүдәгә параллель итеп хәрәкәтләндерү дә нервларны ярсыта, баш мие кабыгына көчле тәэсир итә.

Гипнозның бер төре «сомнамбулизм» дип атала. Сомнамбулизм гипнозында кеше хәрәкәтләнә, яза, сыза, хәтта рәсем дә ясый. Сомнамбулизмда сыналучы кеше ачык күз белән «йокларга» мөмкин, шулай ук сорауларга җавап та бирә, хәтта иркенләп йөри, җырлый, бии, хәрәкәтләнә. Соңгыларын эстрада

гипнозында күрергә мөмкин.

Сомнамбулизм халәтендәге кешедә күрү тәэсире калмый. Аңа мәҗбүри итеп, әйтик, аны яр буенда кармак салып, балык тотып утыра. Күз алдына китергән кармагын елгага ташлый, балык тота, шатлана дип ышандыралар. Гипнозчы:

– Сезгә бал кортлары ябыша, чага күрмәсеннәр, – дип кисәтә.

Тамашачы бал кортын куа, кулларын селкеп, битен, башын каплый.

«Сак булыгыз, су баса...» – дигәч, сыналучы судан сакланып урындыкка менеп баса. Гипнозчы аңа таяк бирә дә синең кулыңда таяк түгел, ә зур елан икән дигәч, ул куркып таягын читкә ташлый.

Гипнозчы, тамашачыга алма дип, чи бәрәңге бирә, ул аны тәмләп ашый. Гипнозчы, стаканга су салып, тамашачыга иснәргә, эчеп карарга куша. Тамашачы стаканны алып, суны иснәп эчә дә су икәнлеген раслый.

Гипнозчы, стаканны алып, серле пасс ясый да, иснәгәч, битен җыерып: «Фу-у-у, бу бит – су түгел, ә сасы исле керосин», — дип, тамашачыга иснәргә бирә. Тамашачы да стакандагы суны иснәп, керосин дип кабул итеп, башын читкә бора.

Гипнозчы яңадан стакандагы суны «сихерләп» яңадан исни дә гаҗәпләнеп залга, тамашачы ярдәмчесенә карый. «Дускаем, бу стаканда су да, керосин да түгел, ә югары сортлы «коньяк», – дип, тамашачыга эчәргә тәкъдим ясый. Тамашачы гипноз тәэсире белән суны коньяк дип кабул итеп эчә, битен җыера, авызын сөртә. Гипнозчы стаканны алып өстәлгә куя да тамашачыга «бик дикъкать» белән карый. «Кара әле, туган, син исерден бит, егыла күр-

мә», – дип, аны култыклап сәхнәдә йөртә. «Кара әле, кара әле, нинди матур күбәләкләр оча... Әйдә, тотабыз», – дип, тамашачыны җибәрә. Тамашачы күзенә күбәләкләр күренә башлый, аларны тотмакчы була.

Тамашаны шулай дәвам итәргә була. Инде сеансны тәмамлау өчен, тамашачыны туктата да, мин өчкә кадәр санагач, син йокыдан уянасың дип, чыгышын тәмамлый.

Бу очракта гипнозчының күз карашы көчле тәэсир итеп, тамашачыны үзенә буйсындыра.

Гипнозның кешегә тәэсире

1. Хөрмәтле (әфәнде, ханым) дип, гипнозчы мөрәҗәгать итеп, тамашачыга боерык бирә: «Артың белән миңа таба борылып бас, аякларыңны бергә куй! Кулларыңны гәүдә буйлап төз тот. Башыңны артка чөер, күзләреңне йом, курыкма!»

Гипнозчы аның аркасыннан тотып тора. «Хәзер мин кулларны алгач, син артка таба егыла башлыйсың. Курыкма! Сине минем кул көче артка тарта, син артка егыласың, егыласың...»

Тамашачы егыла башлагач, гипнозчы аны тотып ала.

2. Гипнозчы тамашачыга күзләренә карарга кушып, аның күзләренә үзе дә текәлеп карап, җиңелчә генә яңагына кулы белән кагыла. «Хәзер мин кулымны алгач, сине минем кул көче үзе артыннан тарта, – дип, акрын гына чигенә башлый... Тамашачы да аңа иярә. — Ярар, шул җитәр!» – дип, тамашачыны туктата.

3. Гипнозчы: «Хәзер кулларыгызны каты итеп кысыгыз! Тагы да катырак кысыгыз! Менә кулларыгыз агач кебек катты. Хәзер инде кулларыгызны аера алмыйсыз. Мин бер, ике, өч дигәч, кулларыгыз ычкыныр, йомшап калыр», – дип, өчкә кадәр саный. Тамашачының куллары аерыла.

Хөрмәтле укучы, шушы кыска курс белән гипноз гыйлеме турында сүземне тәмамлыйм. Һәр гипнозчы үзенә кулай программа төзи. Сүзен кыска, аңлаешлы итеп сөйләп, тамашачыны үзенә буйсындыра.

Кан тибеше ярдәмендә яшерелгән әйберне табу

Тәэсире: артист тамашачыларга дикъкать белән бераз карап торгач, ярдәмче чакыра. Залга төшеп, үзенә кирәкле ярдәмчесен сайлап алып, сәхнәгә алып менә.

Кечкенә өстәлдә, мисал өчен: кул сәгате, каләм, балдак, зажигалка, биш сум акча ята. Артист, тикшереп тору өчен, тагын ике кешене чакыра. Алар артистның һәр хәрәкәтен күзәтеп торачаклар. Артист өстәлдәге әйберләрне берәм-берәм алып күрсәтә.

– Минем күзләрне бәйләгәч, ярдәмче тамашачы өстәлдән теләсә нинди әйберне алып яшерсен, – ди. – Хөрмәтле тамашачылар, сезгә бер үтенечем бар, чыгыш вакытында тавышланмыйча утыруыгызны сорыйм. Чөнки чит тавышлар комачаулый, – дип, күзләрен бәйләтә.

Бу вакытта ярдәмчесе, әйтик, өстәлдән биш тәңкә акча алып, күрсәтеп, залга төшеп, бер тамашачының кесәсенә, хатын-кыз булса, учына сала да сәхнәгә менә. Ике «ревизор-тамашачы» артистны өстәл янына китереп бастыралар да үзләре читтән күзәтәләр. Артист, ярдәмгә менгән тамашачыны чакырып алып, сул кулын үзенең уң кулына куюын сорый. Тамашачы сул кулын артистның уң кулына куя. Артист тамашачыдан өстәлдән алган әйберне кайда яшерүе турында уйларга куша.

Артист:

– Ашыкмагыз, уйлагыз! Кая яшердегез өстәлдән алган әйберне?! Исегезгә төшерегез: кая яшердегез? Ә хәзер эзли башлыйбыз. Уйлагыз, уйлагыз! Кайда яшердегез? Күнелегездән шул җиргә барыгыз!..

Артист ярдәмчесе белән кулын алга сузып, акрын гына сәхнәдән төшәләр. Һәрвакыт ярдәмчесенә: «Кайда яшерүең турында уйла», – дип кабатлап бара.

Артист, кулын сузып, акрынлап ярдәмчесен акча яшерелгән җиргә алып килә. Берничә мизгелдән артист, акча яшерелгән тамашачы янына килеп, аның кесәсеннән биш тәңкә акчаны табып ала.

Бәйләвечен салып, ярдәмчесе белән сәхнәгә менеп, кул чабуларга баш иеп, рәхмәтен әйтә. Ярдәмчеләрен, кулларын кысып, сәхнәдән озата.

Чыгышның икенче варианты

Артист үзе сайлап алган кешене сәхнәгә алып менә. Өстәлдәге әйберләрне ярдәмчесе белән бергә залдагы тамашачыларга күрсәтә. Кара тасма белән күзен бәйләп, залга арты белән баскач, ярдәмче-тамашачы өстәлдәге теләсә нинди әйберне, мәсәлән, сәгатьне күтәреп залга күрсәтә дә яңадан урынына куя. Артистны өстәл янына алып килә.

Артист үзенең уң кулы өстенә тамашачының сул кулын куюын сорый. Артист тамашачыга өстәлдән нинди әйберне күтәреп куюын уйларга куша. Кабат-кабат шул сүзләр кабатлангач, артистның сузган кулы өстендә тамашачының да кулы хәрәкәткә килеп, куллар акрын гына өстәл өстендәге әйберләр өстендә хәрәкәтләнә дә, әле генә күтәрелгән сәгать өстендә туктап, аны күтәрә. Күтәреп күрсәткән әйбернең сәгать булуын тамашачы раслый.

Сере: бу трюкның сере бик нечкә – нәзберек, тамашачының дулкынлануы, кан тибеше ярдәм итә.

Артист залдан тәҗрибәле күзе белән гипнозга тиз бирелүчән кешене сайлап ала. Булачак ярдәмченең кулы, уч төбе дулкынланудан дымланган була, бигрәк тә хатын-кызларның.

Тамашачыны сәхнәгә алып менгәч, аның күзләренә дикъкать белән карарга, дулкынланудан кулларының сизелмәс кенә калтыравын күзәтергә кирәк.

Артистның кулына тамашачы кулын куйгач, аның кан тибешен сизеп, артист: «Уйлагыз, искә төшерегез!» – дип, кат-кат боерык бирә башлагач, тамашачының кан тибеше ешая, ул үзе дә сизмәстән акрын гына артистның кулын яшергән йә күтәреп күрсәткән әйбер янына этәрә бара. Шулай итеп, тамашачы үзе яшергән әйбер янына алып килә.

Бу трюкны башкару өчен, гипноз алымы да ярдәм итә. Тамашачыга көчле итеп тәэсир ясарга, сиздермичә аны үзеңә буйсындырырга кирәк. Сәхнәдә эшләп күп тәҗрибәләр туплагач кына, мондый катлаулы, гипнозлы трюкларны башкарырга мөмкин.

Күз буу театры

Иллюзия сәнгатендә аны «Чёрный кабинет» дип йөртәләр. Кара театр нәрсәдән башлана соң ул? Сәхнә кара тукымага (бәрхеткә) «киенә». Арткы пәрдә, ян-як пәрдәләр, хәтта падуга (түшәмне каплаучы пәрдә) да кара тукымадан. Идәннең дә бер өлешенә кара тукыма җәелә.

ПРК дигән ике прожектор, хәзер зәңгәр ут дип аталган прожекторлар кирәк булачак. Чөнки ул прожекторлар ак, сары, кызыл, зәңгәр, яшел төстәге синтетик, мамык тукымаларны, караңгыда нурларны кире кайтарып, янып торган кебек күрсәтә. Ә кара тукыма ПРК нурларын сүндерә. Әгәр артист баштанаяк кара тукымадан киенсә, ул сәхнәдә күренми.

Кулына кигән кара бияләйне салса, һавада ул кигән ак перчатка «йөзеп йөрергә», төрле кызыклы хәрәкәтләр ясарга мөмкин. Шулай итеп, бик кызыклы иллюзия – күз алдау барлыкка килә. Ак тукымадан ясалган бутафор

кошлар очарга, этләр идәндә чабып йөрергә, көтмәгәндә пәйда булып юкка да чыгарга мөмкин.

Сәхнә караңгылыкка чумган, сихри музыка яңгырый, кинәт ак костюм кигән иллюзионист пәйда була. Тылсымлы таяк минем тирәдә «биегәч», аны селтәүгә, актан киенгән партнёршам килеп чыга. Икебез дә кул белән «тылсымлы» хәрәкәтләр ясауга, иллюзия өсталләре пәйда була. Арткы пәрдәдә зур чәчәкләр үсеп чыга.

Тамаша, «Шүрәле» поэмасына ияреп, яңа персонажлар өстәп, искиткеч зәвыклы тамашага әйләнде. Шартлау белән, Шүрәле пәйда була, шулай ук юкка да чыга... һәм башка күптөрле иллюзия трюклары өстәлде.

Янып-яктырып торган юан бау (канат) үзлегеннән, дәрвиш «сихере» белән күккә чөелеп катып кала. Дәрвиш «кушуы» буенча, Шүрәле бауны кулына алуга, бау җанланып, аны елан кебек чорнап алып юкка чыгалар.

Танылган драматург, прозаик, режиссёр Роберт Батулла гарәп әкият-

ләре циклыннан «Галәветдиннең серле лампасы» дигән әкиятне пьеса итеп язуымны сорады. Анда күп кенә могжизалар булырга, әлбәттә инде, кул сугышлары, төрле мәкерле ситуацияләр тулып ятарга тиеш.

Әлмәт дәүләт театрының баш режиссёры Зәкия апа Туишева әлеге әкият белән кызыксынып әсәрне сәхнәләштерергә үземне чакырды. Мин ул вакытта Казан циркының баш режиссёры идем. Сезон ачылырга бер айдан артык вакыт булгач ризалаштым.

Әсәргә «Шайтан гына өметсез» дигән яңа исем биреп, репетицияләр башланды. Әлмәт театрының артистларына бик зур рәхмәтлемен, репетицияләргә зур энтузиазм белән йөрделәр. Базар массовкасына хәтта укучы балаларын да алып килеп, аларны да катнаштырдык.

Әсәрне кара кабинет алымы белән куйдым. Җиде күренештән торган тамашада, сәхнә пәрдәсе ябылмыйча, «могҗиза» белән күренешләр алышынып торды. Һәр күренеш караңгы сәхнәдә, кара пәрдәләр эчендә, яктырып, бик кызыклы күз алдау – иллюзия килеп чыкты.

Галәветдиннең җен белән очрашуы балаларны гына түгел, зурларны да сискәндерә. Чөнки буш, караңгы сәхнәдә ПРК прожекторлары яктысында, көтмәгәндә шартлау булып, томан эченнән җен пәйда була. Аның йонлы гәүдәсе янып, ялтырап тора. Ул шулай ук сихер көче белән юкка да чыга. Мәгарәдә, өч-дүрт метр биеклектә хан кызының билдән югары өлеше генә ак таганда атынып утыра. Ул – Убырбикә, Галәветдинне алдамакчы. Әмма Галәветдин, сизгерлек күрсәтеп, серле балдак кигән кулын сузуга, хан кызы, битен сыпырып, Убырбикәгә әверелеп, таганы белән бергә караңгы мәгарә эчендә юкка чыга.

Иллюзия трюкларының җыелма сере.

1. Сихри-серле образларның пәйда булуы, юкка чыгуы: артистның ак тукымадан тегелгән киемдә булуы шарт. Ак тукыма зәңгәр утны көзге кебек кире кайтара. Шуңа күрә ул янып күренә.

Костюмнарны тектергәндә, тукыманың зәңгәр утта янып күренүен тикшереп алырга кирәк. Гади мамык ситсы күлмәк караңгыда бик яхшы яктырып күренә.

2. Реквизитларны буяганда, төрле төстәге флюоресцент буяулар да кулланып, шуңа фосфор порошогы да өстәсәгез, бик матур, янып тора торган реквизитлар сәхнәне бизәр.

3. Артистның кинәт кенә пәйда булуы — бик гади трюк. Артист үзе буе кара тукымага яшеренеп чыга. Кара тукыманың өске башына полиэтилен торба кидерсәң, артистка тотарга җайланма була.

Икенче варианты: шул тукыма озын кара таякка беркетелеп, кара киемдәге ассистент артистны яшереп тора. Кирәк вакытта тиз генә кара тукыманы идәнгә төшерә дә тартып үзе белән алып чыгып китә (1 нче рәс.).

4. Серле тәэсир өчен махсус шартлаткыч эшләргә була. Кара тукымага уралган таяк башына агачтан кечкенә ялгаш ясала. Шуңа электр чыбыгы уздырылып, ялгаш эченә нечкә никель чыбыгы тартылып, плюс-минус чыбык башлары ялгана (2 нче рәс.). Шул ялгашка бер бал кашыгы чамасында кара дары салына. Таяк башындагы электр чыбыгын розетка белән тоташтыргач, никель, кызып, дарыны шартлата. Шартлау көчле булмый, күбрәк эффект биреп тотен чыгара.

Шул вакытта кара тукыманы артист алдыннан алгач, ул сихри рәвештә пәйда була.



1 нче рәсем



2 нче рәсем

3 нче рәсем



4 нче рәсем

5. Караңгы мәгарәдә хан кызының (Убырбикәнең) ярты гәүдәсе таган атынып утыруын ясавы катлаулырак. Арткы кара пәрдә алдына, ак бауга эленгән таган куела.

Таганга артистканың күкрәгенә кадәр ясалган «бюст» урнаштырыла (3 нче рәс.). Артистканың ярты гәүдәсе арткы пәрдә артында, махсус ясалган биек урындык-баскычта ята (4 нче рәс.).

Хан кызының Убырбикәгә әверелүе. Артистка башына, артка чөеп, Убырбикә маскасын яшерә. Кулы белән битен сыйпагач, масканы башыннан битенә төшерә. Баштагы масканы резинка төшермичә тора.

Убырбикәнең «юкка» чыгуы. Таганга беркетелгән бюстның баш очына кара нечкә бау белән рулон итеп төрелгән кара тукыма бәйләнгән. Баудан тартуга, төен чишелә дә тукыма, аска тәгәрәп төшеп, Убырбикәне каплый. Кара тукыма каплауга, артистка биек урындыктан төшә. Таган, кара тукыма астында калып, падуга белән бергә өскә күтәрелә.

Күренешләрнең алмашынуы

Пьесаның ничә күренештән торуына карап, арткы пәрдә артына күренешләр элентә (1 нче рәс.). 0 – кара төсле арткы пәрдә, 1, 2, 3 күренешләр падугага эленгән (2 нче рәс.).

Күренешне тәэсирле итеп күрсәтү өчен, зәңгәр ут янганда, акрын гына «0» кара пәрдәне падуга күтәрә. Беренче күренеш пәйда була. Икенче күренешне ачу өчен, кара пәрдә төшә, беренче күренеш өскә күтәрелә. Икенче күренеш әзер тора. Өченче күренешне ачу да шулай эшләнә. Кара пәрдә төшүгә, икенче күренеш өскә күтәрелә. Кара пәрдә күтәрелсә, өченче күренеш тора.

Арткы пәрдәдә үзгәрү алымнарын биек сәхнәле падугалар булганда гына эшләргә мөмкин. Ә инде андый мөмкинлек булмаса, әсәрдә ничә күренеш булуына карап, пәрдәләрне нечкә трос ярдәмендә тарттырабыз.

Ул шулай ук җиңел корыла һәм җиңел җыела.

Биеклеге, сәхнә зурлыгына карап, 4–5 метр, киңлеге 10–13 метр, ян-як пәрдәләр 4 данә.



1 нче рәсем



2 нче рәсем

Фокус остасы

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Альберт Гадел исеме сәнгать сөючеләргә яхшы таныш. Берәүләр аны күз буу остасы, фокусчы буларак үз итсә, икенчеләр аның әсәрләре буенча куелган спектакльләрне карап хозурлана. Альберт Гадел иҗатындагы әлеге ике юнәлеш бер-берсен тулыландыра, киңрәк, колачлырак, мавыктыргычрак итә. Нәтиҗәдә, аның сәхнә әсәрләре көтелмәгән маҗараларга бай була һәм, күз буу алымнары белән баетылып, шулай ук көтелмәгән чишелеш табыла. Соңгы 15–20 елда Казан рус яшь тамашачы театрында бара торган спектакльләре яшь буынны да, өлкәннәрне дә бер үк дәрәҗәдә җәлеп итә.

Алтмышынчы еллар урталарыннан бирле аның иҗатын күзәтеп баручы буларак шуны әйтә алам: фокусчы, әкиятче, драматург Альберт Гадел һәрдаим эзләнүдә, иҗат чишмәсе һич саекмый, байый, тулылана гына бара. Советлар чорында «Күз буу театрын» оештырып җибәрүче дә ул,

һәм әлеге төр театр тамашачыларда зур кызыксыну уятты. Гипноз, дәрвиш уеннары да шул театрда урын тапты һәм халыкны уйландырды, җәлеп итте. Шул рәвешле, Альберт Гаделнең режиссёрлык таланты ачылды, шуңа язучылык сәләте өстәлде. Аның дистәләгән пьесасы сәхнәләрдә уйналды, «Бер чүлмәк алтын», «Кырлай кызы Айсылу» дигән китаплары нәшер ителде.

Мәскәүнең сәнгать академиясендә, Казанда педагогия институтында белем алган, Россиянең Театрлар берлеге, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Альберт Гадел тормышта һәм иҗатта бик актив. Татар циркын оештыручыларның берсе дә әле ул. Күп еллар Казан циркында баш режиссёр булып эшләп халкыбызга хезмәт итте.

Хөрмәтле укучыбыз! Әле сез танышасы китапны «Күз буу сәнгатенең энциклопедиясе» дип әйтү дә бер дә ялгыш булмас. Чөнки анда «күз буу» сәнгатенең бөтен жанрлары яктыртылып, хәтта ничек, нинди әйбердән реквизитларны ясау ысуллары да язылып, киңәш бирелә. Бу китапта күп кенә яңа чыгыш ысуллары кертелеп, «классик» фокусларның сере ачыла.

Альберт Гадел, иллюзия, микромагия, менталь магия трюкларының серләрен кызганмыйча, укучылар белән уртаклаша. Ошбу китап күз буу сәнгатен яратучыларның өстәл китабы булып, шкаф шүрлегендә тузанланып ятмас.

Булачак артистларга – фокусчыларга иҗади уңышлар теләп:

Габделбәр Ризванов,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

Минем фокус

Справочное издание
Для детей среднего и старшего школьного возраста
Гадель Альберт
(**Гадельшин** Альберт Сунгатович)
ЭНЦИКЛОПЕДИЯ ФОКУСОВ

Казань. Татарское книжное издательство. 2016
На татарском языке

Белешмә басма
Урта һәм өлкән яшьтәге мәктәп балалары өчен
Гадел Альберт
(**Гаделшин** Альберт Сөнгат улы)
ФОКУСЛАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Мөхәррире *А. Ф. Галиәхмәтова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *И. Р. Шәмсетдинов*
Корректоры *С. З. Гыймалетдинова*

12 + Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436 – ФЗ.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11.10.2016. Форматы 84x108. $^1/_{16}$. Басма табагы 15,12.
Тиражы 2200. Заказ М-2780.
«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://www.tatkniga.ru
e-mail: info@tatkniga.ru

Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:
Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 29/11. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

Маркетинг бүлеге:
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

Интернет-кибет: http://www.tatkniga.ru

«Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

9 785298 031752